# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2024 1 (41)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

*Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «2023–2030 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программалары кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология
һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият),
ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т.,
СӘЛАХОВА Ә.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Хисамов О.Р.* Идел-Урал һәм Себер татарларының тел һәм этник бердәмлегенең экстра- һәм интралингвистик аспектлары . . . . . . 7
*Мирхәев Р.Ф.* XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында татар әдәби теленең функциональ стильләре. . . . . . . . . . . . .12
*Кузьмина Х.Х.* Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында фразеологик берәмлекләр, мәкаль һәм әйтемнәрнең стилистик кулланылышы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .22

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Заһидуллина Д.Ф.* Шәриф Камал: яшәү моңын сурәтләү . . . . . .30
*Надыршина Л.Р.* 1960–1980 еллар татар поэмаларында лириклашу һәм фәлсәфиләшү тенденциясе *(Илдар Юзеев иҗаты мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . .50
*Гайнуллина Г.Р.* Әмирхан Еникинең 1980–1990 еллар публицистикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .58
*Миңнуллина Ф.Х.* Шамил Усманов драматургиясе . . . . . . . . . .65

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Милли фольклор томнарын төзү: булган тәҗрибә, заманча таләпләр, перспективалар һәм бурычлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .71

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Габдулхакова Г.М., Халилова Л.Р.* Кыргызстан Республикасы Ош шәһәре татарларының милли-мәдәни тормышы (1990–2020 еллар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .80

### МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Абдуллина Д.М., Мөхәммәтҗанов Ә.Х.* Уку-укыту процессында милли уеннар һәм аларның шәхес тәрбияләүдәге роле . . . . . . .85

### СӘНГАТЬ

*Алексеева Е.П.* 1920–1930 елларда Татарстанда кино сәнгате барлыкка килү *(«Татаркино»ның 100 еллыгы уңаеннан)* . . . . . .91
*Юнысова Г.Ф.* «Кави – Сәрвәр» операсы: әдәби-музыкаль нигез һәм куелыш үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
*Шевченко Е.Н.* Драматик спектакльдә пластиканың роле турында *(Г. Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры тәҗрибәсеннән)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110

### ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР

*Фәхрелислам Агиев.* «Көндезге сәхәр» . . . . . . . . . . . . . . . . 116

## ФӘННИ ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*Усманов В.М.* Ютазы төбәгенең ташъязма истәлекләре . . . . . . 125

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Данилова И.Л.* Фәнгә фидакяр хезмәт
*(галим Й.Г. Нигъмәтуллинаның тууына 95 ел тулу уңаеннан)* . . 136
*Габидуллина Ф.И.* Галимнәр остазы
*(Флүн Мусинның тууына 85 ел тулу уңаеннан)*. . . . . . . . . . . 148
*Булатова М.Р.* Тел галиме И.С. Насиповка 60 яшь . . . . . . . . 154

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Закирҗанов Ә.М.* Шәриф Камал турында яңа китап
(«Шәриф Камал: фәнни-популяр җыентык / төз.: А.Р. Шәйхин,
Г.Р. Җиһангирова. Казан: Җыен, 2023. 416 б. («Шәхесләребез»
сериясе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
*Юсупова Н.М.* Рухи мирас сагында . . . . . . . . . . . . . . . . 164
*Абдуллин Х.М.* Э.К. Сәлахованың «Тәтеш өязе татарларының
көнкүреше һәм рухи тормышы (XVIII йөз ахыры – XX йөз башы)»
(Казан, 2023. 296 б.) китабына рецензия . . . . . . . . . . . . . . 171

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

## В НОМЕРЕ


### ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Хисамов О.Р.* Экстра- и интралингвистические аспекты языковой и этнической общности волго-уральских и сибирских татар . . . . 7

*Мирхаев Р.Ф.* Функциональные стили татарского литературного языка во второй половине XIX – начале XX века . . . . . . . . . . .12

*Кузьмина Х.Х.* Стилистическое употребление фразеологических единиц, пословиц и поговорок в поэме Кул Гали «Кысса-и Йусуф» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .22

### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Загидуллина Д.Ф.* Шариф Камал: изображение грусти бытия . . . .30

*Надыршина Л.Р.* Лирическая и философская тенденции в жанре поэмы в татарской литературе 1960–1980-х гг. *(на примере творчества Ильдара Юзеева)* . . . . . . . . . . . . . . .50

*Гайнуллина Г.Р.* Публицистика Амирхан Еники 1980–1990 годов .58

*Миңнуллина Ф.Х.* Драматургия Шамиля Усманова . . . . . . . . .65

### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Мухаметзянова Л.Х.* Составление свода национального фольклора: опыт, современные требования, перспективы, задачи .71

### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Габдулхакова Г.М., Халилова Л.Р.* Национально-культурная жизнь татар города Ош Кыргызской Республики (1990–2020 гг.) . . . . .80

### НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Абдуллина Д.М., Мухаметзянов А.Х.* Национальные игры в учебном процессе и их роль в воспитании личности . . . . . . .85

### ИСКУССТВО

*Алексеева Е.П.* Основные этапы и тенденции развития киноискусства в Татарстане в 1920–1930-х гг. *(к 100-летию «Татаркино»)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .91

*Юнусова Г.Ф.* Опера «Кави – Сарвар»: особенности литературно-музыкальной основы и постановки . . . . . . . . . 105

*Шевченко Е.Н.* О роли пластики в драматическом спектакле *(из опыта Казанского татарского театра юного зрителя им. Г. Кариева)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110

### НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Фахрелислам Агиев.* «Көндезге сәхәр» («Обед во время уразы») . 116

**ПО СЛЕДАМ НАУЧНЫХ ЭКСПЕДИЦИЙ**

*Усманов В.М.* Эпиграфические памятники Ютазинского района РТ . 125

**ПЕРСОНАЛИИ**

*Данилова И.Л.* Жизнь, посвящённая высшим целям научного познания *(к 95-летию со дня рождения Ю.Г. Нигматуллиной)* . . 136

*Габидуллина Ф.И.* Наставник учёных *(к 85-летию со дня рождения Флюна Мусина)* . . . . . . . . . . . 148

*Булатова М.Р.* Языковеду И.С. Насипову – 60 лет . . . . . . . . . . 154

**НОВЫЕ КНИГИ**

*Закирзянов А.М.* Новая книга о Шарифе Камале («Шәриф Камал: фәнни-популяр җыентык / төз.: А.Р. Шәйхин, Г.Р. Җиһангирова. Казан: Җыен, 2023. 416 б. («Шәхесләребез» сериясе)) . . . . . . 159

*Юсупова Н.М.* На страже духовного наследия . . . . . . . . . . . 164

*Абдуллин Х.М.* Рецензия на книгу Э.К. Салаховой «Тәтеш өязе татарларының көнкүреше һәм рухи тормышы (XVIII йөз ахыры – XX йөз башы)» (Казань, 2023. 296 с.) . . . . . . . . . . . . . . . . . 171

**НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ**

УДК 81'28

*О.Р. Хисамов*

# ИДЕЛ-УРАЛ ҺӘМ СЕБЕР ТАТАРЛАРЫНЫҢ ТЕЛ ҺӘМ ЭТНИК БЕРДӘМЛЕГЕНЕҢ ЭКСТРА- ҺӘМ ИНТРАЛИНГВИСТИК АСПЕКТЛАРЫ

Татары, второй по количеству народ в Российской Федерации, расселены по всей территории страны. В Западной Сибири в основном распространён восточный диалект татарского языка. Однако здесь также имеются населённые пункты носителей среднего и западного диалектов, которые вместе с местными представителями татарского народа образуют единую языковую и этническую общность. В статье автором раскрываются экстра- и интралингвистические аспекты ее формирования.

**Ключевые слова:** татары, сибирские татары, волго-уральские татары, татарский язык, восточный диалект татарского языка, топонимия.

Tatars, the second largest people in the Russian Federation, are settled throughout the country. The eastern dialect of the Tatar language is mainly widespread in Western Siberia. However, there are also settlements of speakers of the middle and Western dialects, which, together with local representatives of the Tatar people, form a single linguistic and ethnic community. In the article, the author reveals the extra- and intralinguistic aspects of its formation.

**Keywords:** Tatars, Siberian Tatars, Volga-Ural Tatars, Tatar language, eastern dialect of the Tatar language, toponymy.

Татарлар – Россиядәге бай мәдәни һәм тарихи мираска ия булган иң күпсанлы халыкларның берсе. Алар яшәгән торак пунктлар көнбатышта Рязань һәм Тамбов өлкәләреннән алып көнчыгышта Кемерово өлкәсенә һәм Красноярск краена кадәр, төньякта Вилюй елгасыннан алып көньякта Әстерхан өлкәсенә кадәр урнашкан.

Көнбатыш Себер территориясендә, нигездә, татар теленең көнчыгыш диалекты таралган. Шул ук вакытта биредә урта һәм көнбатыш диалект вәкилләре гомер иткән авыллар да бар.

Көнчыгыш диалект вәкилләре яки Себер татарлары Көнбатыш Себернең абориген халкы саналалар. Аларның әлеге җирләрдә таралып урнашуы күп гасырлык этногенетик һәм миграцион процессларның нәтиҗәсе булып тора. Төрле тарихи чорларда Казан татарлары да Көнбатыш Себергә күпләп күчеп килгәннәр, җирле халык белән катнашканнар һәм алар белән бергә бердәм рухи-мәдәни мохит тудырып, татар милләтен формалаштырганнар.

Себер татарлары теленең үзенчәлекләрен өйрәнү чагыштырмача күптән башлана. 1801 елда И. Гиганов татар теленең беренче грамматикасын бастырып чыгара, ул нәкъ менә Себер татарлары диалектларын анализлауга багышлана [Гиганов, 1801]. Алга таба бу эшне

Н.Б. Атнометов дәвам итә. 1802 елда аның «Букварь татарского и арабского письма с приложением слов со знаками, показывающими их выговор» исемле хезмәте дөнья күрә [Атнометов, 1802].

Себер татарлары сөйләшләрен фәнни яктан беренче булып В.В. Радлов өйрәнә. Ул аларга караган текст материалларын бастыра, үзенең «Сравнительная грамматика северных тюркских языков» хезмәтендә диалектның фонетик үзенчәлекләрен анализлый. Галим шулай ук Себер татарларының этник составына да игътибар итә. В.В. Радлов тарафыннан бастырылган материаллар алга таба төрки телләр өлкәсендәге бик күп тикшеренүләргә этәргеч бирә. Алга таба Себер татарлары сөйләшләренең фонетик үзенчәлекләрен өйрәнүгә В.А. Богородицкий да зур өлеш кертә.

Татар теленең көнчыгыш диалектын җитди һәм системалы рәвештә өйрәнү совет чорында башлана. Әлеге өлкәдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан дәүләт университеты, Төмән дәүләт университеты һәм Тубыл дәүләт педагогика институты галимнәре зур көч куялар. Мәсәлән, 1939 елда Казанда Тел, әдәбият һәм тарих институты булдырыла, ә инде 1940 елда Институт тарафыннан Көнбатыш Себергә, бараба татарлары яшәгән җирләргә беренче фәнни экспедиция оештырыла.

1950 еллар башында Себер татарлары сөйләшләрен Ленинград һәм Мәскәү дәүләт университетларында, шулай ук Томск педагогика институтында өйрәнә башлыйлар. Тикшеренүләр Казанда да дәвам итә, ә 1950 елларның ахырында Тубыл дәүләт педагогика институтында аерым хезмәтләр дөнья күрә. Бу чорда А.П. Дульзон, Л.В. Дмитриева, Г.Х. Әхәтов һәм Д.Г. Тумашева кебек галимнәрнең эшләре игътибарны җәлеп итә.

Алга таба татар теленең көнчыгыш диалектын өйрәнүгә Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Ф.Ю. Йосыпов, Г.М. Сөнгатов, З.Р. Садыкова, Г.Ч. Фәйзуллина, Х.Ч. Алишина, Р.С. Барсукова һ. б. галимнәр үз өлешләрен кертәләр. Алар фәнни экспедицияләр составында Көнбатыш Себергә кабат-кабат барып, беренче чиратта «Программа» (1959) нигезендә материаллар җыялар һәм «Татар халык диалектлары атласы»н төзүдә катнашалар.

Себер татар топонимиясе буенча тикшеренүләр Н.К. Фролов, Т.А. Баранова, М.А. Сәгыйдуллин, Н.В. Хромова (Лабунец) хезмәтләрендә чагылыш таба. Ә Х.Ч. Алишина һәм аның күпсанлы шәкертләренең хезмәтләре бу өлкәдә зур казаныш булып тора.

Алга таба Себер татарларының фольклорын һәм диалектларын тикшерүдә Себердән чыккан татар галимнәренең – Х.Я. Ярми (Ярмөхәммәтов), Ф.И. Урманчеев, Д.Г. Тумашева, Ф.В. Әхмәтова, Х.Х. Гатина кебек фольклорчы һәм диалектологларның эшчәнлеген аерым билгеләп үтәргә кирәк. Алар, җирле сөйләшләр вәкилләре буларак, татар теленең көнчыгыш диалектын камил белгән хәлдә, Себер татарларының сөйләш һәм фольклор үрнәкләрен җыю һәм фәнни яктан өйрәнү буенча зур эш башкаралар.

2009 елдан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты татарлар күпләп яшәгән төбәкләргә, шул исәптән Себергә дә, комплекслы фәнни экспедицияләр үткәреп килә. 2014 елдан башлап Институт галимнәре әлеге чаралар кысаларында Курган, Омск, Новосибирск, Томск, Иркутск, Төмән, Кемерово өлкәләрендәге һәм Красноярск краендагы татар авылларында булдылар. Нәтиҗәдә тарих, диалектология, фольклор һәм сәнгать юнәлешләре буенча гаять бай материал тупланды.

Идел-Урал һәм Себер татарларының тел берлеге әлеге халыкларның этник мәдәниятенең иң кызыклы аспектларының берсе санала. Татар теле төрки телләр гаиләсенә керә һәм күпсанлы сөйләшләрне үз эченә алган өч диалекттан оеша. Аерым фонетик, морфологик, лексик үзенчәлекләргә ия булуга карамастан, алар үзләренең төп уртак билгеләре белән үзара тыгыз бәйләнештә яшиләр һәм бердәм татар теленең җирле төрләре булып торалар. Диалектлар һәм сөйләшләрнең әлеге бердәмлеге уртак грамматик структурага һәм лексик фондка нигезләнә.

Һәр телнең төш һәм периферик берәмлекләре була. Төш берәмлекләр – барлык диалектлар өчен дә мәҗбүри булган, телнең бөтенлеген тәшкил иткән төп берәмлекләр. Шул ук вакытта тел системасында диалекттан диалектка аерылып торган периферик берәмлекләр дә урын ала. Аларның барлыкка килүе төрле факторлар белән бәйләнгән. Биредә, аерым җирлектә яшәү шартларын (мәсәлән, Идел буенда һәм Себердә табигать, флора һәм фауна берникадәр дәрәҗәдә аерыла, бу үз чиратында кешеләрнең тормыш-көнкүрешендә дә чагылыш таба), төрле тел группаларына караган күрше халыкларның йогынтысын, тарихи үсеш үзенчәлекләрен һ.б. атап китәргә мөмкин. Шул рәвешле, периферик берәмлекләр телнең килеп чыгышын билгеләүдә мөһим роль уйнамыйлар һәм тел берәмлекләренең гомуми санына мөнәсәбәттә ул кадәр күпсанлы түгелләр.

Урта гасырларда ук формалаша башлаган татар әдәби теле җирле диалектларны һәм сөйләшләрне үзара бәйләп торучы бер бөҗра ролен үти. Мәгълүм булганча, ул милли телнең диалектлардан өстен, нормага салынган, күптөрле функцияләр башкара торган, стилистик яктан дифференциацияләнгән һәм югары социаль дәрәҗәгә ия булган ассистемасын тәшкил итә. Диалектлардан аермалы буларак, әдәби тел һәм язма, һәм сөйләмә формаларда хәрәкәт итә. Ул – гомумхалык теленең иң югары үсешкә ирешкән, аңлы рәвештә эшкәртелә торган, иҗтимагый тормышның мәдәният, фән, сәясәт, сәнгать, эш башкару, канун чыгару өлкәләрендә, милләтара һәм рәсми булмаган аралашуда һәм, әлбәттә, мәгариф системасында кулланыла торган формасы. Әдәби тел татар халкының барлык вәкилләре өчен мәҗбүри һәм билгеле бер диалектка гына карамый, ул гомумхалык казанышы булып тора.

Биредә тел белгече өчен гадәти булган әйберләрне янәдән ассызыклап үтү мөһим, чөнки бүгенге көндә милли тел, әдәби тел,

диалектлар теле кебек төшенчәләр хәтта белгечләр аңында да шактый буталчык халәттә яшиләр һәм үзләренең чын мәгънәләрен югалта баралар.

Үз вакытында төрки телләр белгече А.Н. Самойлович, тел материалларына таянып, «Ука-Идел-Кама-Тубыл мәдәни-географик районы»ның булганлыгы турында гипотеза тәкъдим итә [Самойлович, 1927, с. 210–217]. Галимнең позициясе татар диалектологларының эзләнүләре белән дә ныгытыла. Нәтиҗәдә, 1930 еллар ахырында Себер татарларының тел ягыннан Идел-Урал татарлары белән бергә татар теленең көнчыгыш диалекты буларак бердәм диалект системасына керүе турындагы нигезләмә формалаштырыла. Алга таба Д.Г. Тумашева хезмәтләрендә әлеге проблема тагын да җентекле эшләнә. Аерым алганда, ул Себер татарлары теле турында бары тик тарихи аспектта гына фикер йөртергә мөмкин булуын, ә Себер татарлары таралып урнашкан территорияләрдә формалашкан тубыл-иртеш, бараба һәм том диалектларының хәзерге торышта татар теле диалектлары системасында аның көнчыгыш яки Себер диалектлары буларак каралырга тиешлеген ассызыклый [Тумашева, 1977, с. 275].

Бу мәгълүматларны безнең тарафтан Көнбатыш Себернең төрки-татар топонимик лексикасы өлкәсендә алып барылган тикшеренүләр дә раслый. 3000 нән артык топонимны һәм 1000 географик терминны өйрәнеп, без, регион һәртөрле кардәш һәм кардәш булмаган телләрнең үзара керешү зонасы булса да, җирле топонимик фондның нигезен төрки-татар асыллы географик терминнар тәшкил итә, ә төп нигез терминнар татар теленең барлык диалектлары өчен уртак булып торалар, дигән фикергә килдек. Җирле татар асыллы географик терминологиянең төш өлешен татар халкының барлык вәкилләренә дә аңлаешлы булган һәм алар яшәгән барлык ареалларда да таралган *йылга, күл, кыр, йул, басу, бүләк, сийарат, болын, кичү, куак, авыл, карагай, имәнлек, кайынлык* кебек лексемалар формалаштыра.

Шул рәвешле, татар теленең Себер диалектларына һәм экспедиция материалларына кыскача анализ ясау гына да аларның үсешендә татар әдәби теленең зур роль уйнаганлыгын күрсәтә. Аларербөтен буларак нәкъ менә татар милләте һәм татар милли әдәби теле формалашкан чорда үзара консолидацияләнәләр [Тумашева, 1977, с. 266]. Күпсанлы периферик берәмлекләр булуга карамастан, җирле сөйләшләрнең төш берәмлекләре башка диалектлар һәм әдәби тел белән тотрыклы уртаклык күрсәтәләр.

1870 еллар башында, ягъни татарлар милләт буларак яңа оеша башлаган чорда, В.В. Радлов тарафыннан тупланган һәм Себер татарлары сөйләшләренең үрнәкләре чагылыш тапкан текстлардан Идел-Урал һәм Себер татарлары арасында тел аерымлыкларының ул вакытта ук инде зур урын алып тормаганлыгы күренә. Бу татар халкының әлеге ике этнографик төркеме вәкилләре арасындагы багланышларның күптәннән, милләткә кадәрге чорда ук башланганлыгын дәлилли. Әлеге фикерне тарихчылар һәм этнологлар да яклый [Исхаков, 2006, с. 19].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, үзләренең билгеле бер үсеш этабында Себер татарлары диалектлары татар милли теле составына кергәннәр. Аның әдәби формасы әлеге этник төркемгә бүген дә хезмәт итә. Татар теленең сөйләмә һәм әдәби формаларының үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә хәзер дә Себер татарлары диалектлары милли тел белән якыная бара һәм аларның икесенә дә хас уртак сыйфатлар барлыкка килү туктамый.

**Әдәбият**

*Атнометов Н.Б.* Букварь татарского и арабского письма с приложением слов со знаками, показывающими их выговор. Сочинённый в Тобольском главном народном училище бухарцом Ният Бакою Атнометевым, под руководством татарскаго языка учителя, соборнаго священника Иосифа Гиганова. СПб.: При Императорской Академии наук, 1802. 66 с.

*Гиганов И.* Грамматика татарского языка (сочинённая в Тобольской главной школе учителем татарскаго языка, Софийского собора священником Иосифом Гигановым и юртовскими муллами освидетельствованная). СПб.: При Императорской Академии наук, 1801. 187 с.

*Исхаков Д.М.* Введение в историю Сибирского ханства. Очерки. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2006. 196 с.

*Самойлович А.Н.* К истории культурных и этнических отношений в волжско-уральском крае // Новый Восток, 1927. № 18. С. 210–217.

*Тумашева Д.Г.* Диалекты сибирских татар: Опыт сравнительного исследования. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. 294 с.

***Хисамов Олег Ришатович,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фән эшләре буенча директор урынбасары, ареаль лингвистика бүлеге мөдире*

УДК 811.512.145

***Р.Ф. Мирхәев***

# XIX ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ – XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНЕҢ ФУНКЦИОНАЛЬ СТИЛЬЛӘРЕ

Статья посвящена изучению состояния функциональных стилей татарского литературного языка во второй половине XIX – начале XX века. Автором дается оценка тенденциям, определившим их развитие в указанный период. До настоящего времени они рассматривались в работах по истории татарского литературного языка, в которых основное внимание уделялось реконструкции эволюции письменных норм и традиций. При этом сами функциональные стили в диахроническом аспекте не становились объектами научных исследований.

**Ключевые слова:** татарский литературный язык, функциональные стили, стиль художественной литературы, публицистический стиль, научный стиль, эпистолярный стиль.

The article is devoted to the study of the state of functional styles of the Tatar literary language in the second half of the XIX – early XX century. The author gives an assessment of the trends that determined their development in the specified period. Until now, they have been considered in works on the history of the Tatar literary language, in which the main attention was paid to the reconstruction of the evolution of written norms and traditions. At the same time, the functional styles themselves in the diachronic aspect did not become objects of scientific research.

**Key words:** Tatar literary language, functional styles, style of fiction, journalistic style, scientific style, epistolary style.

XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы татар әдәби теле һәм аның функциональ стильләре тарихында яңарыш һәм үзгәрешләргә бай, гаять үзенчәлекле, катлаулы чорларның берсе булып тора. Әлеге вакыт аралыгында җәмгыятьтә барган иҗтимагый, социаль, икътисади һәм мәдәни процесслар аның социаль яшәеш даирәләренең киңәюенә, функциональ кулланылыш сфераларының артуына, структур планда яңа тел формалары белән баюына китерә. Болар барысы да үз чиратында функциональ стильләрнең алга таба үсешенә йогынты ясый. Моңа кадәр, нигездә, поэтик һәм дини-дидактик әсәрләр кысаларында хәрәкәт иткән иске татар язма әдәби теле тикшерелә торган чорда яңа әдәби, публицистик һәм фәнни жанрлар белән тулылана. В.Х. Хаков тарафыннан әлеге чор түбәндәгечә бәяләнә: «XIX йөздә һәм XX йөз башында милли әдәби тел үзенең иҗтимагый функциясе ягыннан киң сферага җәелә, җәмгыятьтә кешеләрнең аралашуында әһәмиятле роль уйный. Бу, беренче нәүбәттә, әдәби телнең функциональ стильләрендә ачык чагылыш таба. Элекке язу һәм сөйләү теле традицияләрен саклаган хәлдә, милли әдәби тел нормалары формалашкан чорда киң күләмдә стилистик

дифференциация башлана һәм функциональ стильләр моңа кадәр күрелмәгәнчә зур үсеш алалар. Аларда нормаларның тотрыклануы, специфик үзенчәлекләрнең артуы һәм төрле алымнарның киң кулланылуы күзәтелә» [Хаков, 2003, б. 86].

XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы татар әдәби теле тарихының иң җентекле өйрәнелгән чоры булып тора. Ул бу өлкәдә тикшеренүләр алып барган галимнәрнең (Л. Җәләй, В.Х. Хаков, Х.Р. Курбатов, И.Б. Бәширова һ.б.ның) күпсанлы хезмәтләрендә яктыртыла. Алардан күренгәнчә, тикшерелә торган чорда татар әдәби теленең табигатен билгеләгән стилистик күренешләр, нигездә, язма нормалар һәм традицияләрне барлау, аерым шагыйрьләр һәм язучылар әсәрләренең тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәнү кысаларында каралалар. Шуның белән бергә функциональ стильләрне, аларның формалашу һәм үсеш тарихын, аерым тарихи чорлардагы торышын тикшерүгә багышланган махсус хезмәтләр юк дәрәҗәсендә. Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, мәкалә кысаларында XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында татар әдәби теле хәрәкәт иткән функциональ стильләргә хас булган гомуми тенденцияләрне яктырту максат итеп куелды.

***Матур әдәбият стиле.*** XIX гасырга кадәр татар теленең әлеге функциональ төре, нигездә, шигъри жанрларда чагылыш тапкан. Мәгълүм булганча, язма әдәбиятның иң югары формасы саналган иске татар поэзиясе, үзенең барлыкка килү вакытыннан башлап, суфичылык фәлсәфәсе белән тыгыз мөнәсәбәттә торган. Әлеге дини-фәлсәфи агым аны гасырлар дәвамында күпсанлы шигъри образлар, символлар, метафоралар белән баетып килгән. Алар аша шагыйрьләр кеше җаны белән Илаһи башлангыч арасындагы бәйләнешне ачып бирергә омтылганнар [Сайфуллина, Гумеров, 2013, с. 211]. Бу традиция билгеле бер дәрәҗәдә XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы татар шагыйрьләре тарафыннан да дәвам иттерелә.

Шигъри әсәрләр, нигездә, җәмгыятьнең югары катлау вәкилләренә, аерым алганда, галимнәргә, руханиларга һәм шагыйрьләрнең үзләренә атап язылган. Аларның күбесе Урта Азия мәдрәсәләрендә һәм Көнчыгыш илләренең уку йортларында белем алганнар. Нәтиҗәдә, гарәп һәм фарсы телләрен камил белгәннәр.

Мәгълүм булганча, Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, татар халкы дәвамлы рәвештә христианлаштырылуга дучар ителгән. Шуңа да карамастан, ислам татарлар тормышында үзенең позицияләрен саклап кала алган. Моңа күп яктан суфи шагыйрьләрнең аны йөрәктән килгән «күңел дине» буларак аңлатулары да ярдәм иткән.

Галимнәр фикеренчә, суфичылык татар шигъриятен формалаштыруда мөһим роль уйнаган. Соңгысы исә үз чиратында дини, фәлсәфи һәм суфичылык карашларын пропагандалау өчен үзенә күрә бер мәйдан булып торган. Үзләренең әсәрләрендә Әбелмәних Каргалый (1782 –1826), Һибәтулла Салихов (1794 –1867), Шәмсетдин Зәки

(1825–1865), Габделҗаббар Кандалый (1797–1860), Гали Чокрый (1826–1889) һ.б. Аллага һәм якын кешеңә мәхәббәт турында язганнар, үзара туганлыкка һәм ярдәмләшүгә өндәгәннәр.

Бу өлкәдәге лингвистик тикшеренүләр иске татар поэзиясе теленең бертөрле генә булмавын күрсәтә. Аерым әсәрләр традицион тел чараларына бай булса, башкаларында гомумхалык сөйләм теле берәмлекләре өстенлек итә. Әлеге күренеш, беренче чиратта, әсәрләрнең жанр һәм стиль үзенчәлекләре, авторның карашлары һәм алган белеме белән аңлатыла. Үз вакытында катнаш телдә язу төрле өлкәләрдә яшәгән төрки шагыйрьләр һәм шигъри әсәрләрне күчереп язучылар тарафыннан традиция дәрәҗәсенә күтәрелә [Юсупов, 2006, с. 7]. Гомумиләштереп әйткәндә, XIX гасыр татар поэзиясе телендә иске татар язма әдәби теленең нигезен тәшкил иткән традицион төрки-татар берәмлекләре стилистик максатларда кулланылган гарәп-фарсы алынмалары белән керешеп китәләр [Юсупов, 2006, с. 166; Хаков, 1993, б. 229 –243]. Мәсәлән:

*Хәмәл туғды, бәһар улды,*
*Ләйәли чөн нәһар улды,*
*Көнә-көн мәстанәр улды,*
*Һәммә әқwән әҗәр баздыр.*

[Гайнуллин, 1968, б. 227]

Әйтергә кирәк, бу тенденция күпчелек шагыйрьләрнең иҗатында XX гасыр башына кадәр күзәтелә.

Мәгълүм булганча, XIX гасырда татар җәмгыятендә мәгърифәтчелек идеяләре тарала башлый, демократик һәм либераль агымнар формалаша. Әгәр баштарак мәгърифәтчеләр фәлсәфи мәсьәләләр, фән һәм мәгърифәтне пропагандалау белән генә чикләнгән булсалар, соңрак аларның эшчәнлеге татар халкы, аның мәдәнияте һәм теле тарихында тирән эз калдырган яңа әдәби агым булып үсеп китә [Татар әдәбияты тарихы, 1985, б. 212]. XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында татар әдәбиятында Европа культурасы йогынтысы астында яңа юнәлеш формалаша. Аның вәкилләре үзләренең әсәрләрендә шул чор татар җәмгыяте өчен актуаль булган милләтне агарту, аны Урта гасырлар караңгылыгыннан чыгару, башка мәдәни халыклар белән бер дәрәҗәгә күтәрү кебек мәсьәләләрне күтәреп чыгалар. Мәсәлән, 1886 елда үзендә рационализм, сентиментализм һәм мәгърифәтчелек реализмы идеяләрен берләштергән беренче татар романы – М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәре дөнья күрә. Берникадәр вакыттан укучы игътибарына Европа әдәбияты үрнәгендә язылган башка әсәрләр – З. Бигиевнең «Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә» (1886) һәм «Гөнаһе кәбаир» (1890) детектив романнары, Р. Фәхретдиннең «Сәлимә яки гыйффәт» (1899) хикәясе белән «Әсма яки гамәл вә җәза» (1903) повесте тәкъдим ителә. Әлеге әсәрләр белән мәгърифәтче язучылар татар әдәбияты тарихында яңа дәверне башлап җибәрәләр [Татар әдәбияты тарихы, 1985, б. 291].

Фәнни тикшеренүләр татар мәгърифәтчелек прозасы теленең бу чор татар поэзиясе, дини-дидактик, фәлсәфи һәм тарихи әдәбият теленнән беркадәр дәрәҗәдә аерылып торганлыгын күрсәтә. Күрсәтелгән әсәрләрдә иске татар язма әдәби теле өчен хас булган традицион үзенчәлекләр һәм халыкчан сөйләмә формалар белән бергә госманлы төрек берәмлекләренең дә күп кулланылуы күзәтелә. Мәсәлән: *Русийә уртасында Идел нәһерендән озаķ дәгел бер татар аwылы мәүҗүддер. Ķарйәнең әһалисе ике йөз әв ķадәр улыб, адыны фаш итмәкдән чәкенейурыз, анҗаķ хикәйәмезе йиңел анлатмаķ ичүн адыны Нун хәрфейлә ишарәт идәмез. Нун ķарйәсенең ханәләре ғади ханәләр кеби ағачдан wә башлары бәғзән саламдан бәғзән ағачдан йасалмышдыр. Нун аwылында ике мәсҗед вар. Бер урамлы аwыл булыб, урамы озын wә киңдер. Урамы узайыб ķыйбла тарафындағы очында борылыб, суға йул чыķадыр* [Акъегет, 1886, б. 2].

Алга таба проза теле гомумхалык сөйләм теленә якыная. Болар барысы да мәгърифәтче язучылар татар әдәбияты белән бергә татар әдәби теле үсеше тарихында да яңа дәверне башлап җибәргән дип әйтергә тулы нигез бирә.

Мәгърифәтче язучыларның әсәрләре стилистик яссылыкта да уникаль күренеш тәшкил итәләр. Аерым алганда, аларда матур әдәбият стиле публицистик, фәнни һәм дини-дидактик стильләр белән бергә керешеп китә. Мәсәлән, М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында автор чынбарлык күренешләрен һәм вакыйгаларны сурәтләгәндә, тормыш-көнкүреш, мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләләре белән генә чикләнеп калмыйча, татар тормышына XIX гасыр алып килгән үзгәрешләргә һәм яңалыкларга мөнәсәбәтен дә белдерә. Бу – әсәрнең эчтәлегендә дә, автор һәм персонажлар сөйләменең бирелешендә дә күренә. Иҗтимагый һәм мәдәни тормышка кагылышлы мәсьәләләр әсәрдә публицистик стильдә тасвирлана. Үз вакытында тел галиме В.Х. Хаков билгеләп үткәнчә, «...вакыйга һәм күренешләрне тулы сурәтләргә омтылыш, портрет, персонаж сөйләмен бирүдәге яңалыклар, матур әдәбият һәм публицистика әсәрләре теленә хас үзенчәлекләрнең аралашып килүе М. Акъегеткә хас язу алымнарын тәшкил итә» [Хаков, 1993, б. 247–248].

Тикшерелә торган чорда матур әдәбият стиленә хас үзенчәлекләр поэзия һәм проза үрнәкләреннән тыш драма әсәрләрендә дә чагылыш таба. Мәгълүм булганча, татар драматургиясенең беренче үрнәкләре XIX гасырның соңгы чирегенә карый. 1887 елда Г. Ильяси тарафыннан «Бичара кыз» драмасы язылса, 1888 елда Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» әсәре дөнья күрә. Аларның нигезенә дә мәгърифәтчелек идеяләре салына [Гайнуллин, 1983, с. 240–241]. Алга таба татар драматургиясенең беренче яралгылары Г. Камал, Г. Исхакый һ.б.ның пьесаларында үстерелә.

Башка әдәби жанрлардан аермалы буларак, драма әсәрләрендә төрле социаль катлау вәкилләренең сөйләм үзенчәлекләре аеруча ачык чагылыш таба, ягьни аларның теле гомумхалык сөйләм теленә

якын булуы белән характерлана. Шуның белән бергә биредә иске татар язма әдәби теле берәмлекләре дә урын ала [Хаков, 1993, б. 251]. Мәсәлән:

*Фәрихә. Йә, сиңа әйтәм, йаучы килсә, ни әйтим?*

*Биктимер. Ни әйтәсең килмәгән йаучыга...*

*Фәрихә. Фатыйма, Сәхибә әбине чакыра барганда, Җантимерләрнең капкасы төбендә асраулары белән сөйләшкән. «Бүген сезгә йаучы җибәрәләр», дигән. Шуңа күрә әйтәм, Син базарга чыкканда килсә, мин ни әйтергә дә белмим дип әйтүем.*

*Биктимер. Ни әйтерсең, тәвәккәлләп бирербез.*

*Фәрихә. Соң, сиңа әйтәм, Маһитап йаратырмы икән? Уртарак, диләр.*

*Биктимер. Тагы кемгә бирмәкче буласың?*

*Фәрихә. Соң, миңа Маһитап шулай дип әйтсә, дип әйтәм.*

*Биктимер. Мин риза булгач, әйтмәс!* [Гайнуллин, 1968, б. 544].

Гомумән алганда, тикшерелә торган чорда матур әдәбият теле һәм стиле өлкәсендә барган үзгәрешләр, Х.Р. Курбатов сүзләре белән әйткәндә, түбәндәгеләрдә чагылыш таба: «XIX йөз поэзиясе үзенең образлы фикер йөртү рәвеше, стиль алымнары һәм шигъри формалары ягыннан Урта гасыр белән турыдан-туры бәйләнештә. Әмма телдә зур кузгалыш башлана: бер төркем язучылар һәм шагыйрьләр төрки әдәби телне тагын да катлауландырып (барыннан да бигрәк төрек теленә якынлаштыра төшеп) иҗат итсәләр (Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Шәмсетдин Зәки, Гали Чокрый, Муса Акъегет, Заһир Бигиев), икенчеләре, киресенчә, халыкның җанлы сөйләмен шигърият дәрәҗәсенә күтәрергә тырышалар (Габделҗаббар Кандалый, Әхмәт Курмаши, Габдрахман Ильяси, Фатих Халиди, Каюм Насыйри, Риза Фәхретдинов, Фатих Кәрими һ.б.). Бу соңгыларының поэмаларында һәм шигырьләрендә иске әдәби формалар, традицион стилистик алымнар сүз һәм грамматик формаларның яңача кулланылышы белән бергә үрелеп бара. XX йөз башында Тукай һәм башка язучыларның бүгенге әдәби телне барлыкка китерүенә шул рәвешчә юл салына» [Курбатов, 1984, б. 5].

***Публицистик стиль.*** Галимнәр фикеренчә, «татар әдәби телендә публицистик стильнең беренче яралгылары бик күптәннән – XV–XVI йөзләрдә, хәтта аннан да элегрәк башлана» [Хаков, 2003, б. 12]. XIX гасырга кадәр ул, нигездә, сәяхәтнамә жанрында хәрәкәт итә. Аның барлыкка килүе билгеле бер иҗтимагый (исламның изге урыннарына хаҗ кылу) һәм сәяси (Көнчыгыш илләре белән сәүдә һәм дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыру) факторлар белән бәйләнгән. Иске татар телендәге иң борынгы сәяхәтнамә тексты 1699 ел белән даталанган. Аның авторы Мортаза әс-Симети Гарәбстанга хаҗ сәфәре кылган вакытта алган тәэсирләре белән уртаклаша, мөселман пәйгамбәрләренең, әүлия һәм шәехләрнең каберләрен, изге урыннарны тасвирлый [Фәхреддин Ризаэддин, 2006, б. 38–39]. Татар телендә төзелгән юлъязма жанрының иң күренекле үрнәкләреннән тагын

берсе – Мөхәммәдәмин сәяхәтнамәсе (XVIII гасырның соңгы чирегенә карый. Биредә дә автор үзенең хаҗ сәфәрен тасвирлый [Алеева, 1988; Алеева, 1993, с. 6–7]. Алга таба әлеге әсәрләрдә салынган традицияләр «Исмәгыйль ага сәяхәте» (XVIII гасыр), Ф. Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902 ел) һәм «Кырымга сәяхәт» (1904 ел), З. Бигиевнең «Мавәраэннәһердә сәяхәт» (1908 ел) сәяхәтнамәләрендә дәвам иттерелә. Әлеге әсәрләрнең тел үзенчәлекләренә килгәндә, бу өлкәдәге тикшеренүләр аларның иске татар язма әдәби телендә язылганлыгын күрсәтәләр. Мәсәлән: *Бундан ун-унбиш сәнә мөкаддәм Бохара, Сәмәрканд, гомумән, Урта Асийа йуллары сусыз чүллек иде, у wакыт у тарафлары зийарәт итмәк бик агыр, гайәт мөшкел иде. Бу көндә исә Озын Ададан узанмыш тимер йул wасытасыйла у тарафларда сәйәхәт йиңел һәм рәхәт улды. Ростовдан Дон нәһрейлә парохода бенеб, мөнтәһаи Донда улан Калач нам мәнзилә йулландым. Йалңыз идем. Һәм сәфәр бер аркадашым йук иде. Видаг сәламләре соңында, гүйә йулчыларың калебләренә фирак әләме истиля итмеш кеби, пароходымызда бер сөкүн пәйда улды, йулчыларда сәс йук, сүз йук. Йалңыз пароходың бухары су үзәренә шиддәтлә орыр, чарыклары йулчылары гүйә: «Хәрәкәтдә без, әфәнделәр! Иншалла, һәр береңезе сәламәтлекдә максудыңыза исаль идәрем. Хатырларыңыз рәхәт улсын!» – аwазыйла калебләрене тәсәллийә идәр иде* [Бигиев, 1908, б. 1–2].

Тикшерелә торган чорда публицистик стильгә хас үзенчәлекләр, алда әйтеп үтелгәнчә, мәгърифәтче язучыларның әдәби әсәрләрендә дә урын алалар. Моннан тыш ул XX гасыр башында чыга башлаган татар вакытлы матбугаты битләрендә үстерелә. Мәгълүм булганча, 1905 елның 2 сентябрендә Санкт-Петербургта «Нур» газетасының беренче номеры дөнья күрә. Әлеге вакыйга белән татарларның иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында яңа этап башлана: татар телендәге газеталар Россия империясенең татарлар күпләп яшәгән башка шәһәрләрендә дә чыга башлый [Гайнуллин, 1983, с. 12–89]. Аларның тел үзенчәлекләренә килгәндә, галимнәр XX гасыр башы вакытлы матбугаты битләрендә шул чорның гомумхалык сөйләм теле формалары белән баетылган иске татар язма әдәби теле чагылыш таба, дигән фикердә торалар [Миннуллин, 2012, с. 273–289].

***Фәнни стиль.*** Татар теленең фәнни өлкәдә кулланылышы күп гасырлык традициягә ия. Ул үзенең тамырлары белән Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларына барып тоташа [Хаков, 1972, б. 125; Хаков, 1999, б. 255; Хаков, 2003, б. 13]. Тикшерелә торган чорга кадәр татарларда фәнни әдәбиятның нигезен тарихи һәм дини-дидактик характердагы әсәрләр тәшкил иткән. XIX гасырда татарларның тарихы, мәдәнияте һәм теле буенча хезмәтләр дөнья күрә башлый. Бу да үз чиратында фәнни стильнең үсешенә зур йогынты ясый.

Фәнни хезмәтләр гарәп һәм фарсы телләре белән беррәттән, берникадәр дәрәҗәдә гомумхалык сөйләм теленнән аерылып торган иске

татар язма әдәби телендә иҗат ителгәннәр. Әлеге өлкәгә хас булган гомуми тенденцияләрне В.Х. Хаков түбәндәгечә билгели: «Татар әдәби телендә элек-электән Болгар чорыннан ук XIX гасырга кадәр берничә юнәлеш сакланып килә. Аларның берсе тулысынча гарәп, фарсы телләрендә язылган әсәрләрне эченә ала. Бу традиция Г. Утыз Имәни, Г. Курсави әсәрләрендә, XIX гасырга чыккач, Ш. Мәрҗани әсәрләрендә ачык күренә. Икенче юнәлеш – гарәп-фарсы сүзләре белән чуарланып язылган Идел буе төрки әдәби телендәге фәнни әсәрләр. Боларында исә һәр чорның үз язма китап теле чагыла» [Хаков, 2003, б. 179–180].

Әйтергә кирәк, соңгы юнәлеш XX гасыр башларына кадәр дәвам иттерелә. Аның үрнәкләрен бу чорда язылган сәяхәтнамәләрнең фәнни стиль катламында да күзәтергә мөмкин. Мәсәлән: *9 нчы гасыр миләди ахырында, хәлифәте Габбасийә заманында, 287 сәнә һиҗридә Бохарада Саманиләр хөкүмәте ибтида улынды. 145 сәнә имтидад итмеш хөкүмәтләре дәwерендә Мавәра ән-нәһер тәрәққый wә қуәт кәсеб итмеш иде. Фетнәләр мөнқатыйг улды. Низам мәйдан тотды. Саманиләр дәүләтенең мөәссисе Исмагыйль бин Әхмәд заманларында, 892–907 милади сәнәләр имтидадында, Бохара иң бөйек қуәтенә наил улды. Шимальдә – сахралара, шәрықда – Тянь-Шань тагларына, җәнүбдә – Фарс көрфезенә, гаребдә Багдада қадәр мөмтәд иде* [Бигиев, 1908, б. 4].

Алга таба, дөньяви мәктәпләр ачыла башлагач, җәмгыятьтә халыкның киң катлаулары өчен аңлаешлы телдә язылган фәнни хезмәтләргә, дәреслекләргә һәм кулланмаларга ихтыяҗ туа. В.Х. Хаков билгеләп үткәнчә, «XIX йөз ахырында фәнни стиль зур үзгәрешләр кичерә: нәкъ шушы дәвердә ул функциональ юнәлештә үсеп китә һәм халык теленә нигезләнә башлый. Бу тенденция бигрәк тә XX йөз башында язылган фәнни әсәрләрдә киң чагылыш таба. Яңа чорда аерым фәннәр буенча чыгарылган хезмәтләр тагы да арта, күп кенә дөньяви мәктәпләр ачыла, аларда фән укыту беренче планга куела. Табигый ки, заман таләпләренә җавап бирерлек итеп, мәктәпләр өчен төрле фәннәрдән дәреслекләр булдыру, кулланмалар төзү көн тәртибенә килеп баса. Шулай итеп, фәнни әдәбиятның киң үсеш алуы һәм аның стиле формалашу XIX йөз икенче яртысында XX йөз башында татар мәгърифәтчеләренең эшчәнлеге һәм шул чордагы иҗтимагый-политик вакыйгалар белән бәйләнгән» [Хаков, 1972, б. 126].

Әлеге юнәлештә татар халкының күренекле мәгърифәтчесе К. Насыйриның эшчәнлеген билгеләп үтми мөмкин түгел. Аерым алганда, ул «гыйльми хезмәтләр һәм дәреслекләр язуга зур игътибар биреп, бердәм әдәби тел нормаларын эшкәртүне язма тел белән сөйләү телен якынайту юнәлешендә алып бара, матур әдәбият телен (бигрәк тә проза теле стилен), әдәби телнең функциональ стильләрен (фәнни һәм публицистик әдәбият телен) үстерүдә, аларны төрле чаралар белән баетуда, математика, география, лингвистика, биология,

медицина һ.б. фәннәрдәге терминнарны һәм атамаларны тәртипкә китерүдә киң колачлы эш башкара» [Хаков, 2003, б. 182].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, тикшерелә торган чорда җәмгыятьтә барган үзгәрешләр үз чиратында фәнни стильнең үсешендә дә чагылыш таба. Аерым алганда, фәнни хезмәтләр киң җәмәгатьчелеккә аңлаешлы телдә языла башлыйлар. Мәсәлән: *Йир йөзен күрсәтә торған кәғазьне харита диләр. Йир йөзе биш қыйтғаға бүленәдер. Ул биш қыйтға ошбулардыр. Аврупа, Азийә, Афстралийә, Африка, Америка қыйтғаларыдыр. Wә бу биш қыйтға биш харита итеб йасаладыр. Бөтен йир йөзен күрсәтә торған хританы харитайи ғомумийә дирләр. Йирнең бер өлешен, йәки бер мәмләкәтне, йәки бер вилайәтне күрсәтә торған хаританы харитайи хосусийә дирләр. Имди йир йөзенең дүрт өлешендән бер өлеше қоры йирләрдер wә қалған өч өлеше диңезләр wә сулардыр* [Насыйри, 1890, б. 8].

***Рәсми эш стиле.*** Мәгълүм булганча, әлеге стильнең барлыкка килүе турыдан-туры сәяси һәм социаль факторларга бәйле. Моның өчен, беренче чиратта, дәүләтчелек һәм административ, хокукый, икътисади мөнәсәбәтләрнең булуы зарур. Әлеге яктан караганда, татар теле уникаль күренеш тәшкил итә: XVI гасырда халкы үзенең дәүләтен югалтуга карамастан, ул өч гасырдан артык Россия империясенең Көнчыгыш илләре белән дипломатик һәм сәүдә мөнәсәбәтләрендә рәсми тел буларак хезмәт итә. XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында аның эш кәгазьләре теле буларак кулланылыш даирәсе тагын да киңәя һәм ул татар телендәге рәсми документларның яңа төрләре барлыкка килү белән билгеләнә. Аерым алганда, бу чорда «татарларда промышленность һәм сәүдә капиталының үсүе, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең яңа баскычка күтәрелүе канцелярия-идарә эшендә дә үзенең чагылышын таба» [Хаков, 1972, б. 168].

Галимнәр фикеренчә, иске татар язма әдәби телендә төзелгән эш кәгазьләре үзләренең структур һәм тел үзенчәлекләре буенча бер рәткә тезелеп, аның гомуми үсеш линиясен чагылдыралар [Хисамова, 1999, с. 7 –9].

***Хатлар стиле.*** XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы татар җәмгыятендә барган үзгәрешләр берникадәр дәрәҗәдә хатлар стиленә дә тәэсир иткән. Ул иң элек аларны язуны тәртипкә салу омтылышларында чагылыш таба. Әлеге чорда хатларның үзенчәлекләрен ачып бирүгә багышланган махсус китаплар дөнья күрә башлый [Авхадиева, 2007, с. 34–35]. Моны тормыш үзе таләп иткән. Алга таба «мәгърифәтчелек хәрәкәтенең көчәюе, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең үсүе, сәүдә-базар эшләренең киңәюе хатлар өслүбенең киң сферага җәелүенә зур йогынты ясаган. Мәгърифәт, мәдәният, хосусый капитал һәм шәхси милек белән бәйләнешле хатлар моны ачык күрсәтәләр» [Хаков, 1999, б. 279].

Мәгълүм булганча, хатлар үзләренең эчтәлекләре һәм төзелешләре ягыннан ике төркемгә – рәсми һәм шәхси хатларга бүленәләр.

«Рәсми хатлар төрле учреждениеләр, оешмалар исеменә языла. Аларда рәсмилек, канцелярия документларына хас катгыйлык кына түгел, бәлки тарихи-публицистик очеркларга хас хикәяләү алымы да зур урын алып тора» [Хаков, 1999, б. 279]. Язма чыганаклардан күренгәнчә, тикшерелә торган чорда татарлар рәсми оешмаларга да хатлар язганнар. Ш. Мәрҗанинең Фәннәр Академиясенә язган хаты моның бер дәлиле булып тора: *«Бу – Болгарның элекке мәликләреннән берсе булырга охшый. Чөнки аларның иң элек мөселман булганнары, Алмасхан Сәлки хан углы, Габбасилардан Моктадир Билләһкә буйсынуны бурыч итеп алып, Габбасиларны баш белеп, акчаларны алар исеменә, хөтбәләрне аларга кылалар иде. Һәр бар эштә дә аларга охшауны үзләренә һөнәр итеп алганнар иде. Хәтта электәге "хан" титулын "әмиргә", ә үз исемен "Алмас"тан "Җәгъфәр"гә алыштырып, "Әл-әмир Җәгъфәр дип исемләнде", ә углына «әмир Әхмәт» дип куйды. Минем фикеремчә, аның нәселе Тимур һөҗүменә кадәр исән иде. Ләкин үзбәкләргә, ягъни Чыңгыз нәселләренә буйсынуда иделәр. Болгар әмирләреннән Тимур тарафыннан үтерелгән әмир Габдулла шуларның соңгысы дип уйлыйм»* [Хаков, 1999, б. 281].

Шәхси хатларга килгәндә, язма чыганаклар XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында аларның түбәндәге төрләре булганлыгын күрсәтә:

1) күренекле шәхесләр арасында язылган хатлар (мәсәлән, Х. Фәезхановның Ш. Мәрҗанигә, К. Насыйриның Н. Катановка, Г. Тукайның Ф. Әмирханга язган хатлары һ.б.);

2) тормыш-көнкүреш, сәүдә эшләре белән бәйләнешле хатлар (сәүдәгәрләр арасындагы язышулар, приказчикның хуҗасына, шәкертнең остазына, остазының шәкертенә язган хатлары һ.б.);

3) туганлык-кардәшлек хатлары (ата-ананың балаларына, баланың туганнарына, туганлык мөнәсәбәтендәге төрле буын кешеләренең үзара бер-берсенә җибәргән хатлары);

4) дуслык хатлары (үзара кардәш булмаган, ләкин бер-берсе белән иң якын самими мөнәсәбәттә торган кешеләрнең хатлары);

5) мәхәббәт хатлары [Хаков, 1999, б. 281–291].

Шәхси хатларның тел-стиль үзенчәлекләренә килгәндә, алар өчен язма әдәби тел берәмлекләренең сөйләмә формалар һәм конструкцияләр, аерым затларның индивидуаль стильләре өчен хас булган үзенчәлекләр белән бергә керешеп китүе хас. Ягъни биредә билгеле бер норма һәм традицияләргә генә ияреп бару күзәтелми. Бу әлеге төр хатларның тиз вакыт эчендә һәм төрле социаль катлам вәкилләре тарафыннан язылуы белән аңлатыла.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы татар әдәби теленең функциональ стильләре сан һәм сыйфат ягыннан мөһим үзгәрешләр кичергән чор булып тора. Иҗтимагый һәм мәдәни тормышта барган үзгәрешләр аларны яңа форма, эчтәлек һәм тел чаралары белән баета. Бу үз чиратында функциональ стильләрнең кулланылыш даирәсен киңәйтә.

## Әдәбият

*Авхадиева А.И.* История изучения эпистолярного стиля в татарском и русском языкознании // Учен. зап. Казан. ун-та. Сер. Гуманит. науки. 2007. Т. 14, кн. 4. С. 32–37.

*Акьегет М.* Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

*Алеева А.Х.* Списки «Мөхәммәд-Амин сәяхәтнамәсе» и живая народная речь в ее языковой структуре // Истоки татарского литературного языка. Казань: ИЯЛИ, 1988. С. 34–44.

*Алеева А.Х.* Путешествие Исмагил ага в Индию (исследование языка татарских путевых записок XVIII в. «Исмагил ага сәяхәтнамәсе»). Казан, 1993. 166 с.

*Бигиев З.* Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр). Казан: Типолитогр. И.В. Ермолаевой, 1908. 108 б.

*Гайнуллин М.Х.* Татар әдәбияты: XIX йөз. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. 690 б.

*Гайнуллин М.* Татарская литература и публицистика начала XX века. Изд. 2-е, доп. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. 352 с.

*Курбатов Х.Р.* Иске татар поэзиясендә тел, стиль, метрика һәм строфика. Казан: Татар. кит. нәшр, 1984. 163 б.

*Миннуллин Б.К.* Татарская газета «Борхане таракки». Лингвистические исследования. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2012. 300 с.

*Насыйри К.* Истиляхаты җәгърафия. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1890. 74 б.

*Сайфуллина Ф.С., Гумеров И.Г.* Творчество Гали Чокрыя: традиции суфийской литературы Востока // Филология и культура. Philology and culture. 2013. № 3 (33). С. 210–214.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 2 т.: XIX йөз татар әдәбияты / баш редколлегия: Н.Г. Юзиев (баш редактор), Я.Г. Абдуллин, Ш.Ш. Абилов, Г.А. Ахунов, М.Г. Гайнуллин һ.б. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 564 б.

*Фәхреддин Ризаэддин.* Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. 360 б.

*Хаков В.Х.* Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. 221 б.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле тарихы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. 323 б.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле (стилистика). Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 304 б.

*Хаков В.Х.* Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 295 б.

*Хисамова Ф.М.* Татарский язык в восточной дипломатии (XVI – нач. XIX в.). Казань: Мастер Лайн, 1999. 408 с.

*Юсупов А.Ф.* Язык произведений Шамсетдина Заки. Морфология. Казань: Казан. гос. ун-т им. В.И. Ульянова-Ленина, 2006. 204 с.

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 81-112

*Х.Х. Кузьмина*

# КОЛ ГАЛИНЕҢ «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ПОЭМАСЫНДА ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘР, МӘКАЛЬ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘРНЕҢ СТИЛИСТИК КУЛЛАНЫЛЫШЫ

В языке письменных памятников часто встречаются устойчивые словосочетания с переносным значением. Они проникают в ткань произведения в готовом виде из живой народной речи и занимают особое место в обогащении стиля произведения. Часто фразеологизмы и метафоры вплетаются в структуру друг друга.

Фразеологические единицы использовались в литературном языке с глубокой древности. Поэма «Кысса-и Йусуф» богата такими устойчивыми словосочетаниями, крылатыми выражениями, афоризмами, пословицами, поговорками. В них отражается многовековой накопленный народом ум, знания, поэтому использование устойчивых словосочетаний повышает убедительность, выразительность, эмоциональность произведения, украшает его язык.

**Кючевые слова:** стилистика, фразеологизмы, пословицы и поговорки, «Кысса-и Йусуф».

In the language of written monuments, stable phrases with a figurative meaning are often found. They penetrate into the fabric of the work in finished form from living folk speech and occupy a special place in enriching the style of the work. Often phraseological units and metaphors are woven into each other’s structure.

Phraseological units have been used in literary language since ancient times. The poem «Kyssa-i Yusuf» is rich in such stable phrases, catchphrases, aphorisms, proverbs, and sayings. They reflect the centuries-old accumulated intelligence and knowledge of the people, therefore the use of such stable phrases increases the persuasiveness, expressiveness, emotionality of the work, and decorates its language.

**Keywords:** stylistics, phraseological units, Turkic proverbs and sayings, «Kyssa-i Yusuf».

Язма истәлекләрнең телендә еш кына күчерелмә мәгънәдәге тотрыклы сүзтезмәләр очрый. Алар әсәр тукымасына әзер килеш халыкның җанлы сөйләм теленнән килеп керәләр һәм стильне баетуда аерым урын билиләр. Фразеологизмнарның нигезендә кайчандыр халыкның җанлы сөйләм телендә актив булган, еш әйтелә торган сүзтезмәләр ята. Еш кына фразеологизм һәм метафоралар бер-берсенең структурасына керешеп китәләр. Бу очракта без метафораның чагыштыру чараларыннан тыш бирелгән, арттырып, күпертелеп күрсәтелгән бизәкле чагыштыру икәнен, ә фразеологизмның үзгәрешкә бирелми торган, җиңел истә калырлык тотрыклы сүзтезмә булуын истә тотарга тиешбез. Еш кына «Фразеологизм метафорага нигезләнә, шуның белән ул чагыштырмаслыкны чагыштыруны күздә тоткан иҗади аң өлкәсенә карый: фразеологизм образы ике семиотик системаның –

мәдәният һәм телнең үзара үтеп керүен тормышка ашыручы үзенчәлекле юл күрсәтүчесе була» [Ларин, 1956, с. 195]. Татар телендә фразеологик берәмлекләрне өйрәнүнең бай тарихы бар [Исәнбәт, 1990; Хәкимҗанов, 2022].

Фразеологик берәмлекләр әдәби телдә бик борынгыдан ук кулланылганнар. «Кыйссаи Йосыф» поэмасы да мондый тотрыклы сүзтезмәләргә, канатлы әйтелмәләргә, афоризмнарга бик бай. Бер компонентлы фигыль белән билгеләнгән тотрыклы сүзтезмәләр аеруча күп кулланыла: *җүмләсиниң хатеринә ғоссә йағды* (барысының хәтеренә кайгы-сагыш яуды); *миһер уды қайнады, бәғри йанды* (күңел уты кайнады, бәгыре янды); *кәндүләриң миһренә уд йақдылар* (үзләренең күңеленә ут яктылар); *Йусуф аны ишитүб, қаныйн ағлар* (Йосыф аны ишетеп, кан белән елый); *бу сөзә Йәһүдәниң җаны күйди* (бу сүзгә Йәһүдәнең җаны көйде); *хәсрәт уды ичин йақар, бәғрин дағлар* (хәсрәт уты эчен яндыра, бәгырен талый) һ.б. Мәсәлән, тотрыклы сүзтезмәләрнең автор тарафыннан никадәр яратып кулланылганын аңлау өчен, текстта очраган берничә мисалны карап үтик.

*Бу сөзә Йәһүдәниң җаны күйди, / миһер уды қайнады, бәғри йанды, / батил ишдән кирү дүнүб, тәүбә қылды: / «Ля-тәктөлү Йусуфа!» – дәйүр имди.* [Кол Гали, 1983, б. 68]. Әлеге строфада биш тотрыклы сүзтезмә кулланылган, шуларның өчесе тасвирлы сурәт барлыкка китерә һәм хәзерге татар телендә дә кулланыла *(җан көю, күңел уты кайнау, бәгырь яну)*. Калган ике фразеологизм *(ишдән кирү дүнү, тәүбә қыл)* сөйләм телендә кулланыла торган тотрыклы сүзтезмәләр булып торалар. Шуны да әйтергә кирәк: *җан* сүзе татар телендә актив тотрыклы берәмлекләр ясый һәм еш кулланыла: «Татар телендә җан төшенчәсенең үзенчәлекле ягы булып, очу сәләте тора: *җан күбәләге; җан канатлану; җан очышы* һ.б.» [Хуснутдинов, 2018, с. 1290]. «Кыйссаи Йосыф» поэмасы телендә дә бу үзенчәлек күзәтелә: *шәриф тәндин айырылды ғәзиз җаны, / Қуша биңзәб ужмах таба учар имди* [Кол Гали, 1983, б. 282].

‘Баш тарту, кире кагу’ мәгънәсендә кулланылган тотрыклы сүзтезмәләр шактый: *көңил биз-* (күңел бизү); *шәфқәт кис-* (шәфкать кисү, мәрхәмәтсезлек күрсәтү); *йүзин дүндүр-* (йөзен кире бору, читкә карау); *шәфқәт уз-* (шәфкать өзү): *кәндүдән сабыры кәтди, бихуд олды* [Кол Гали, 1983, б. 140] – сабыр китү, хушсыз булу сүзтезмәләре; *җүмләләри Йусуфә қәсд қылур имди* [Кол Гали, 1983, б. 70] – явызлык кылу кебек фразеологизмнарда да образлы сурәтлелек өстенлек итә.

Алда саналган фразеологизмнар образлы, сәнгатьле булулары белән аерылып торалар, аларны әдәби телгә, матур әдәбият стиленә хас фразеологизмнар итеп карау дөрес булыр. Шул ук вакытта поэма телендә җанлы сөйләмнән алынган, образлылыгы кимрәк булган, күбесе хәзерге татар телендә дә кулланыла торган фразеологик берәмлекләр еш очрый: *башыйға ғақлы кәлди* (башына акылы килде), *ғақлы шашды* (акылыннан шашты), *әлинә кирди* (кулына керде), *әл тикерде*

(кул тигерде), *ант ичтиләр* (ант эчтеләр), *қулағына кирди* (колагына керде), *үрә дорды* (үрә торды), *улуғлуқа тигинди* (олылыкка тиенде), *башың қалдыр* (башыңны күтәр), *қулақ дутуб* (колак тотып) һ.б. Болар хәзерге көнгә кадәр татар телендә актив кулланыла торган берәмлекләр булып саналалар.

Халыкның гасырлар буе тупланып килгән акылы-зиһене, белеме мәкаль-әйтемнәрдә, канатлы сүзләрдә чагыла, шуңа күрә мондый тәгъбирләрне куллану әсәрнең ышандыру, тәэсир итү көчен, эмоциональлеген артыра, телен бизи.

Әсәрдә берничә урында Коръән аятьләреннән алынган һәм гарәп телендә бирелгән гыйбарәләр дә очрый: *«Мән йәғмәлү йәҗзәбиһи» олды ғәйан, / җәзасини болдачыдур сөчи қыйлан* [Кол Гали, 1983, б. 166]; *«Ля-тәктөлү Йусуфа!» – дәйүр имди* [Кол Гали, 1983, б. 68]; *«Қози әл-умрә әлләзи фиһи тәстәфтийан!» / Йусуф әйдүр: «Хақ қазасы дүнмәз имди»* [Кол Гали, 1983, б. 180]; *«нәфәғәна вә иййакүм» қыйла имди* [Кол Гали, 1983, 294]; *мәшһүрлики «ля сәйф илля Зулфиқәр / ля фәта иллә Ғәли қәррар» имди* [Кол Гали, 1983, б. 46]. Әлеге гыйбарәләр әсәрнең телен югары кимәлгә куялар, әмма автор аларның кайберсен алдагы юлда төрки телгә тәрҗемә итеп бирә.

Поэманың идея-эчтәлеге төп каһарманнарның үз-үзләрен тотышларында, кылган эш-гамәлләрендә чагыла, каһарманнарның сөйләме дә әлеге идеяне ачып бирә. «Кыйссаи Йосыф» әсәре телендә кулланылган мәкаль-әйтемнәр арасында бер-берсенә мәгънәдәш булганнары да очрый, ягъни алар арасында синонимлык мөнәсәбәте күзәтелә. Әлеге мәкаль-әйтемнәрнең составында бик матур метафоралар, сүз уйнатулар, тасвирый сыйфатламалар урын ала. Алар әсәрнең телен баеталар, авторның укучыга җиткерергә теләгән фикерен көчәйтәләр.

«Кыйссаи Йосыф» әсәреннән кала, Урта гасырларда язылган башка бер генә әсәрдә дә шулкадәр күп мәкаль-әйтемнәр кулланылмагандыр. Аларны мәгънәләре буенча берничә төркемгә берләштерергә мөмкин:

1. *Язмышка һәм Аллаһы Тәгаләнең хөкеменә буйсыну, аның кодрәтенә дан җырлау турындагы мәкаль-әйтемнәр.* Әлеге тематик төркемгә караган мәкаль-әйтемнәр әсәрдә күпчелекне тәшкил итә. Ислам дине тәгълиматларына тугры булып яшәү, аның кануннарын үтәү, Аллаһ хөкеменә буйсыну, фәрештәләрне, пәйгамбәрләрне, изгеләрне данлау турындагы мәкальләрнең кайберләре халык теленнән алынган, кайберләре исә, кирәсенчә, Кол Гали каләменнән халык теленә кереп киткән булырга мөмкин. *Мундан соңра қул тәдбири рәуа олмаз* [Кол Гали, 1983, б. 102] – Моннан соң кол чарасы (эшләргә теләгәне) яхшы булмас; *Самәд күрәр, күргәнин һич йаңылмаз, / Самәд бушуб йаздығин қул аңламаз, / Самәд оқы дуқынса, һич оңалмаз, / Аңа қаза оқы дәйүб аңла имди* [Кол Гали, 1983, б. 168] – Аллаһ күрә, күргәнен һич ялгышмас, Аллаһ ачуланып язганын кол аңламас, Аллаһ угы тисә, һич уңа алмас, Аны бәла-каза угы диеп аңла инде; *Қадир мәулүм тәқдирини ким шашыра* [Кол Гали, 1983, б. 92] – Бөек Аллам язганны

кем боза ала; *Аның хөкмин һич кимсәнә йықмаз имди* [Кол Гали, 1983, б. 126] – Аның хөкемен һич кем ега алмас инде; *Нә-ким халиқ хөкем қылса кимдүр йықа?* [Кол Гали, 1983, б. 182] – Әгәр Аллаһ хөкем кыйлса, аны кем ега ала?; *Бу дүнйаның вафасы йук, кәлүр-кидәр, / ахирәткә дурышмақ кәрәк имди* [Кол Гали, 1983, б. 190] – Бу дөньяның борчуы юк, килә-китә, ахирәткә әзерләнергә кирәк инде; *Хәсрәтләри хәсрәтинә ол қушурур* [Кол Гали, 1983, б. 256] – Хәсрәтлене хәсрәтлегә ул кавыштырыр; *Қушурғучи қушырурсә кяңес имди»* [Кол Гали, 1983, б. 94] – кавыштыручыга кавыштыру җиңел инде; *қаза кәлсә, бәсарәт әлдин кидәр, / иляһедин хөкем улса, кимә батар / лябуддер-кем, аның хөкми ула имди* [Кол Гали, 1983, б. 58] – каза килсә, куанычлар кулдан китәр, Илаһыдан хөкем булса, көймә батар, Һичбер шиксез, аның хөкеме була инде.

Кайбер очракта строфа тулысынча гыйбрәтле сүзләрдән генә торырга да мөмкин. Мәсәлән, *Йусуф әйдүр: «Кәчкән сөз кирү кәлмәз, / хак тәқдире бөйлә иркән, кимсә билмәз, / мундан соңра қул тәдбире рәуа улмаз, / Фәрманына риза вирмәк кәрәк имди* [Кол Гали, 1983, б. 102] – Йосыф әйтә: Әйткән сүз кире кайтмас, Хак тәкъдире шулай икән, кем соң белмәс, моннан соң кол гамәле яхшы булмас, Фәрманына риза булу кирәк инде; *Бу тәқдири тәңридән билмиш кәрәк, / хақ хүкминә қуллар разый олмыш кәрәк, / шиддәтинә кәмал риза вирмиш кәрәк, / қазасына дагы тәслим олдым имди»* [Кол Гали, 1983, б. 100] – Бу тәкъдирне тәңредән дип белү кирәк, Аллаһ хөкеменә коллар разый булу кирәк, аның көченә риза булу кирәк, казасын да кабул иттем инде.

Югарыдагы мисалларда строфаларның һәрбер юлы мәгънәле сүз, канатлы гыйбарәләрдән тора. Бу – «Кыйссаи Йосыф» әсәренең үзенчәлеге.

2. *Кайгы-хәсрәт, аерылу газабы турындагы мәкаль-әйтемнәр.* «Кыйссаи Йосыф» әсәренең сюжеты ата белән угылның бер-берсеннән, Йосыф пәйгамбәрнең бала килеш үз гаиләсеннән, яраткан туганнарыннан, торган җиреннән еракларга аерылып китеп, бер-берсен сагынып, юксынып гомер итүләре кыйссасына нигезләнә. Аерылу – төп лейтмотивларның берсе. Һәрбер кеше диярлек үз тормышында аерылу газабын кичерә, шуңа күрә бу хис укучыларга аваздаш, бу хисне укучы үз күңеленә кабул итә һәм йөрәге аша үткәрә ала. Кол Гали укучы күңеленә әнә шул хисне сүз ярдәмендә тасвирлау аша үтеп керә һәм аерылуны, аның аркасында килеп чыккан кайгы-сагышны сурәтләү өчен мәкаль-әйтемнәргә шактый күп урын бирә. Бу очракта ул төрки фольклорга да, гарәп теленнән алынган гыйбарәләргә дә мөрәҗәгать итә. Соңгылары әсәрнең телен әдәби тел югарылыгына күтәрәләр, катлауландыралар: *«Иза җәа'ә әл-кәза, гоми әл-бәсар» / қаза кәлсә, бәсарәт әлдин кидәр* [Кол Гали, 1983, б. 58] – Каза килсә, шатлык кулдан китәр; *Қазасына риза әлин вирди имди* [Кол Гали, 1983, б. 78] – Казасына ризалык кулын бирде инде; *Ғәм-ғоссәдән имди айру қылғыл, диде* [Кол Гали, 1983, б. 198] – Кайгы-сагыштан

инде аерыл, диде; *Хатериндән гәм-госсәсин йусун имди* [Кол Гали, 1983, б. 78] – Хәтереннән кайгы-сагышын юсын инде; *Йимәк-эчмәк қайгуси кәтди имди* [Кол Гали, 1983, б. 150] – Ашау-эчү кайгысы китте инде; *Фирақ отын тәлим йутдым, хәсрәтим чуқ* [Кол Гали, 1983, б. 164] – Аерылу утын күп йоттым, хәсрәтем күп; *Қайгуң үзрә нийәт қыйлдум имди* [Кол Гали, 1983, б. 246] – Кайгың аркасында ният кылдым инде һ.б.

Әлеге әйтемнәр арасында гарәп теленнән алынган мәкаль *(«Иза җа'ә әл-кәза, гоми әл-бәсар»)* текст тукымасына кереп киткән, алдагы юлда аның төрки телдә тәрҗемәсе китерелә. Бу әйтемнәрнең кайберсе татар телендә хәзерге көнгә кадәр кулланыла (*ашау-эчү кайгысы юк, кул биру* һ.б.)

3. *Шәфкатьлелек, тугрылык, яхшылык турындагы мәкальәйтемнәр.* «Кыйссаи Йосыф» поэмасында шәфкатьлелек, тугрылык, яхшылык кебек гомумкешелек кыйммәтләренә дан җырлана. Гомумкешелек кыйммәтләре – теоретик рәвештә сурәтләгән әхлакый кыйммәтләр, аларның эчтәлеге җәмгыятьнең конкрет тарихи үсеш чоры яки конкрет этник традиция белән турыдан-туры бәйле түгел, әмма һәр социомәдәни җирлектә үз конкрет мәгънәсе белән баетыла һәм теләсә кайсы мәдәният төрендә кыйммәт буларак билгеләнә. Кол Гали яшәгән чор (XIII гасыр) – шактый катлаулы, дөньяда монгол яулары һәм шуның белән бәйле халыклар күчеше, чуалышы башланган дәвер. Әсәрдәге вакыйгалар Идел буеннан бик еракта – хәзерге Палестина һәм Израиль, Мисыр дәүләтләре территориясендә бара, аның каһарманнары да – яһүд, гарәп, эфиоп милләте вәкилләре. Ничек кенә булмасын, поэмада кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне гомумкешелек принципларына һәм кыйммәтләренә кору авторның максаты булып та билгеләнә. Бу яктан караганда, әсәрдә яңгыраган төп кыйммәтләрнең берсе – Йосыфны үлемнән алып калган агасы Йәһүдә тарафыннан мәкаль буларак формалаша: *Қәриндәш қәриндәшни һич өлдүрмәз* [Кол Гали, 1983, б. 68] – Карендәш карендәшне һич үтермәс. Шунда ук ни өчен икәнен дә аңлатып күрсәтә: *Йәһүдә әйтүр: «Бу ишиңиз рәуа олмаз, / қәриндәш қәриндәшни һич өлдүрмәз, / муный қылған халиқдан рәхәт болмаз, / йәгрәк олдур, тәүбә қылыб дүнүң имди!* [Кол Гали, 1983, б. 68], ягъни үз туганын үтергән кеше Аллаһтан рәхәт күрмәс дип кисәтә, тәүбә кылып, бу эштән баш тартырга өнди. Монда турыдан-туры борынгы изге китапларга ишарә – Кабил һәм Һабил тарихы төсмерләнә: Кабил һәм Һабил Адәм белән Хәуваның оҗмах бакчасыннан куылганнан соң туган беренче балалары булганнар («Яратылыш китабы» (Книга Бытия)). Тәурат китабында (Библиядә) әйтелгәнчә, ике туган да Аллаһка корбан китерергә карар иткәч, Һабил корбаны кабул ителгән, ә Кабил корбаны кире кагылган. Көнчелек аркасында Кабил үзенең абыйсын үтергән һәм кешелек тарихына беренче үтерүче буларак кереп калган, гаеп ителгән. Шуңа күрә әсәрдә *қардәш хақы, қардәш қаны* гыйбарәләре искиткеч көчле эчтәлеккә ия: *Қәрдәшиңиз қаныны көтәрмәк, дир* [Кол Гали, 1983,

б. 70] – Кардәшегез канын күтәрү дияр; *Ата хақын, қәрдәш миһрин сақлаң имди* [Кол Гали, 1983, б. 71] – Ата хакын, кардәш күңелен саклагыз инде һ.б.

Әсәр телендә *уҗмах – тәмуғ* антонимиясе еш очрый, ул мәкаль-әйтемнәрнең, канатлы сүзләрнең дә нигезенә ята: *Уҗмах вireб, тәмуғ сатун алдыңыз сиз* [Кол Гали, 1983, б. 100] – Оҗмах биреп, тәмуг сатып алдыгыз сез; *Уҗмах вирүб, тәмуғ отыйн сатун алмақ, / Тәмуғ эчрә бақый қалмақ сизләр имди* [Кол Гали, 1983, б. 70].

«Кыйссаи Йосыф» – әдәби телнең гүзәл үрнәге булудан тыш, тирән фәлсәфә салынган әсәр. Тормыш һәм дин фәлсәфәсе юнәлешендә әсәр Н.М. Ногманова, Р.Х. Шәрәфетдинов хезмәтләрендә тикшерелә [Нугманова, 2003; Шаряфетдинов, 2009]. «Төп геройны сурәтләгәндә Кол Гали мөселман Көнчыгышы шигъриятендә таралган яктылык, төс, исләр символикасы, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясыннан чагыштырулар кебек сәнгати чараларны һәм алымнарны куллана», – дип күрсәтә Р.Х. Шәрәфетдинов [Шаряфетдинов, 2009, с. 16]. Әсәрдә тирән фәлсәфи мәгънә салынган юлларны очратабыз: *Һәр киши өз лайықын ишләр имди* [Кол Гали, 1983, б. 98] – Һәр кеше үзенә лаекны эшләр инде; *Атамә нәтә хаин олам имди?!* [Кол Гали, 1983, б. 160] – Атама ничек хаин булам инде?!; *Сәкизинчи – хаин дәгүл, әманәтлү* [Кол Гали, 1983, б. 140] – Сигезенче – хаин түгел, амәнәтле; *Сагдан-сулдан фәрештәләр йазар имди* [Кол Гали, 1983, б. 164] – Уңнан-сулдан фәрештәләр яза инде; *Батил ишдән ихтийат кәрәк имди* [Кол Гали, 1983, б. 164] – Начар эштән баш тарту кирәк инде һ.б.

4. *Сабырлык, түземлелек турындагы мәкаль-әйтемнәр.* Әсәрдә сабырлык тәгълиматы төп лейтмотивларның берсе булып тора. Автор «һәрбер эшне сабырлык белән, ашыкмыйча эшләргә кирәк», дигән фикерне алга сөрә, моны раслау һәм укучы хәтеренә салып кую өчен ул сәнгати сурәтләү чараларыннан метафораларны, мәкаль-әйтемнәрне, канатлы сүзләрне куллана. Сабырлык һәм сабырсызлык бер-берсенә каршы куела, һәм сабырсызлык аркасында каһарманнар язмышында көтелмәгән борылышлар, түбәнгә төшүләрнең булуы күрсәтелә: *«Бу қазаны бәңа вирди мәүля-җәлил, / Сабырсызлық ғәзизләрни қылур зәлил, / Бән қылурмын имди бонда сабыр җәмил, / Сабыр бирлә морад хасил олур имди»* [Кол Гали, 1983, б. 86]. Әлеге юлларда *сабыр җәмил* (матур сабыр) тезмәсендә бүгенге көндә дә татар телендә кулланыла торган *күркәм сабырлык* мәгънәсе тоемлана. *Сабырсызлық ғәзизләрни қылур зәлил* канатлы гыйбарәсе нигезендә исә *ғәзиз ~ зәлил* (бөек ~ түбән) антонимиясе ята. Авторның *Сабыр бирлә морад хасил олур имди* шигъри юлы хәзерге татар халкының «Сабыр иткән – морадына җиткән» мәкалендә чагылыш таба.

Сабырсызлык кылу, нигездә, Зөләйха образына хас, әмма Йагъкуб пәйгамбәр дә, Йосыф үзе дә сабыр итәргә кирәклеген искәртәләр. Зөләйханың сабырсызлыгы исә аның гашыйк булуы белән аңлатыла: *Ушал хәлдә җанындән кәтди кәрар / Ғишқы йидди, асла сабыры қал-*

*маз имди* [Кол Гали, 1983, б. 146]; *Сәни көрүб, кимниң сабыры қалур имди?!* [Кол Гали, 1983, б. 218]; *Висал шәүке сабырым гарәт қылды имди* [Кол Гали, 1983, б. 164]; *Сабыры қалмаз, аңламаз кимсә сөзин, / Нә сөзләсә, «Йусуф!» дәйү сөзләр имди* [Кол Гали, 1983, б. 148]; *Йалуарыр ол санәмгә, зари әйләр, / Зирә-ки гыйшқы галиб, сабыры аулар* [Кол Гали, 1983, б. 148]; *Бақубән көрси үзрә сәни көрсүн, / Нәчә сабыры вар исә, кәтсүн имди* [Кол Гали, 1983, б. 156]; *Ол сурәт көзүмә көрүнү кәлди, / Хатеремни, һушымны җүмлә алды, / Ғақлым алуб, сабырымы гәрәт қылды, / пәйвәстә нәфсүм аны эстәр имди* [Кол Гали, 1983, б. 130]; *Йа хатун, сән сабыр қылгыл, – диб сөзләрләр, / Сабыр бирлә морад хасил олур имди* [Кол Гали, 1983, б. 136]; *Гәля-д-дәуам көрә дурсам, Йусуф, сәни, / Көрмәсәм, сабырым һәргиз қалмаз имди* [Кол Гали, 1983, б. 162]; *Бу иш эчрә сабыр қылгыл», – дәйүр имди* [Кол Гали, 1983, б. 234]. Әлеге юлларда кулланылган *кимниң сабыры қалур; асла сабыры қалмаз; сабырымы гәрәт қылды* һ.б. еш кабатланган әйтемнәр аша әсәрдә сабырлык идеясе бик югары күтәрелә.

Йагъкуб һәм Йосыф образларында Кол Гали тормышта очраган авыр хәлләргә, кайгы-михнәтләргә сабыр итәргә кирәклеген, сабырлыкны Аллаһ хуплаганын, сабыр иткән кешеләрне ахирәттә рәхәт тормыш көткәнлеген аңлата: *Хыййанәт әһлини халиқ сәүмәз, / Душманлардан гәзабын һич кидәрмәз, / Дәргяһинә кәләнләри кирү қуймаз / Сабыр қылгыл, хаиф раҗи улгыл имди!* [Кол Гали, 1983, б. 160]; *Ғақибәт аны олу мәлик қыйлам, / Вәлякин ол сабыр қыйлсун, – дәйүр имди* [Кол Гали, 1983, б. 118]; *Кәндүдән сабыры кәтди, бихуд олды* [Кол Гали, 1983, б. 140]; *Сабыр қылгыл, шайтан мәкһур олсун имди* [Кол Гали, 1983, б. 158]; *Бу михнәтә сабыр қылгыл, – дәйүр имди* [Кол Гали, 1983, б. 182]; *Шөйлә икән, сабырым сиздән артық имди* [Кол Гали, 1983, б. 176]; *Қул хүкминә рази олуб, сабыр қылса*, / *Михнәт соңра рахәти һәм олур имди* [Кол Гали, 1983, б. 256] һ.б.

Зөләйха төшендә Йосыфны күреп, аңа гашыйк булганнан соң, Мисыр патшасына кияүгә чыгам дип, туган илен калдыра һәм еракларга китә. Әмма аңа Йосыф төшендә сабыр итәргә куша: *Сабыр бирлә ишләгил ушбу иши, / Сабыр бирлә ишләнүр ишләр башы, / Морадына тиз йитәр сабырлу киши, / Бу иш эчрә күрклү сабыр қылгыл имди* [Кол Гали, 1983, б. 132]. Гашыйк Зөләйха бу сүзләрне бөтенләй исәпкә алмый һәм авыр хәлгә кала [Кузьмина, Камалиева, 2023, с. 10] Үзенең сабырсызлыгы аркасында ул Йосыфны да начар юлга өнди, әмма пәйгамбәр Аллаһка сыенганга һәм атасы күзалдына килгәнгә күрә генә җәһәннәм утында янудан котылып кала: *Йусуф әйдүр: «Ходавәндә, ходавәндә, / сәнең хүкмүң кәлтүрди бәни бонда, / бунча фитнә дүшән қула сабыр қанда? / Фазлың бирлә сабыр җәмил виргил имди!* [Кол Гали, 1983, б. 158]; *Атасы һәм Йусуфа заһир олды / «Батилдән нәфсиң маниғ олгул», диди / Аны көрүб, Йусуф сиддиқ сабыр қылды, / Халиқдан коркыб, мәмнуғ олур имди* [Кол Гали, 1983, б. 166]; *Фазлың илә сән қуртаргыл бәни бондан, / Боның кәйди сабырым гарәт қылды имди!* [Кол Гали, 1983, б. 168].

*Әсәрдә сабыр иту, сабыр кылу* сүзтезмәләренә синоним рәвешендә *тәкать* (түземлелек) сүзе һәм аның ярдәмендә ясалган әйтемнәр, фразеологик берәмлекләр кулланылган. Мәсәлән, *Өзум сиддик, атам Йагҗуб, дәдәм Исхаҗ, / Җәрдәшләрим җәфасындан тәҗәтим таҗ* [Кол Гали, 1983, б. 66]; *Мәгшуҗның биңзи күндән күнә сулур, / Таҗәти, җуввәти җалмаз имди* [Кол Гали, 1983, б. 152]; *Мәхзүн ирүр, гаҗизлиҗдин тәҗәти таҗ, / Сәниң йүзиң көрмәкгә йаулаҗ мөштаҗ* [Кол Гали, 1983, б. 190]; *Ибне-Йәмин әйдүр: «Әйа мөрәүүәтдар, / Сәниң йүзиң көрмәкгә морадым бар, / Бәңа хәсрәт әсәр җылмыш, тәҗәтим тар, / Нәҗаб сойсаң, җәмалиң көрсәм имди?!»* [Кол Гали, 1983, б. 234]. Хәзерге татар телендә әлеге мәгънә *тәкате китте, тәкатеннән килү, тәкать иту, тәкать кылу, тәкать китерү, тәкать кору, тәкать киту, тәкать корыту, тәкать тоту, тәкатькә тию, тәкатьтән тыш, тәкатьтән язу* кебек тезмәләрдә һәм, нәкъ «Кыйссаи Йосыф» әсәрендәге кебек үк, *таҗатем таҗ* гыйбарәсендә сакланып калган.

Шул рәвешле, әлеге мәкаль-әйтемнәрдә, канатлы сүзләрдә әсәрнең төп идея-эчтәлеге дә чагыла; тел бизәге булудан тыш, алар тәрбияви-дидактик әһәмияткә дә ия.

### Әдәбият

*Исәнбәт Н.С.* Татар теленең фразеологик сүзлеге: ике томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр. 1990. 365 б.

*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф / төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кульязмаларның тасвирламасын ясаучы филология фәннәре кандидаты Ф.С. Фәсиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 542 б.

*Кузьмина Х.Х., Камалиева А.М.* Речевой портрет Зулейхи в поэме «Кысса-и Йусуф» Кул Гали (XIII в.). Tatarica. № 20. 2023. С. 7–19.

*Ларин Б.А.* Очерки по фразеологии: О систематизации и методах исследования фразеологических материалов // Ученые записки ЛГУ. Серия филол. наук. Л., 1956. Т. 198. Вып. 24. С. 195.

*Нугманова Н.М.* Художественное отражение философии ат-Таухид в «Киссаи Йусуф» Кул Гали: дис. ... канд. филол. наук: 10.01.02. Казан, 2003. 189 с.

*Хәкимҗанов Ф.С.* Татар теленең фразеологизмнар сүзлеге: тотрыклы сүзтезмәләр һәм тәгъбирләр. 3 томда. 1 т. (А–Б). Казан, 2022. 672 б.

*Хуснутдинов Д.Х., Сагдиева Р.К., Мирзагитов Р.Х., Сагдиев Р.Х.* Фразеологические единицы татарского языка с компонентом *җан* (душа) // Вестник Башкирского университета, 2018. Т. 23. № 4. С. 1289–1292.

*Шаряфетдинов Р.Х.* Трансформация коранического сюжета об Иосифе Прекрасном в поэме Кул Гали «Кысса-и Йусуф» («Сказание об Йусуфе»): автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 2009. 18 с.

***Кузьмина Халисә Хатыйп кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Габдулла Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең*
*татар теле белеме кафедрасы доценты*

УДК: 821.512.145

*Д.Ф. Заһидуллина*

# ШӘРИФ КАМАЛ: ЯШӘҮ МОҢЫН СУРӘТЛӘҮ

Статья посвящена жизни и творчеству классика татарской литературы, прозаика и драматурга, поэта и публициста Шарифа Камала. Рассматриваются малоизвестные факты из жизни, журналистской деятельности, сделана попытка обобщающей оценки творческой эволюции писателя. Установлено, что Ш. Камал стал одним из первых авторов татарской психологической прозы, мастером психологического параллелизма. Ш. Камал обращается к художественному потенциалу разных литературных направлений: реализма, романтизма, модернизма, символизма, импрессионизма. Изображение жизни людей, вынужденных искать счастье вдали от родины, тематическое обновление татарской прозы произошло также благодаря художественному творчеству Ш. Камала.

**Ключевые слова**: татарская литература, Шариф Камал, возрождение, начало XX века, психологизм, «поток сознания».

The article is devoted to the life and work of the classic of Tatar literature, novelist and playwright, poet and publicist Sharif Kamal. Little-known facts from life and journalistic activity are considered and an attempt is made to generalize the assessment of the writer's creative evolution. It is established that Sh. Kamal became one of the first authors of Tatar psychological prose, a master of psychological parallelism. Kamal addresses the artistic potential of various literary trends: realism, romanticism, modernism, symbolism, impressionism. The depiction of the lives of people forced to seek happiness far from their homeland, the thematic renewal of Tatar prose also occurred thanks to the artistic work of Sh. Kamal.

**Keywords:** Tatar literature, Sharif Kamal, renaissance of the beginning, twentieth century, psychologism, «stream of consciousness».

2024 елның 27 февралендә татар әдәбиятындагы иң серле язучыларның берсе Шәриф Камалның тууына 140 ел тулды. Безнең буын аны мәктәптә һәм вузда совет әдәбиятын тудыручыларның әйдаманы буларак, иҗатының 1917 елдан соңгы дәверенә, бәхет эзләүче татар юксыллары, хезмәт ияләре тормышын сурәтләү мотивларына игътибар биреп өйрәнде. XX–XXI гасырлар чиге алып килгән иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр боларны кисеп калдырды, бер үк вакытта язучының инкыйлабка кадәрге тылсымлы иҗатына, милли сүз сәнгатендә кешенең рухи дөньясын тасвирлау мөмкинлекләрен арттыруына игътибар итте. Совет чорында үзе дә юксылларның берсе дип күрсәтелгән әдипнең нәсел тамырлары XVII гасырдан ук билгеләнә килеп, олы руханилар, хәрбиләр, мулла-мөфтиләр, иҗтимагый эшлеклеләр белән бер булуы да ачыкланды.

Соңгы вакытта Ш. Камал иҗатын төрки әдәбиятлар, аерым алганда төрек әдәбияты контекстында өйрәнү омтылышлары да ясала

[Хөсәен Барган]. Гәрчә төрек галименең татар һәм төрек язучылары иҗатындагы уртаклыкларны тема-мотивлар яссылыгына да күчерүе күңелдә ризасызлык уятса да, Ш. Камал һәм Халит бәй прозасындагы лириклык, музыкальлек, нәфис-зәвыклы, моңсу-өметле якты сурәт стиль охшашлыгы турында сөйли.

*Тормыш сәхифәләре*

Шәриф Камалетдин улы Байгилдиев 1884 елның 27 февралендә элеккеге Пенза губернасы Инсар өязе (Мордва АССРның Рузаевка районы) Пешлә (Татар Пешләсе) авылында имам Камалетдин Фәйзулла улы гаиләсендә туа. Башлангыч белемне үз авылларында алгач, 1896–1900 елларда күрше Ләбәҗә авылындагы тирә-якка танылган мәдрәсәдә укый: биредә төпле гыйлем туплый, ислам фәлсәфәсен, гарәп һәм фарсы телләрен, Шәрык әдәбиятын тирәннән үзләштерә. Беренче карашка, шушы елларда аның киләчәк юлы күзаллана башлый: дин-гыйлемгә хезмәт итәргә дигән максат билгеләнә. Аның абыйсы, мәгърифәт юлын Шәриф шикелле үк узган Гыймади (Гыймадетдин) шул юлдан тайпылмый – ахун дәрәҗәсенә ирешә.

Шәриф исә шәкерт чагыннан ук гел китап укый; аны чит дөньялар үзенә тарта: җәйләрен Мәскәү-Казан тимер юлында төрле эшләрдә йөри, 1901 елда исә, ваклап сатучы сәүдәгәр Анненковка ялланып, Рига шәһәренә китә. Анда ярты еллап эшләгәч, Одессада, Батумда яшәп һәм хезмәт итеп ала. Әмма күзаллауларын тагын да киңәйтү, белем алу нияте гел алга чакырып тора: шуңа да егет Төркиягә, аннары Мисырга юл ала. Мондагы шартлар исәпләгәнчә булып чыкмый: ике елдан ул Россиягә әйләнеп кайта. Тагын дөнья гизәргә чыга: 1903–1904 елларда Украинадагы күмер шахталарында, Каспий диңгезе буендагы балык промыселларында эшли. Күп җирләрдә булу, төрле кешеләр белән аралашу күзәтүчән, сабыр егетнең әдәби әсәрләргә әйләнәчәк тормыш багажын бик нык баета.

1905 елгы революцияне Ш. Камал Петербургта, татар мәдрәсәсендә мөгаллим вазифасында каршылый. Татар тормышы рухи-мәдәни күтәрелеш, сикереш кичергән, җәмгыятьтә башланып килгән зур үзгәрешләргә олы өметләр баглаган дәвер бу. Шәриф татар телендә вакытлы матбугат оештыру мәйданында кайный: «Нур» исемле беренче татар газетасы редакциясенә корректор булып урнаша, аның битләрендә үзенең тәүге әдәби тәҗрибәләрен – мәгърифәтчелек рухында язылган шигырьләрен һәм публицистик мәкаләләрен бастыра. 1906 елда яшь авторның «Сада» («Аваз») исемле кечкенә генә шигырьләр җыентыгы дөнья күрә, анда XX йөз башы татар шигъриятендә мәйданга чыккан мотивлар: татар халкын алгарышка чакыру, мәгърифәтчелек, иҗтимагый тормыштагы яңалыкларны хуплау үзәктә тора.

1907 елны туган авылы Пешләгә кайтып, мәдрәсәдә балалар укытырга керешүе Ш. Камалга актив иҗат белән шөгыльләнә башларга мөмкинлек бирә. Ул күп укый, аеруча проза, М. Горький, А.П. Чехов

иҗатлары белән кызыксына. Эпик жанрдагы беренче әсәрен – «Уяну» (1909) исемле хикәясен яза һәм аны Оренбургта нәшер ителә торган «Шура» журналына җибәрә. Озакламый хикәя басылып та чыга, укучылар арасында уңыш казана. Татар зыялылары автор белән кызыксыналар, Рәмиевләр аны Оренбургка чакыралар. Үзе дә әдәби үзәккә якынрак булырга теләп, 1910 елда Ш. Камал гаиләсе белән Оренбургка күчеп килә, «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы нәшриятында хисапчы, соңга таба редакция хезмәткәре булып эшли, мәшһүр «Хөсәения» мәдрәсәсендә татар теле һәм әдәбияты укыта; үзен проза остасы итеп таныта, иҗаты белән «татар әдәбиятының тематик колачын һәм сәнгатьле сурәтләү алымнарын сизелерлек киңәйтеп җибәрә» [Әдипләребез, б. 660].

1917 ел революциясен Шәриф Камал Оренбургта хуплап каршылый һәм 1918–1919 елларда шунда чыккан «Эшчеләр дөньясы» исемле газетада, аннары Төркестан фронтының Беренче армиясе политбүлеге органы «Кызыл йолдыз» газетасында эшли һәм языша; шәһәрнең И. Гаспринский исемендәге татар китапханәсендә мөдир вазифасын башкара. 1919 елның көзендә аны Коммунистлар партиясенә алалар. 1920–1921 елларда Ш. Камал Оренбургтан ерак булмаган Чебенле авылында коммуна оештыруда катнаша, гаиләсен дә чакырып, роялен һәм китапларын китертеп, биредә әдәби-музыкаль кичәләр оештыра (әйтик, Т. Ченәкәй, А. Таһировларның килеп йөрүе мәгълүм).

1923 елны Оренбургка яңадан кайтып, укытучылар әзерли торган «Багбостания» кызлар мәктәбендә әдәбият дәресләре бирә. Бераздан Урал буендагы мөселман балалар йорты мөдире итеп билгеләнә. 1924–1925 елларда «Юл» (соңрак – «Сабан») исемле газетада башта редколлегия члены, аннары җаваплы редактор хезмәтләрен дә үти.

1925 елның көзендә Ш. Камал ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты карамагына җибәрелә һәм «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасы редакциясенең партия бүлеге мөдире итеп билгеләнә, Соңыннан ул Татар мәдәнияте йортында гыйльми секретарь (1928), Главлит хезмәткәре (1929–1932), Татар дәүләт академия театрының әдәбият бүлеге мөдире (1933–1935) вазифаларын башкара. Гомеренең соңгы елларында – профессиональ язучы.

1942 елның 22 декабрендә әдип кинәт вафат була.

### *Иҗаты*

Шәриф Камалның иҗатка килүе шигърияттән башлана. Әмма үзенең юлы – шигъриятгә түгел, бәлки прозада икәнен ачык аңлап, ул кабат шигырь дөньясына әйләнеп кайтмый. Бу урында Ш. Камал прозасының тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият белгечләре тарафыннан һәр дәвердә шигъри проза буларак бәяләнеп килүен дә искәртергә кирәк. Шул ук вакытта, 1905 ел биргән демократик иркенлекләрне хуплап, халкын йокыдан уяныргa, белем алырга, алдынгы халыклар белән бер югарылыкка күтәрелергә чакыру үзәктә торган шигырьләр аларның авторының шушы үзгәрешләргә ихлас ышанып, халкы

өчен янып-көеп яшәгәнлеген тагын бер кат раслыйлар. Алар шулай ук мәгърифәтчел идеяләрнең ярымпублицистик яңгыратылуы, әдәби текстларның традицион дини-суфичыл мотив-образларыннан, гарәп-фарсы һәм төрек гыйбарәләре чуарлаган лексикасыннан аерыла алмавы, әмма шәхси-милли мөрәҗәгатьләрнең кавемдәшләренә атап белдерелүе, татар халкы тормышын яхшы якка үзгәртергә омтылган заман лирик героен тудыруы белән үз дәвере татар шигъриятенә аваздаш. Әйтик, *«Янә шу гаскәр»* шигыре Дәрдмәнднең «Әгәр барсаң, саба җил...»ен искә төшерә. Суфи әдәбияттан килгән бу образ Ш. Камалда традицион эчтәлеккә якын булса (бу якынлыкны, иң беренче чиратта, чит җирдә сахрада кан эчендә яткан егет образы тәэмин итә), Дәрдмәндтә инде ул бөтенләй дөньявилаша.

Ш. Камал шигырьләре беренче тапкыр кирилл хәрефләрендә «Җыен» фонды әзерләгән «Шәхесләребез» сериясендә дөнья күргән фәнни-популяр җыентыкта тәкъдим ителде [Шәриф Камал, б. 131–141].

Җыентыкка исем биргән «Сада» шигыренең беренче өлешендә мәйханә, сәрхуш, мөфлис-теләнче кебек образлар ярдәмендә суфичыл дөнья сурәте тергезелә, караңгы һәм тәртипсез җир тормышы кире кагыла. Тексттагы икенче өлеш бу сурәтне «татар-төркестанлылылар» хәл-халәтенә күчерә, аларны гыйлем-һөнәр өйрәнмәүләре өчен тәнкыйтьли, Гареб-Шәрык, ягъни Көнбатыш-Көнчыгыш каршылыгы тудырып, лирик «мин» соңгыларының артта калганлыклары өчен сызлана.

Алга таба әсәр тагын үзгәрә: текстка хуҗа, ия, дус мәгънәләрен йөрткән Сахиб исемле образ килеп керә. Аның сөйләгәннәрендә XX йөз башы татар шигъриятендәге иң актив образларның берсе – «милләт йокысы» («Йоклаб калган милләтдин») – ачкыч ролен үти. Ул мәгърифәтчел тәнкыйтькә юл ача. Бу өлеш бөтенләй мәгърифәтчеләрчә язылган.

Шигырьдәге сурәт кабат үзгәреш кичерә: хыялый-фантастик бер вакыйганы тасвирлау төсен ала. Үз чиратында, вакыйга, шулай ук суфи әдәбият белән интертекстуаль бәйләнешкә керә.

Имеш, Сахиб сәяхәткә чыгып, гаҗәеп тау битендә ял итәргә туктагач, үз башыннан кичкән бер вакыйганы сөйли (ул суфи әдәбияттагы Тур тавы итәгендә чиктәш дөньяга аяк басуны да, төш күрүне дә хәтергә китерә). Сахиб хикәятендә гаҗәеп бер күренеш калка: тау итәгенә татар халкы җыйналган, имеш. Алар таркау, наданлыкка йөз тотканнар, йокыда – гыйлем яки һөнәр үзләштереп, күзләрен ачарга теләмиләр, төрле фирка-партияләргә бүлгәләнгәннәр. Шулвакыт бер ялкынлы сүзле егет чыгып, музыка һәм сүз берлеге ярдәмендә кавемдәшләрен уянырга, берләшергә, «Ватан вә милләт мәнфәгатенә» хезмәткә өнди. Бу урында инде суфичыл сурәтне – милли-мәгърифәтчел күзаллау алмаштыра.

Текстка тарихи күренешләр, явызлык, наданлык белән гомер сөргән дәүләтләр, аларның җимерелүе турындагы тарихи мәгълүматлар

килеп керә. Озын шигырь кавемдәшләрен гыйлемгә, берләшергә чакырып, мәгърифәтчел өндәүләр белән төгәлләнә. Монда Ш. Камалның, милләткә хезмәтне алга куеп та, шигъри юл, өслүб сайлый алмавы да аермачык күренә.

«Тынычсызлык» дип исемләнгән фәлсәфи шигырь гомернең кыскалыгы, үлем белән тәмамлануы, адәм баласының шул кыска гомерен явызлык эшләп уздыруы турында сөйли. Болар лирик «мин»нең сызлану объекты булып килә. Бу шигырьдә инде авторның дөньяви сурәтләүгә өстенлек бирүе күзгә ташлана.

Ш. Камал татар әдәбиятында XX йөз башы мәдәни яңарышын башлап җибәргән, психологик прозага нигез салган язучыларның берсе буларак күренекле. Бер яктан, үз чоры татар җәмгыятендәге төрле катлау, бигрәк тә хезмәт кешеләренең (сезонлы эшчеләр, балыкчылар, шахтёрлар), интеллигенция вәкилләренең яшәешен тормышчан картиналарда һәм образларда тасвирлап, язучы милли әдәбиятка өр-яңа темалар алып килә: матди хәлләре чиктән тыш авыр булган татарларның читтә бәхет эзләве, сукбайлык, матди-иҗтимагый шартларның кеше язмышларын җимерүе шундыйлардан. Икенче яктан, форма өлкәсендә татар прозасында башланган үзгәрешләр дә Ш. Камалның 1909–1910 елларда иҗат ителгән кыска хикәяләренә барып тоташа. Ул XX йөз башы татар әдәбиятына сәнгатьнең гади кешеләр күңелендәге матурлыкны, рухи байлыкның танып белеп бетерү мөмкин булмаган тирәнлеген, кешенең тормыштагы һәр мизгелгә җылы мөнәсәбәт белдерә – ягъни бәхет кичерә – алуын сурәтләргә тиешлеге хакындагы карашны алып килә, кешеләрнең катлаулы психологиясен, эчке дөньясын, рухи үзгәрешләрне, хәтта аң төпкелендә барган процессларны сурәтләү объектына әйләндерә. Эмоциональ-лирик моң, аз сүз белән бирелгән тирән мәгънә, композицион җыйнаклык һәм тыгызлык – әдипнең хикәяләренә әнә шул сыйфатлар хас. Тормышны тышкы детальләр, әйберләр, эш–хәрәкәт яссылыгында сурәтләүдән – кешенең эчке дөньясын, хис–фикер үсеш-үзгәрешен тасвирлауга күчү, шәхесне эш-гамәл һәм уй-омтылыш берлеге булган катлаулы характер итеп күрсәтә башлау милли сүз сәнгате өчен яңа мөмкинлекләр ача: аны фәлсәфи-психологик дулкынга көйли.

Хикәяләрендә кешеләрнең фаҗигасы яки күңел матурлыгы, рухи байлыгы яки бушлыгы хакында сөйләп, Ш. Камал һәр әсәрендә яшәешнең бер ягын ача. Аның геройлары – гади кешеләр, ләкин характер бирелеше ягыннан автор аларга бер төркемгә, сыйныф-катлау вәкилләренә хас сыйфатларны туплый, тормыш сынауларының иң авырларын үткәргән геройлар хәлиткеч мизгелдә – тагын да җаваплырак сынауны (кешелеклелек сынавын!) кичкән мәлдә сурәтләнәләр. Әйтик, «Уяну» (1909) хикәясе тегермәндә эшләүче Муса һәм аның хатыны Гафифә образлары, аларның язмышы аша тормыш китергән авырлыкларны күтәрә алмауның ике моделен тергезә. Элек бай баласы булган Муса хәзер *шәһәрнең читендә иң сәләмә, иң ярлы мәхәлләдә* [Камал, б. 7] яши. Язучы аның ни сәбәпләр белән бу хәлгә

төшүен күрсәтми. Ләкин әлеге сынау Мусаны үзгәртә: ул эчүгә бирелә, язмышка үчен сөеп өйләнгән хатыныннан ала башлый, нишләгәнен белмәс дәрәҗәгә җиткән ерткычка әверелә. Иң соңгы сынау – үзе өчен бердәнбер кадерле кеше булган хатынын кыйнап үтергәнен белү – Мусаны акылдан яздыра. Гафифә исә сынауларны сабырлык белән кабул итә. Ире кыйнаганнан соң, елгага ташланырга җыенуы да аның хакына булып чыга (*Ах, үләм инде, тынычланырсың...*). Язучы бу вакыйганы Мусаның да, Гафифәнең дә фаҗигасы итеп сурәтли. Хикәяләү әле Муса хисләрен, әле Гафифә кичерешләрен тергезә һәм тормышның башкача булу мөмкинлеген искәртә. Хикәянең исеме – «Уяну» – Мусаның үзе кылган хаталарны аңлавы, мәхәббәтен югалтканлыгына төшенүе турында сөйли. «Уянган» Муса, ерткычлыгы, вәхшилеге нәтиҗәләрен күтәрә алмыйча, акылдан яза. Г. Халит мондый финалны «гади кеше намусының явызлыктан, кыргыйлыктан өстенлегенә, аның вөҗдан уты сүнмәвенә, рухи матурлыгына ышаныч» [Татар әдәбияты тарихы, б. 321] уятучы дип бәяли.

Ретроспекция ясап, язучы Муса һәм Гафифәнең яшь вакытларын, мәхәббәтләрен искә төшерә. Егет уйларында мәхәббәтне саклау мөһимлеге искә алына: *Ниһаять, гыйшык... өйләнү... мәхәббәт... ух! Нихәтле зәвык, нихәтле сәгадәт иде! Әүвәлге икесе инде үткән... соңгысын гына кайтарып булмасмы икән?* [Камал, б. 7]. Хикәядә әһәмиятле символ буларак бирелгән Гафифәнең якасыннан өзелгән төймә мәхәббәтнең дә өзелгән булуын күрсәтеп килә. Егетнең *Югалмасын, үзе килгәч үзенә бирермен...* дип уйлавы мөнәсәбәтләрне тергезергә омтылыш булып аңлашыла. *Муса үбеп-үбеп, җан сулышы белән аның кулларын җылытмакчы була иде. Әмма куллар инде җылынмый иделәр,* дигән өлештә дә Мусаның күңелендә хатынына карата хисләрнең исән булуы белдерелә. Әмма төймә, яшьле күзгә охшап, Мусага гаебен искәртә, иң якын кешесен, бәхетен, киләчәген югалтуы хакында сөйли. Шулай мәхәббәт категориясе хикәяне аерым кеше тормышы тарихыннан – гомумән яшәеш кануны хакындагы фәлсәфи тарихка әйләндерә. Кеше өчен иң кадерле хис – мәхәббәтнең бик нәфис һәм нәзберек икәнлеген, тормыш авырлыкларын күтәрә алмыйча, аны югалтуның фаҗигага әверелүен сөйли. Бер ясалган ялгышның, хатаның төзәтелә алмаганын укучы сызлануы объектына әйләндерә.

Шулай ук «уяну» халәтендәге геройлар язучының башка хикәяләрендә дә тасвирлана. «Буранда» (1909) хикәясендә этисенең коткысына бирелеп әнисен рәнҗеткән Мостафаның, ялгышын аңлап, аны төзәтергә ашкынуы, ләкин улы ишектән кергән мизгелдә ананың бакыйга күчүе кебек үсә барган вакыйгалар, егет күңелендә кайнаган каршылыклы уй-кичерешләрнең тышта котырган буран белән янәшәлектә бирелүе сәбәпле, шулай ук фәлсәфи гомумиләшә. Ялгышлар кеше күңелендә тынычсызлык уята, аны кайгыга сала, диюче язучы шушы халәтне психологик анализ ярдәмендә барлык вакыйкларында укучыга җиткерә. Ялгышны аңлау – хәтер категориясе,

үткәндәге аерым мизгелләрне искә төшергәндә хасил була. Ш. Камал геройларының матур омтылышлары да, хисләре дә – хатирәләрдә: шулар аша язучы ясалган ялгышларның сәбәпләрен дә укучыга җиткерә. Хикәядә ул, һичшиксез, Мостафаның үзенә бәйле: әтисе исән вакытта кылган дорфалыкларыннан тыш, ул үлгәч тә егет әнисе янына килеп гафу үтенми (*Ул анасыннан бизгәнмени инде? Әйе, ул үзен тудырган һәм бишеге янында катып, караңгы, тын һәм күңелсез төннәрне «балам» дип йокысыз уздырган анасыннан бизгән иде! (...) Болар һәммәсе яшь вакытында, әмма зур булгач? Менә хәзер аның беренче мәртәбә бармагын тешләп аптыраганы да – үзенең анасына каршы, атасы барында күрсәткән тәрбиясезлекләреннән тыш, атасы үлгәч тә, анасыннан гафу сорамавы, һаман аңар илтифатсыз һәм салкын мөгамәләсе өчен иде...* [Камал, б. 15]). Ана мәхәббәтеннән мәхрүмлек аның салкын, башкаларга ышанмый, аларга мыскыл итеп карый торган кеше булып формалашуына китерә. Андагы үзгәрү ноктасын тасвирлаганда, язучы иптәше Хөсәен исеменнән мондый бәя бирә: *Һәрнәрсәгә мыскыл күзе белән карый, бер сүзгә дә инанмый, кеше сөйләгәнне тыңламый, үзе сөйләсә, кешедән көлә торган салкын һәм ян-елымсыз бер кешенең аптырау һәм оялуы чынлап кызык иде* [Камал, б. 12].

Шуның белән янәшә, язучы бу ситуацияне татар җәмгыятендә еш очрый торган әхлаксыз күренеш кебек шәрехли *(Атаң мине сөрә...)*. Символ буларак та, янәшәлек кебек тә урынлы кулланылган буран мондый күренешләрнең кешеләр күңелен дә, җәмгыятьне дә хаоска, куркыныч салкынлыкка, билгесезлеккә китерүче булуын ассызыклый. Хикәя ахырында әнисеннән исән вакытта гафу үтенеп кала алмаган, ләкин ялгышын аңлаган Мостафа шул халәттә кала. Соңгы җөмлә – *Тышта буран һаман дулый иде* – ялгышны аңлауның, уянуның тормышны үзгәртү өчен беренче адым гына булуын искәртә.

Аерым бер хикәяләрдә тормыш сынаулары кешенең аларны кабул итүенә бәйләп куелмый. Язучы яшәешнең кешеләргә зур авырлыклар китерүен күрсәтеп, татар җәмгыятендәге бәхетсезлекләрне милли проблема буларак аңлата. «Сулган гөл»дә (1909) 19 яшьлек Камәрнең ялгызлыгы – көндәш өстенә карт ирләргә кияүгә бирелгән татар кызлары фаҗигасы кебек шәрехләнә. «Кычкырыш»та (1910) киленнәрнең – хатын-кызларның татар гаиләсендәге хокуксызлыгы игътибар үзәгенә куела. Фаҗигалы күренеш белән янәшә, геройлар күзаллаган, хыялланган бәхет тә кечкенә детальләрдә сиземләнә. Әйтик, «Сулган гөл»дә Камәрнең рухи ялгызлыгына 13 яшькә кадәрге балачагы һәм шул вакыттагы өмет-хыяллары каршы куела, бәхеткә омтылыш, рухи яктан үзенә якын кеше белән аралашу ихтыяҗы кичерешләр агышы кебек сурәтләнеп, Г. Халит бик дөрес билгеләгәнчә, «бу кичерешләрдә үзен бәхеткә хаклы санаган олы җанлы герой дөньясының якты бер чите, тәрәзәчеге ачылып киткән кебек» [Татар әдәбияты тарихы, б. 321]. Гади бер татар кызының рухи дөньясы, аның табигать, күкләр белән аралашу гүзәллеге язучы сурәтләгән фаҗиганы тагын да

көчәйтергә ярдәм итә. Шундый ук алым башка хикәяләрдә дә урын ала. «Ата» (1910) хикәясендәге картаеп кына әти булган, ашлык абзарында эшләүче Корбангалинең улы туу белән бәйле хыяллары гади кешеләр яшәгән тормышның авырлыгын тасвирлауда катнаша, бер үк вакытта кешеләрнең, нинди генә кыенлыклар килүгә карамастан, бәхет кичерә алу мөмкинлеге турында сөйли.

«Сукбай» (1911) хикәясендә үз чорының типик герое – читкә акча эшләргә китеп, авылдагы анасын, хатыны белән баласын, апасының гаиләсен бәхетсезлек чигендә калдырган Гали язмышы тергезелә. Аның фаҗигасында язучы, бер яктан, ирнең үзен гаепли, кешегә үзе кылганнарның нәтиҗәсен күрергә, кичерергә туры киләчәген сөйли. Икенче яктан, иҗтимагый сәбәпләрне дә ассызыклап, туган җирләреннән китеп, башка мохиттә яшәү шартларына яраклаша алмаган татарлар бәхетсезлегенә дәлил китерә. Шуңа күрә дә хикәянең ахырында язучының оста каләме белән тудырылган табигать сурәте (*Гали кояш чыгышына таба китеп бара... Тик, кояш чыгар алдыннан күренергә тиешле матур манзараны буран каплаган иде...* [Камал, б. 41]) Галинең караңгы язмышына гына түгел, татар җәмгыятенең караңгылыктагы, билгесезлектәге киләчәгенә проекцияләнә. Мондый гомумиләштерү, хикәянең символлар, яңгыраш матурлыгы, образлы сөйләм мөмкинлекләреннән файдалануы аны югары зәвыклы укучыга атап язылган гаять камил, тәэсирле әдәби әсәр дип билгеләргә мөмкинлек бирә.

Шушы юнәлештәге иң аяныч, фаҗигалы хикәяләрнең берсе – «Козгыннар оясында» (1910) шулай ук туган җирләреннән аерылып, шахтада эшләүче татарлар көнитешеннән алып язылган. Эчкечелек, юктан кызык табып, мәгънәсез көлке оештырып яшәүче «козгыннар» Мәрьям белән Госманның – *бер-берсенә бик якынлык хис итә* торган ир белән хатынның – бәхетен, өметләрен җимерәләр: Мәрьям суга батып үлә, бәхетсез Госман, үзенең гаебен аңлаган хәлдә, билгесез тарафка юл тота. Язучы әлеге вакыйга ярдәмендә читтә акча эзләүче татарларның үз тормышларын да, башкалар язмышын да әрәм итүе хакында сөйли, бу юлның татарлар өчен мәгънәсез икәнлегенә укучының игътибарын юнәлтә.

Ш. Камалның аерым бер хикәяләре кеше психологиясен яшәеш хакында гомуми нәтиҗә ясарлык итеп файдалана, язучы «мәгълүм бер халәте рухияне (психологический момент) эләктереп алып, шунда казыну, эзләнү юлы» [Вәлиди, б. 321] сайлый. Шундыйларның берсе – «Ике яхшы» (1910) хикәясе. «Бер хатирә дәфтәреннән» дип куелган әсәр мәхәббәт һәм хыянәт, гафу итү тарихын сөйли. Хикәяләүче мин Зөһрә исемле кызга гашыйк була. Ләкин кыз башканы сөя, егетне мыскыл итә. Сөйгәне ташлап киткәнне белгәч, егет Зөһрә янына килә. Шунда кыз аңа: *Син бик яхшы күңелле,* – ди. Бу очракта егетнең яхшылыгы гафу итә алу сыйфаты булып аңлашыла. Яшьләр өйләнешәләр, кызның «яхшы»лыгы яратмаган кешесен бәхетле итү рәвешендә төгәлләшә.

Хикәя бер гаилә булып гомер уздырып картайган кеше авызыннан сөйләнелә. Ул картның фикер агышы кебек оештырылган. Шушы фикер агышы *Менә хәзер икебез дә картайдык, чәчләребез агарды, һаман бер-беребезгә иң сөйгән вә иң якын кешеләр булып гомер итәбез* [Камал Ш., б. 36] дигән җөмләгә кадәр килә, аларны бергә яшәргә мәҗбүр иткән карашны расларга яки кире кагарга омтылып сөйләнә. Картның хәтеренә уелып калган, димәк, иң әһәмиятле берничә вакыйгага мөнәсәбәт, шул мизгелләрдәге кичерешләре бәян ителә. Бала чакта кызның кулын учына алып, уңайсызлык кичерүе; гашыйк булу, кызга табыну, бәхетле чак; кызның кире кагуы – «хәрабә», аңсызлык вакыты; яратканын башка белән күреп, аннан мыскыл ителү – «ярымүлек» хәлдә булу; ташланган кыз янына барып, аны гафу итү. Ләкин кызны гафу иткәннән соң, яңадан ярату хакында сүз бармый: мәхәббәт инде «үлгән». Егет бары тик кызның үзен «яхшы» дип атавы хакында гына сөйли, олы күңеллелек күрсәтүе белән горурлана. Өйләнешү яки гаилә булып яшәү хакында да «хәтер»дә берни юк.

Шул рәвешле, хикәя мәхәббәт үлгәннән соң гафу итү, ике кешенең, ярату булмаган килеш, гомерләрен бер-берсенә багышлавы хакында булып чыга. Аның моңсу интонация белән сөйләнүе, хикәяләүченең берничә урында калкытып куелган эчке каршылыгы, һаман да «дөрес эшләдемме» дигән үкенечле сорау куя килүе, шул сорауга үзенең «сентиментальный вә хыялый» булуын сәбәп итеп, аклану эзләве дә – шуңа дәлил. Кешенең хәтерендәге иң мөһим күренешләрнең үз хәтерләве тәртибендә, үзенең мөнәсәбәт белдерүе кебек язылып, хикәя укучыны аның язмышына фаҗига итеп карау баскычына күтәрә, фикер агышын күзәтеп бару шул фаҗиганы аңлау ноктасына алып килә. «Аң агышы» хикәяләүче кешегә хакыйкать булып тоелган нәрсәләрнең шартлылыгын ассызыклый һәм укучыны фәлсәфи нәтиҗә чыгарырга этәрә: бер үк бәхетне ике тапкыр кичерү мөмкин түгел!

«Эч пошулы» (1912) хикәясе нәкъ шул схемада иҗат ителгән. Узганны хәтергә төшерү бүгенге халәт турында башламда һәм ахырда сөйләү белән каймалап алынган. Биредә төзек сюжет та юк: әсәр, мозаика кебек, аерым бер күренешләрдән җыелган. Биш ел элек яшәгән шәһәргә кайтып, хикәяләүченең үзе фатирда торган хуҗа картны очратуы. Шул чакны хәтерләп, картның кечкенә кызлары Мәрьямнең яланаяк йөрүе һәм скрипка уйнаганны тыңларга керүен искә төшерү. Мәрьямнең хәзерге хәлен сорау һәм аның тормышның иң түбән пычрак төпкеленә төшкәнлеген белү... Шушы күренешләр хикәянең буеннан-буена тормышның пычрак, караңгы, күңелсез, түбән булуы хакында сөйләү белән үрелеп бара.

Хикәядә егетнең Мәрьямгә гашыйклыгы, мәхәббәт хакында сүз бармый. Кечкенә Мәрьям – матурлык һәм сафлык символы, тормышның матур якларын күрергә мәҗбүр итүче идеал кебек тәкъдим ителә.

Хикәянең ахырында *Бу язу бер гостиницаның 13нче номер бүлмәсендә табылган иде* дигән автор искәрмәсе бар. Әсәрнең исеме, «Эч пошулы» гыйбарәсе белән кушылып, ул тирән депрессиядәге кешенең башына килгән уйларын кәгазьгә төшереп баруы кебек уйланылган. Хикәягә салынган фәлсәфи фикер текстта да күпмедер чагылыш таба. Беренче ике җөмлә болай яңгырый: *Күңел теле: бир куәт! Шул мең кат тапталып беткән чиркин тар кабыкны тишеп чыгыйм…* [Камал, б. 115]. Фәлсәфи планда, кеше үзе уйлап тапкан матурлык һәм изгелек идеалы кайберәүләр, яшәүдән өмет өзгәннәр өчен яшәешнең матур якларын күрергә, шәхесне томалап алган тар кабыкны ватарга ярдәм итә ала, диелә.

Шул ук вакытта хикәяне милли проблема яктылыгында уку мөмкинлеге бар. Хикәяләүче сафлык идеалы итеп сурәтләгән кызны, этисе сүзләре белән әйткәндә, *аздырдылар, мескенне.* Әйтелеш рәвеше Мәрьям фаҗигасында тирәлекне, җәмгыятьне гаепләрлек итеп уйланылган. *Чиркин таш кабыкны тишеп чыгу* – җәмгыятьтә билгеләнгән рамкаларны, кешелексез тәртипләрне җимереп, сафлыкка, чисталыкка омтылыш төсен ала. Хикәянең исеме – «Эч пошулы» – Ш. Камалның башка әсәрләрендә дә татар яшьләрендәге халәт кебек кабатлана. «Шәкерт» (1910) хикәясендә мәдрәсә тормышының мәгънәсезлеген, һөнәрсезлеге сәбәпле киләчәгенең томанлы булуын аңлаган Гомәрнең дә *күңелендә шул хәтле шигърияте сез бер эч пошу* оялаган. Бу үзенчәлеккә Г. Нигъмәти игътибар итә: «Ш. Камал әсәрләрендә яратып бирелгән коллизияләрнең берсе – хыял белән хакыйкатьнең бәрелеше булып, моның нәтиҗәсендә матур, тәмле хыял һәм өметләр һәрвакыт җимерелеп, алар урынын эчпошыргыч, күңелне сыкраткыч, омтылышларны буучан чынбарлык ала» [Нигъмәти, б. 148]. «Эч пошу» гыйбарәсе алга таба татар прозасында тотрыклы төс алып, Ф. Әмирхан, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Ә. Тангатаров, М. Хәнәфи һ.б. әсәрләрендә күзәтелә һәм татар җәмгыятенең кимчелекле якларын күреп тә, шуны үзгәртә алмау чарасызлыгын ассызыклый.

Ш. Камал тормышны төрле яклап, төрле төркем кешеләр очрашкан психологик әһәмиятле мизгелләр сәхифәсе кебек тергезә. «Курай тавышы» (1912) хикәяләүченең балачагындагы кайбер истәлекләрне яңартуы кебек язылган. «Ике яхшы»дагы кебек үк, биредә «яхшы» һәм «начар» сүзләре уйнатыла, автор җәлли белү һәм мәрхәмәт күрсәтүнең яхшы кешегә хас сыйфатлар булуын ассызыклый. Әлеге хикәядә әдип чиктәш – өн белән төш, саташу – халәтендәге кичерешләрне тасвирлап, яшәешнең гомер һәм үлем кебек чикләрен тоташтыруга ирешә.

«Тормыш көе» (1913) хикәясе шулай ук хикәяләүче егетнең хатирәләре, үз башыннан үткән кайбер күренешләрне иптәшләренә сөйләве кебек язылган. Ул өч кешенең үзара мөнәсәбәтләрендәге үзгәрешне сурәтли. Беренче күренеш гаиләнең матур вакытын искә төшерә: эти кеше улы һәм хатынына үзенең яшь вакытларын, Әстерханда эшләвен күңелле итеп сөйләргә ярата торган була. Аннан соң-

гы истәлекләр кайгылы яңгырый. Ата кеше авырып китә, терелә. Моннан соң әти кеше хатынына һәм малаена гел ачуланып тора, кул күтәрә; яшь хатынга өйләнә. Шушы сызыкка бәйле, татар җәмгыятендәге күпхатынлык күренеше бәяләнә. Тагын бер вакыйга аерып бирелә: ана улын өйләндерергә тели, ләкин бу эш барып чыкмагач, нык борчыла, елый.

Аннары егет ике елга авылдан китә. Кайтуына инде ана вафат булган. Хикәянең соңгы җөмләләре мондый: *Әмма бирәү: «Сез аны икәү үтердегез: әткәң белән син...» – диде. Шуны кем, кайда, өнемдәме, төшемдәме әйтте – һич хәтерли алмыйм...* [Камал, б. 147].

Хәтердә сакланып калган вакыйгалар, аларның шәрехләнүе егет характерын ачарга, аның күңелендәге үкенечне күрсәтергә ярдәм итә. Гаиләдәге йомшак күңелле ана ирен яратып, аның хисләренә ышанып яши. Ләкин ир бу өметне башта – катылыгы белән, аннары башкага өйләнеп «үтерә», юкка чыгара. Ананың күңелендә малаен бәхетле итү, яраткан кешесе белән бергә булырга мөмкинлек тудыру теләге уяна. Ләкин монысы да барып чыкмый. Инде тормышта тотып торыр ышанычы, өмете калмаган ана үлә. Кадерле кешесен югалтканнан соң гына аның фаҗигасын аңлый, төшенә алган улы анасын уйлап яши башлый. Аң төпкеленнән, хәтереннән бу фаҗиганы тудырган сәбәп-күренешләрнең иң әһәмиятлеләрен барлап чыга. Иптәшләре белән сөйләшкәндә дә тормышындагы үзе өчен иң мөһим әлеге хәлне бәян итә.

Әсәрнең идеясе исемгә үк чыгарылган һәм фәлсәфи яңгырый. Егетнең хәтерендәге күренешләр тормыш агышына бәя бирә: кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр гел үзгәреп тора, яратуны рәнҗетү алмаштыра, өметләр көлгә әйләнә, ди сыман. Өмет өзелү исә – үлем. Ләкин бик якын кешеләр дә өметләр өзелгән мизгелне күрергә сәләтле түгел, ярдәм итә алмыйлар. Бу исәннәргә гомерлек үкенеч бирә. Менә шушы – тормыш көе, законы.

Хәлиткеч мизгелләрне кичерүче, үз хәлләрен аңлау-төшенү халәтендә сурәтләнгән геройлар Ш. Камалга укучыны да «ачыш ясау бусагасына» бастырырга мөмкинлек бирә. Хакыйкатькә күзләре ачылган геройлар тормыш ситуациясен чишү юлларын таба алмый: морза улы Әсфәндиар Мохтаров, матди кысынкылыктан котылу юлын күрмичә, үзенә кул сала («Җимерелгән звонок», 1911), балаларына кирәксез икәнлеген төшенгән карт үлемгә өметләнә («Бер картның тойгылары», 1910), кызы Газизәнең алданганын белгән ананың йөрәге чыдамый – ул бакыйлыкка күчә («Күңелсез эш», 1910), атасының үги ана җәбереннән үзен яклый алмавына төшенгән Нәфисә билгесез якка китеп югала («Нәфисә», 1912). Язучы чарасызлык чигенә җиткән кешенең тормыштан ваз кичү халәтен тергезә, гадәти булмаган күренешләр ярдәмендә яшәеш кануннарын билгели. Шул ук вакытта мондый ситуацияләр XX йөз башы татар җәмгыятенә бәя булып яңгырый. Җәмгыятьтәге торышны күп кешеләр язмышлары мисалында,

төрле яклап тасвирлап, Ш. Камал аны өметсезлек, чарасызлык чигенә җитү дип белдерә.

1914 елны Ш. Камал күләмле әсәр – «Акчарлаклар» повестен төгәлли. Ул язучы хикәяләрендә очраган күп кенә мотивларны мөстәкыйль сюжет сызыклары дәрәҗәсенә үстереп язылган. Вакыт ягыннан, Каспий диңгезенә эшкә килгән кешеләрнең бер сезон (җәй башыннан көзгә кадәр) тормышларын колачлап алган повесть күп язмышлар, ялланып эшкә килергә мәҗбүр иткән сәбәпләр хакында җентекләп сөйләп, татарларның читкә эшкә йөрү хәрәкәтен тулы яктырта. Автор сурәтләгән геройлар – ярлылыкка түзә алмыйча, акча эшләргә килүчеләр. Ләкин алар арасында солдаттан кайтыр җире булмаганнар да (Хөснетдин), эчү аркасында гаиләсен җимергән мулланың балалары да (Гариф), бөлгән бай малайлары да (Федор Лашкарев) бар. Җир азлык акча эшләргә читкә куа, диюче автор бу кешеләрнең асылда бераз мая туплап, яңадан туган якларына кайтып дөнья көтәргә хыяллануын ачыклый. Ләкин повестьта сурәтләнгән сезон да, эшчеләрнең искә төшереп-ретроспекция ясап тәкъдим ителгән алдагы еллар вакыйгалары да бу хыялның тормышка ашарлык түгеллеген күрсәтә. Шул ук вакытта язучы читтә йөрүнең татар гореф-гадәтенә, әхлагына тискәре йогынты ясавы турында да сөйли: аракы эчү, карта уйнау, сугышу-талашу, пасха бәйрәмнәрен билгеләп үтү күренешләре шулай мотивлаштырылган.

Гариф белән Газизә мәхәббәте турындагы сюжет сызыгы да ялланып эшләүчеләрнең кабат татар авылларына кайта алмаячагына, шушы алдавыч тормыш белән яшәү дәвам итәчәгенә мисал булып килә. Газизәгә карата күңелендә җылы хисләр уянган Гариф, шулар иркенә буйсынып, кызга вәгъдә бирсә дә, бу вәгъдәнең тормышка ашмаячагы табигать сурәте аша сиздерелә. Бер тапкыр бу юлга бастыңмы – моннан котылу юк. Язучы читтә ялланып эшләүчеләрнең йортсыз-җирсез, өметсез, киләчәксез булуын ачынып сөйли. Бүгенге табыш хакында уйлау ераккарак күз ташларга мөмкинлек бирми. Газизәнең авылга кайтып эшләргә, дөнья көтәргә теләге булса да, Гариф гаилә корырга әзер түгел. Ш. Камал читтә бәхет эзләүнең милләтне инкыйразга китерә торган хәрәкәт булуын идея итеп күтәрә. Шушы фикерне ассызыклау өчен кертелгән канатсыз акчарлаклар метафорасы, аларның *тонык һәм эчпошыргыч тавыш белән елаганга да, көлгәнгә дә охшашлы гыйгылдап-гыйгылдап* [Камал, б. 241] кычкырынулары автор сызлануы, экзистенциясе төсен ала.

Гариф һәм Газизә язмышына Ш. Камал «Таң атканда» романында әйләнеп кайта. Роман 1917 елның 6 октябре вакыйгалары белән башланып китә. Солдатларның Беренче бөтендөнья сугышыннан качып кайтулары, Вакытлы хөкүмәткә мөнәсәбәт, большевиклар идеяләренең таралуы хакында сөйләп, язучы аны власть Советлар кулына күчкән вакытка кадәр алып килә. Шушы кечкенә аралыкта карашлар бәрелешен, омтылышлар төрлелеген сурәтләп, Ш. Камал халык арасындагы таркаулыкны ассызыклый, большевиклар парти-

ясенең системалы, максатчан эш алып баруын үзәккә куя. Читтә ялланып эшләүчеләрнең (Гарифның, Мохтарның), иң беренче чиратта, большевиклар идеясен эләктереп алуы билгеләнә. Алар чарасызлык чигенә җиткән үз тормышларын үзгәртү юлын бары тик шушы идеядә генә күрәләр.

Шәрәфи картка һәм Газизәгә терәк – большевик Мохтар Булатов романда үзәк герой буларак тәкъдим ителә. Язучы Мохтарның фикри өлгерүен күзәтә, моның сәбәпләрен тарихи ихтыяҗ белән генә аңлатмыйча, татар җәмгыятендәге патриархаль күренешләргә дә тоташтыра. Әйтик, Мохтарның ире кыйнап үтергән апасы Хәлимәнең, аның кызы Фатыйманың язмышы шундыйлардан. Моннан тыш, язучы революция татар җәмгыятендә тудырган кайбер тарихи бәхәсләрне вакыйгалар тукымасына кертеп җибәрә. Шундыйлардан, милли яки сыйнфый көрәш мәсьәләсенә кагылышлы дискуссия аеруча кызыклы һәм уйландырырлык. Җәмгыятьтәге бер төркем кешеләрнең фикерен белдерүче Нәгыйм Кәбиров болай сөйли: *Гомумән алганда, татар милләте – үзенең тарихы, үзенең кара язмышы белән, гомумән, дөнья йөзендәге бөтен милләтләргә караганда артыграк җәбер, җәфалар, хәсрәт һәм кысынкылыклар, пришанлык һәм фаҗигалар күргән бер милләт. Гомумән алганда, шушы сәбәпләр аркасында, ул, наданлык, фәкыйрьлек чокырына батып, башка милләтләрдән бик күп артка калган. Иң элек татар милләтен гомуми икътисадый һәм мәдәни яктан тәрәккый иттерү һәрбер татар баласының бурычы хисапланырга тиеш. Бу эш фәкать милли-мәдәни мохтарият аркасында гына гамәлгә куелырга мөмкин...* [Камал, б. 325]. Яки мөгаллим Фазлуллин, шулай ук, *иң элек милләт аякка басарга тиеш. Шуннан соң социализм турында уйларбыз*, дип белдерә. Аларга каршы Мохтар авызыннан әйттерелгән сорау (*Ул кысынкылык, ул җәфалар, ул наданлыклар милләт дигән нәрсәнең бөтен катлаулары өлешенә тигез төшкән бәхетсезлекме?* [Камал, б. 326]), милли-дини мәсьәләне «мигрень» дип атау исә капма-каршы як позициясе буларак яңгырый.

Шәхси сюжет сызыклары шулай ук билгесезлектә төгәлләнә. Большевик Гариф сугыштан Петроградка китеп бара. Газизәнең сугыштан яраланып кайткан ире Төхфәт үлеп китә. Ләкин романның исеме – «Таң атканда» – символик мәгънәгә ия булып, киләчәкнең якты булачагына ышаныч уята.

Берничә томнан торачак зур эпопеяның беренче китабы итеп уйланылган «Матур туганда» (1937) романы шулай ук Октябрь революциясе нәтиҗәсендә яңа тормыш туу барышын тасвирлый. Ул автобиографик вакыйгаларга – әдипнең Чебенледән килеп йөрүчеләр белән аларда авыл хуҗалыгы коммунасы «Матур»ны төзешүенә нигезләнә. Үрге һәм Түбән Чебенле авыллары арасындагы утар да Ш. Камал булышлыгы белән төзелү, бу яңа авылга «Дала утлары» дигән исем кушуның әдип тәкъдиме булуы да мәгълүм.

Роман сыйнфый көрәш каршылыгына корылган. Әсәр башланганда коммуна оештырып йөрүче Мостафа белән Каюм, шәһәргә

килеп, профсоюз хезмәткәре Әхмәтне дә шушы эшкә тарталар. Әхмәт ярдәме белән Садыйк байның водокачкасын коммунага алалар. Аның астына байның алтыннары күмелгән булып, язучы укучысын мавыктыргыч һәм кешеләр психологиясен (саран Садыйк бай, бер холмогор токымлы сыер хакына байга акчаларын кайтарырга вәгъдә биргән, әмма барыбер коммунарларга серне чишкән дача каравылчысы Галләметдин һ.б.) ачарга ярдәм иткән күренешләр белән иҗтимагый-сәяси вакыйгалар эченә алып кереп китә. Күмәк хезмәт, матур киләчәккә ышаныч берләштергән хезмәтчәннәрнең үзгәрүен күзәтеп барып, язучы роман исеменә чыгарган «матур» – коммуна гына түгел, бәлки дуслык, хезмәткә мөнәсәбәт, үзара ярдәмләшү, мәхәббәт һәм тигезлеккә нигезләнгән гаилә дә булып аңлашыла.

Дингә каршы көрәш, аерым сызык булып, роман буенча сузыла. Кулаклар, байлар, куштаннар – искелек калдыклары, көлке объектлары кебек сурәтләнә. Партияне һәм яңа тормыш төзү яклыларны аларга каршы куеп, язучы геройларын да идеологик яссылыктан торып иҗат итә. Шул ук вакытта бу чор тормыш-көнкүрешен бик яхшы белеп, детальләрдә, көндәлек гадәти һәм заман алып килгән көтелмәгән күренешләрдә холык-фигыльләрне ача барып, язучы укылышлы, мавыктыргыч, татар әдәбияты өчен яңа бер текст тудыра. Романның тел-стиле дә әдипнең хикәяләрендәгедән үзгә: биредәге ачык, гади, халыкчан хикәяләү, үзара сөйләшүләрнең муллыгы татар прозасында социалистик реализмның урнашуына өлге булып хезмәт итәчәк әле.

Язучының совет чоры иҗаты – татар әдәбиятында социалистик реализм методын урнаштырган үрнәк иҗатларның берсе. Ш. Камал кебек сүз остасының бу юнәлештә эшчәнлеге татар әдәбиятында, идеологик таләпләргә буйсынган хәлдә, гади кешенең тормыш-көнитешен һәм уй-хыялларын, шатлык-гамьнәрен барлык нечкәлекләре белән тасвирлау рәвешен ныгыта.

Әйтик, «Авыл матур уйлый» хикәясенең икенче өлеше буларак иҗат ителгән «Җыр тавышы ишетелгәндә» (1926), тышкы яктан караганда, татар дөньясына инкыйлаб алып килгән үзгәрешләрне үзәккә куя кебек. Әмма аны укыганда әдип каләм бөтенләй үзгә яссылыкка алып китә: яңа тормыш төзүгә ышаныч ике гаиләнең – Фәсхетдин белән Хәйбулла, Гайниҗамал белән Гайшәнең – аралашу-сөйләшүләре, үзара мөнәсәбәтләре аша калкулана, бер үк вакытта әдип гади кешеләр көнкүрешенең, кичереш-омтылышларының, үзара ярдәмләшүнең матурлыгын беренче планга чыгара.

1939–1940 елларда «Совет әдәбияты» журналында әдипнең «Ныклы адымнар» исемле яңа романы («Матур туганда»ның дәвамы) басыла башлый. Ләкин әсәр тәмамланмый кала.

### *Шәриф Камал – драматург*

Ш. Камал драматургия өлкәсендә каләм сыный: «Хаҗи әфәнде өйләнә» (1915) комедиясе, язылуга, сәхнәгә менә («Сәйяр» труппасы сәхнәләштерә) һәм шушы Ш. Камалны, прозадагы кебек үк, кеше

характерларын тирәннән тасвирлавы белән, классик драматург итеп таныта. Әсәр татар дөньясындагы тискәре бер күренешне көлеп туймаслык хәлгә әйләндерә: яшь мөгаллимә кызны алырга йөргән 70 яшьлек карт үзенең хатынына кабат «өйләнеп» куя! Хатын-кызлар хаҗины акылга утыртып, көлкегә калдырырлык зиһенле, хәйләкәр булып чыга. Шул рәвешле, комедиядә Юныс хаҗины тәнкыйтьләү генә түгел, татар җәмгыятенең мондыйлар белән көрәшә алу көче дә күрсәтелә.

1928–1934 еллар арасында Шәриф Камал драма төренә игътибарын кабат юнәлтә. Бу чорда аның бер-бер артлы «Ут» (1928), «Козгыннар оясында» (1929), «Таулар» (1931), «Томан арты» («Габбас Галин», 1934; үзгәртелгән варианты «Карчыга») исемле әсәрләре языла һәм Татар дәүләт академия театрында уңыш белән бара. «Сафура» пьесасы төгәлләнмичә кала.

Совет дәвере драма әсәрләре идеологик таләпләргә җавап бирерлек итеп эшләнгәннәр. Әйтик, «Ут» драмасында сурәтләнгән вакыйгалар НЭП чорында байларның кабат үз позицияләрен яулап алу омтылышын сурәтли. Аның герое – трест җитәкчесе Рәүф элекке миллионер кызы Галиягә өйләнә. Хатынының туган-тумачасын эшкә урнаштыра, болар исә советка каршы эш алып баралар. Моны белгән ир хатынын буып үтерә. Тарихи вакыйгаларны күрсәтү ягыннан кызык булса да, драманың ясалма каршылыгы тамашачыны ышандырмый.

«Таулар» драмасында бер завод эчендә югары урыннарга оялаган дошманнарның уртак эшкә аяк чалулары үзәккә куела. Бу әсәрләрдәге төп геройлар шәхси позицияләре ачык күренеп тормаган, үз фикерләрен якларга көчләре җитмәгән йомшак характерлар булып күренәләр.

Алардан аермалы буларак, «Томан арты» драмасындагы яшь инженер-химик Габбас Галин, чын мәгънәсендә, яңа заманның көчле шәхесе итеп сурәтләнә. Аның белән тире эшкәртү заводының сәүдә вәкиле Зөфәр Талипов арасындагы каршылык та һәм иҗтимагый, һәм хезмәт, һәм гаилә яссылыкларында кабатлана. Шуның белән әсәр әдәбият-сәнгать мәйданында уңыш казана.

Тәмамланмаган «Төеннәр» (1928) комедиясе Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә»сен хәтерләтә. Монда инде әхлаксыз типлар бирәү генә түгел. Баласын чит бер карчыкка ташлап кияүгә чыккан Рәйхан һәм аның бу хәлләрдән хәбәрдар этисе мәзин Фазлулла да, шулай ук башка хатыннан баласы барлыгын хатыны Рәйханга әйтмәгән Галиәкбәр дә, Рәйхан кызының коммунист этисе дә, мондыйлардан акча суыручы Хөбби карчык та – бар да язучының көлкеле каләм очына эләгәләр. Алдап һәм алданып яшәүче геройларының үз-үзләрен тотышларын, үзара мөнәсәбәтләрен зур осталык белән тасвирлаган драматург, асылда, бу җәмгыятьтә (совет җәмгыятендә!) аларга каршы куярлык уңай геройлар да тапмый. Күрәсең, шушы үзенчәлек әсәрнең 1928 елда – совет идеологиясе ныгыган бер вакытта язылып бетмичә калуына китергәндер.

*Публицистик иҗаты*

Ш. Камал публицистика өлкәсендә дә актив эшли. XX гасыр башының әһәмиятле мәсьәләләреннән, татар халкының хәле һәм киләчәге (Әфгале милләтә бер имкян // Нур. 1905, 2 сентябрь), белем бирү системасын үзгәртеп кору (Мәктәп вә китаплар тирәсендә // Вакыт. 1910, № 678), татар җәмгыятендә хатын-кызларга караш (Хатын-кыз мәктүпләре // Вакыт. 1910, № 653) шикелле көн кадагына суккан язмалары белән еш чыгыш ясый. Аның публицистик иҗаты Бөек Ватан сугышы чорында аеруча активлаша, тирән патриотик рух белән сугарыла.

Әдипнең XX йөз башы публицистикасы – прозасы белән бер дулкында иҗат ителүе аермачык күренә. Уртак темалар һәм мотивлар, үз заманы геройларын, ситуацияләрен ачык тергезүләре ягыннан публицистик язмалар үзләре нәсер, хикәяләргә охшап китәләр. Әйтик, фельетон жанрында иҗат ителгән «Нидер җитми иде» (1910) язмасы милләт өчен көрәш мәйданына килгән типларның берсе – демократик үзгәрешләр дулкынында кичәге мулладан, Истанбулда укып кайтып, газета-журналлар нашире һәм редакторы булып киткән, бу эштән бары тик баюны гына көткән Нәгыймнең, хыяллары барып чыкмагач, гаиләсеннән китеп, яңа бер шөгыль табуын, җырчыга әверелүен аның хатыны – бай кызы Зөбәйдә кичерешләре аша тасвирлый.

Зөбәйдәне *укымышлы гына бер яшь шәкерткә, бер хәзрәт баласына кияүгә* бирәләр. Бераз вакыт узгач, хатын хәләленең укымышлылыгына шикләнеп карый башлый: *...хәзердә аның кияве элек уйлаганча зирәк, укымышлы, серле... булмаенча, бәлки үзенең туганы төсле садәдил, серсез, хәтта ахмак кына бер малай булып күренә башлады* [Шәриф Камал, б. 46].

Иренең иҗтимагый мәйданда күренә башлавы – чит илдә йөреп кайтуы, газеталар-журналлар ачып җибәрүе яшь хатында иренә карата ихтирам хисе дә кузгатып-кузгатып куя. Әмма акыллы һәм көчле булып күренергә теләгән ирнең авырлыклар белән очрашуы аны кабат чарасызлыкка төшерә. Болар хакында беренче заттан сөйләү язучыга ачыктан-ачык көлү аша түгел, бәлки Зөбәйдә икеләнүләренә яшеренгән нечкә ирония ярдәмендә XX йөз башында Нәгыйм кебек буш, әмма бүтән рольдә күренергә теләгән яшьләрнең игътибар үзәгенә чыгуын, аларны яңарыш дулкыны сыртына күтәргән вазгыятьне тәнкыйтьләргә ярдәм итә.

«Кызыл кафтанлы» (1910) фельетоны да дөнья әдәбиятында билгеле диалогны (шайтанның кешене аздыруы) татар җәмгыятенә күчерә: заман герое Нафигъның милләт, әдәбият, матбугат кебек сүзләр белән авыз корытмаска чакырган, программаларында дин-шәригать белән чикләнергә кушкан шайтан белән сөйләшүен үзәккә куеп язылган. Шайтанның: *Син менә, гүя үз эшләрең генә җитмәгәндә, «халык эше, җәмәгать файдасы, милләт мәнфәгате» дигән булып юкны бушка тутырып йөргән буласың ич! Хәлбуки, үз эшләреңне бер дә рәтләп йөртмисең; Ә минем эшләр бар... мин дә халык эше*

*артыннан йөрим, ләкин сезнең кебек түгел, мин башка тыкрыктан һәм дә тәмам икенче юл белән йөрим!* [Шәриф Камал, б. 51–52] – дигән сүзләре, бу үзгә тыкрыкның – шәригатькә өндәү икәнлеген әйтүе билгесез затның тормыш позициясе булып та, геройның эчке җан авазы кебек тә аңлашыла ала. Шуңа күрә текстны татар дөньясындагы җәдит-кадим бәхәсе дип тә, алдынгы фикернең һәрвакыт каршылыкка, мәкергә очравы кебек тә, бу чордагы алдынгы карашлы яшьләрнең дә көнкүрешендә ике төрле фикернең – яңалыкка омтылышның һәм традицияләрне саклау мөһимлегенең – бәхәсләшүен тасвирлау буларак та укырга мөмкин.

Гомумән алганда, Ш. Камал публицистикасы XX йөз башының иң үткен мәсьәләләрен күтәрә, әмма һәрвакыт диярлек көлке алымнарына мөрәҗәгать итә. Әйтик, «Хатын-кыз мәктүпләре» (1910) фельетоны татар хатын-кызларының иҗтимагый-мәдәни тормыштагы һәм гаиләдәге хәле яхшы якка үзгәрүне күзәтү белән башлана. Моңа дәлил итеп, әдип вакытлы матбугат битләрендә басылып чыккан хатын-кызлар язган хатларга күзәтү ясый. Аның карашынча, хатын-кызларның хатларда үз хәлләреннән зарлануы, ирек, хокуклар, белем алу өчен шартлар таләп итүе – заман күренеше, табигый барыш. Ш. Камал моның заман алып килгән уңай үзгәрешләрнең иң әһәмиятлеләреннән булуын ассызыклый. Шул ук вакытта текстның ахырында көтелмәгән борылыш ясала: татар ирләренең дә хокуклары киселгән булу, шуңа күрә хатын-кызлар таләп иткән күп кенә шартларның татар ир-атларына да тудырылмавы бу юнәлештәге алгарышны туктаткан фактор буларак нечкә көлү белән искәртеп үтелә. *Фатыйма ханымнар сорасыннар иде, безнең үзебезгә, ирләргә (дарелфөнүнләрне инде әйтмисең дә) ничә генә данә мөкәммәл урта тәрбия бирерлек урыннарыбыз бар? Ул вакыт без аларга шуннан соң җавап бирер идек. Әлбәттә, оят булса да, тугрысын сөйләр идек...* [Шәриф Камал, б. 59], – дип, әдип хатын-кыз мәсьәләсенең уртак милли мәсьәләнең аерылгысыз бер өлеше генә булуына игътибар юнәлтә. Аның бу фикере татар вакытлы матбугатын тутырган, хатын-кызларга ирек даулаган язмалар фонында үзенчәлекле караш булып яңгырый.

Ирония әдипнең кайбер язмаларында ачы сатирага әйләнеп китә. Бозык имам-муллаларны фаш иткән «Хикәядән бер баб» (1910) фельетоны, заман күренеше – күпләп мәйданга чыккан ярдәм җәмгыятьләренең эш урынына буш сүзләр сөйләп вакыт уздыруыннан көлгән «Шатланырлык байтак эшләребездән бере» (1912) – шундыйлардан.

Әдипнең иң кызыклы публицистик текстлары чит битлек киеп яшәргә омтылган, башкалар карашында алдынгырак, гыйлемлерәк, халык гамен кайгыртучы булып күренергә теләгән заман геройларының тулы бер галереясын тудыра. Әйтик, «Мәктәпләр хакындагы мәктүпләрдән» (1911) язмасы мәктәп кайгырткан булып, буш мәкаләләр язучылардан көлүгә корылган. Текстта аерым газеталарда нәшер ителгән язмалар һәм аларның авторлары (Җамалетдин Мөэминбаев,

Г. Шәрифи шикелле) телгә алыну аны вакытлы матбугатка күзәтү язмасына әйләндерә. «Минем таныш» (1913) – ихлас мөселман, сәясәтче булып кыланган геройның, асылда, гап-гади бер исерекбаш булуын фаш итә. Яки «Булган вә булмаган эшләр» (1913) язмасының герое таз Вәли, мөгаллим урынына солдатка китәм, миңа бөтен халык, мәгърифәт таратучы гыйлем иясен саклап калган өчен, рәхмәтле булачак, хисләрен кире каккан Гөлбану үзе үк көтәргә вәгъдә бирәчәк, мин геройга әйләнәчәкмен дип, хыялларга бата. Текст ахырында Вәлинең үз урынында калуы, аның бу күзаллаулары – хыял гына икәнлек, мөгаллимне сугышка алып китүләре мәгълүм була. Мондый язмаларда әйтерсең лә Ш. Камал XX йөз башы татар дөньясының бер күренешен – күңелләрендә үз халкына хезмәт итү, изге эшләр башкару омтылышы янган, әмма моны тормышка ашыру өчен белеме һәм әзерлеге җитмәгән «сәер геройлар», аларның эчке бушлыкны ясалма битлек белән капларга теләвен калкуландыра, шундый типлар аша заман образын хасил итә.

Мондый геройлар Ш. Камалның 1910–1913 елларда язылган, татар җәмгыятендәге аерым күренешләр, характерлар, ситуацияләр хакында уйланырга мәҗбүр иткән юмористик һәм сатирик хикәяләрендә дә күп. Сыра эчеп, үз гомере өчен борчылудан башканы белмәгән Гайнетдин бай («Холера вакытында», 1910), мөгаллимдә үзенә конкурент күреп, әхлакка сыймас адымнар ясый торган икейөзле мулла («Авыл мөгаллиме», 1910), үзенең вазифасын да төшенмәгән депутат («Депутат», 1910) типлары – көлү катыш фаҗигалылык ярдәмендә, публицистик текстлардагы шикелле үк, татар җәмгыятенең кимчелекләрен үзенә күрсәтү максаты белән иҗат ителгәннәр.

Тәнкыйди фикер язучы публицистикасыннан 1917 ел инкыйлабыннан соң да бөтенләй үк китеп бетми. Әйтик, ««Өтер» үз урынында түгел» (1926) язмасы совет чиновникларын халык гамен түгел, бәлки үз мәнфәгатьләрен кайгыртуын тәнкыйтьли. Дөрес, әдип биредә системага сүз әйтми, «бюрократизм» дигән *Совет, хуҗалык аппаратларын зәһәрләүче бу кабахәт авыруның дәһшәт һәм куркынычлыгын аңлау өчен Ленинны укырга һәм көндәлек практик эшләрне шуңар чагыштырып карарга кирәк* [Шәриф Камал, б. 88], дигән сүзләр шул хакта сөйли.

Әмма алга таба әдип публицистикада мондый язу рәвешеннән баш тарта. Тәнкыйть зур романнарда – яшеренеп, эзоп теле белән генә аз-аз белдерелә башлый.

Публицистика мәйданында Ш. Камал күп кенә әдәби тәҗрибәләр уздыра. Әйтик, «Сугыш бәйрәме» (1912) дигән, «Вакыт» газетасында басылган мәкалә, асылда, нәсер жанрына тартым формада иҗат ителгән. Язучы аны 1812 елгы Ватан сугышында җиңүнең 100 еллыгына багышлаган, язмада әлеге җиңүнең Ватаныбызга зур даншөһрәт китерүе дә, туган җирне саклап көрәшүнең намус эше булуы да ассызыклана.

XX йөз башының типлары турында сөйләүне дәвам иткән «Чуар манзара» (1910) әсәре, жанр ягыннан хикәягә якын булса да, шулай ук публицистиклык белән сугарылган.

Дини-суфичыл эчтәлекле «Мигъраҗ» (1912) нәсере М. Гафуриның шушы кимәлдәге «Тәэссорат» (1913) нәсере, Г. Тукайның «Мигъраҗ» (1910) шигыре белән аваздаш. Әдип биредә ислам дине, андагы ышануларның кешеләр күңеленә тәэсире хакында гаять эмоциональ-тәэсирле бер формада бәян итә.

Ш. Камалның «Айлар җыелышы» (1913) – аллегория ярдәмендә татар дөньясындагы көлкегә лаек хәлләрне яктырткан әсәре дә әдәби-публицистик синтез буларак кабул ителә.

Шулай итеп, Ш. Камал – иҗаты XX гасыр башы татар прозасына бик зур йогынты ясаган әдип, аның хикәяләре реалистик яки романтик сурәт тукымасына психологик анализ үтеп керүне тәэмин итә. Аның һәр хикәясе – бер роман дәрәҗәсендә киңәергә, төрлечә укылырга сәләтле дип бәяләгән Г. Сәгъди «Шәриф Камал хикәяләре татар матур әдәбиятында аңарча булмаган яңа бер рәвеш күрсәтәләр. Шул формада хикәя язуны татарда ул иҗат итте» [Сәгъди, б. 147] диюе белән хаклы.

Татар прозасының Шәрыктан килгән форма үзенчәлекләрен: лириклыкны, табигать белән шәхесне янәшәлектә сурәтләүне, кешенең хис-кичерешләрен, омтылышларын, хыялларын, фикер үсеш-үзгәрешен тасвирлау аша тормышка бәя бирүне, символик һәм метафорик сурәт тудыруны, тирәлектәге үзгәрешләрдә кәеф-халәт көчешен тергезүне – үстереп, бу иҗат аларның XX гасыр буе милли әдәбиятта кулланылышын тәэмин итә.

Ш. Камал татар әдәбиятына яңа темалар, милли мәдәният моңа кадәр игътибар итмәгән катлаулар тормышын алып килә. Кеше концепциясе ягыннан – иң авыр сынауны кичү мәлендә сурәтләнгән геройлар шәхес күңеленең чиктән тыш матурлыгын яки түбәнлеген тасвирлап, сискәнергә мәҗбүр итә. Тормыш-көнитеш күренешләре Ш. Камал әсәрләрендә һәрчак яшәеш, кешенең хата-ялгышлары, аларның кеше холкына, киләчәгенә, язмышына тәэсире хакындагы гомумиләштерүләргә алып килерлек итеп сайлана. Мондый тирәнлеккә ирешү өчен психологик анализ, символлар, ишарәләр ярдәмгә килә. Автор идеалны геройларның хыял-өметләрендә генә таба, тормышны исә шул өметләрне җимерүче, иҗтимагый һәм мәдәни чикләүләр белән шәхеснең олы җанын вакларга әзер авырлык, шулай ук сынау кебек аңларга юл күрсәтә. Шушы сынау язучыга кеше җанының, аңының, күңеленең чиктән тыш тирән, фаҗигаларга да, матурлыкка да сизгер, нәзберек, бай булуын тасвирлау мөмкинлеге бирә.

**Әдәбият**

Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 2 томда / төз.: Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. 1 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 751 б.

*Җамал Вәлиди*. Әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз.: Д. Абдуллина, Җ. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2010. 624 б.

*Камал Ш.* Сайланма әсәрләр. Казан: Таткнигоиздат, 1954. 381 б.

*Нигъмәти Г.* Сайланма әсәрләр / төз. Җ. Нигъмәтуллина, Ә. Мәүлиханов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. 280 б.

*Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы. Дәреслек-кулланма. Казан: Татгиз, 1926. 300 б.

Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т. 3: XX йөз башы. Казан: Татар. кит. нәшр, 1986. 598 б.

*Хөсәен Барган.* Идел-Урал язучысы Шәриф Камалга Халит Зыя Ушаклыгөлнең йогынтысы / төрекчәдән Р. Сәфәров тәрҗ. // Казан утлары. 2024. № 2. Б. 173–180.

*Шәриф Камал.* Фәнни-популяр җыентык / төз. : Шәйхин А.Р., Җиһангирова Г.Р. Казан : Җыен, 2023. 416 б.

***Заһидуллина Дания Фатих кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге*
*баш гыйльми хезмәткәре*

УДК 82-14

*Л.Р. Надыршина*

# 1960–1980 ЕЛЛАР ТАТАР ПОЭМАЛАРЫНДА ЛИРИКЛАШУ ҺӘМ ФӘЛСӘФИЛӘШҮ ТЕНДЕНЦИЯСЕ (Илдар Юзеев иҗаты мисалында)

Импульс лирической и философской тенденциям в жанре поэмы в татарской литературе 1960–1980-х гг. задает возрождение классического романтизма в татарской литературе, «вернувшего» в национальное поэтическое искусство тему любви и духовной красоты. Осмысление «вечной» темы поэзии идёт по линии философизации жанра. Одним из зачинателей в этом направлении становится И. Юзеев, обратившийся в своем творчестве (как лирическом, так и лиро-эпическом) к народным традициям стихосложения, лиризму и особой мелодике. В данной статье анализируется ряд его романтических поэм («Таныш моңнар» – «Знакомые мелодии», 1955; «Мәхәббәт китабы» – «Книга любви», 1978–1979; «Әнкәй» – «Мама», 1959; «Туган ягым каеннары» – «Березы родного края», 1983) с точки зрения жанровой специфики. Автор приходит к выводу, что родовая основа жанра – эпическое – в данных поэмах рассматривается не как сюжетно-композиционная, а как содержательная категория; структурообразующим центром зачастую становится исповедальный монолог, демонстрирующий внутренний мир лирического субъекта и преломление в этом мире общечеловеческих проблем.

**Ключевые слова:** татарская поэзия, поэма, жанр, Ильдар Юзеев, образ, лирический герой, романтизм.

The impulse of lyrical and philosophical tendencies in the genre of poetry in the Tatar literature of the 1960s and 1980s sets the revival of classical romanticism in Tatar literature which «returned» the theme of love and spiritual beauty to the national poetic art. The comprehension of the «eternal» theme of poetry follows the line of philosophizing the genre. One of the initiators in this direction is I. Yuzeev, who turned in his work (both lyrical and lyric-epic) to the folk traditions of versification, lyricism and special melody. This article analyzes a number of his romantic poems («Familiar melodies», 1955; «The Book of Love», 1978–1979; «Mama», 1959; «Birches of his native land», 1983) from the point of view genre specifics. The author comes to the conclusion that the generic basis of the genre – the epic – in these poems is considered not as a plot-compositional, but as a meaningful category; the structure-forming center often becomes a confessional monologue, demonstrating the inner world of the lyrical subject and the refraction of universal problems in this world.

**Keywords:** Tatar poetry, poem, genre, Ildar Yuzeev, image, lyrical hero, romanticism.

Узган гасырның 60–80 нче еллары татар сүз сәнгатенең бөтен өлкәләрендә җанлану, үсеш чоры икәнлеге һәркемгә мәгълүм. Илдә иҗтимагый-сәяси вазгыятьнең, рухи-мәдәни яшәешнең үзгәрүенә китергән «Хрущев җепшеклеге» идеологик кысаларга кертелгән, дистә еллар дәвамында торгынлыкка дучар ителгән әдәби процесска яңа

сулыш өрә, традицион татар шигъриятенең дә «эчтәлек, хис һәм фикерне җиткерү формалары, бигрәк тә әдәби-эстетик хасиятләр ягыннан өр-яңа үзгәреш кичерү вакыты» [Заһидуллина, б. 9] башлана. Совет чорында көчләп оныттырылган Дәрдмәнд, Ш. Бабич, Ф. Бурнаш, Н. Думави, С. Сүнчәләй, идеология тегермәненә эләккән Х. Туфан, М. Җәлил кебек каләм ияләренең иҗаты әдәби барышка кайтарылу инкыйлаб сәбәпле өзелгән XX йөз башы милли әдәби традицияләрен яңартырга мөмкинлек бирә.

Бу чор сүз сәнгатендә реализм әйдәп баручы агым булып кала биреп, эпиклык, масштаблылык әле жанр үсешендә магистраль юнәлешләрнең берсе рәвешендә яшәвен дәвам итсә дә, эпик поэмаларның еш кына лирик һәм фәлсәфи чигенешләр белән баетылуы, зур вакыйгаларны аерым шәхес язмышы аша ачып бирүгә таба борылуы ачык тоемлана. Шулай ук тарихилык һәм масштаблылыкның татар халкы язмышы турындагы уйланулар белән үрелүе, әлеге чор әдәбиятында гаять популяр булган индустрияләштерү һәм урбанизация темалары яссылыгында милли һәм гомумкешелек проблемаларына кагылу да эпик поэмаларда лирик башлангычның роле көчәюгә китерә (мәсәлән, С. Хәкимнең «Үрләр аша» (1964–1968), «Дуга» (1968), Ә. Маликовның «Чигүле кулъяулык» (1985–1986) поэмалары һ.б.). Шушы процесс белән янәшә моңа кадәр күләгәдәрәк кала килгән лирик поэма үсеш ала башлый.

Гомумән, XX гасырның 60 нчы елларыннан поэманың лириклашуы процессы гомумсовет әдәби галәмен иңләп алган күренеш буларак игътибарга лаек. Поэтик текстның үзәгенә олы идеологик проблемалар куелмыйча, аерым кешенең реаль шатлык-борчулары, гамьнәре калкытылу жанр кризисы хакындагы әдәби бәхәскә дә сәбәп була, хәтта «хикәяләүгә корылган сюжетлы эпик поэманың үсеш перспективасы юк» [Михайлов, с. 57], дигән катгый фикерләр дә яңгырый.

Татар әдәби мохитендә, әлбәттә, мондый катгыйлык юк. Шулай да «жанр таләбен тоеп бетерә алмау, поэманы очерк, хикәя яки повесть ничек язылса, шулай язу, тормыш күренешләрен иң югары, шигъри моментларында гына күрсәтә алмау поэманы чырайсыз, сүлпән, кызыксыз итә» [Юзиев, 1961, б. 31], «эпик поэзиядә пафос һәм патетика белән генә образ тулылыгына ирешеп булмый» [Юзиев, 1966, б. 31] кебек күзәтүләр ясала.

Поэманы жанр ягыннан яңартуның уңышлы үрнәкләре буларак, 1950–1960 еллар чигендә «тар мәйданда сурәтләүне тыгыз итеп оештырган» [Шунда ук, б. 170] «кечкенә поэмалар» иҗат ителә башлый (С. Хәким. «Сары капкалы йорт»; Ш. Галиев. «Хупҗамал»; М. Шабаев. «Җирән Конрад»; Э. Мөэминова. «Ефәк яулыгым» һ.б.). Бу поэмаларда жанр модификациясе лиризм һәм сәнгати образлылыкның үсеше юнәлешендә бара.

1960 еллардан лирик башлангыч беренче планга чыккан поэмалар иҗат ителә башлау татар әдәби мәйданыннан озак елларга төшереп калдырылган классик романтизмның яңаруы белән алшартлана.

«Такташ рухындагы романтик шагыйрь буларак мәйданга чыккан» [Йосыпова, б. 141], «яшьлек һәм романтика, матурлык һәм батырлык җырчысы» [Даутов, б. 126] булып танылган Илдар Юзеев бу агымның иң төп вәкилләреннән санала. Т.Н. Галиуллин билгеләвенчә, элек-электән татар шигъриятенең «төп юлы халыкчан образлылыгы, лиризмы, музыкаль иҗеге һәм халык җырына, халык моңына якынлыгы белән характерлана» [Галиуллин, б. 111], романтик иҗатта әлеге сыйфатлар аеруча калку. И. Юзеевның поэма жанрында беренче тәҗрибәсе – «Таныш моңнар» (1955) әсәрендә дә бу ачык күренә. Миләүшә белән Зөфәрнең мәхәббәт тарихын сәнгатьчә гәүдәләндергән әлеге романтик поэма беренче карашка төгәл-эзлекле сюжетны бәян итү рәвешендә язылган кебек тоелса да, хисси-эмоциональ башлангычның алга чыгуы, геройларның күңел кичерешләрен үзәккә куйган күләмле лирик монологлар зур урын алып тору, яшьләрнең күңел кичерешләренә аваздаш яңгыраган җыр текстлары кертелү, текстның экспрессивлыгы һ.б. эпик нарративлыкның лиризмга буйсынуы турында сүз йөртергә мөмкинлек бирә. Поэмада моңлы җыр, гармун моңы образлары, шартлы-метфорик эчтәлек алып, Зөфәрнең рухи дөньясын, хисләр тирәнлеген бөтен тулылыгы белән ачып биргән образ булып китә: *Әллә ничек шунда, бу ялгыз җыр / Бик якын да кебек, ерак та, / Әллә ничек шунда, бу ярсу җыр / Үксеп туа кебек йөрәктә* [Юзеев, б. 14]. Алга китеп әйтик: милли яшәешнең аерылгысыз өлеше, татар халкының рухи-мәдәни кодларыннан берсе булган әлеге образлар И. Юзеевның романтик иҗат дөньясында үзәк төшенчәләрнең берсе булып китә.

Геройларның мәхәббәт коллизияләре хакында бәян итүче автор поэма вакыйгаларын үзенең күңеле аша үткәргән образ буларак күзаллана: героинясын сурәтләүдә ул артык эмоциональ дә булып китә, кайвакыт геройларының гамәлләренә битараф та кала алмый, гомумән, «үзе тудырган хисләр дөньясында яши башлый, <...> хыялы тудырган вакыйгалар эченә кереп, чынлап торып ярата, шатлана, хәсрәтләнә, үзен дә юата» [Яхин, б. 53], әмма шул ук вакытта геройларның ялгышырга, үз язмышларын үзләре корырга хокуклары булуын да аңлый, аларның тормыш борылмаларын читтән борчылып күзәтүче роле белән чикләнә дә сыман. Шул рәвешле, поэмада лирик-хисси башлангыч белән объектив хикәяләүнең үзенчәлекле синтезы тудырыла.

«И. Юзеев – гашыйк шагыйрь! Җиргә, илгә, кешеләргә, табигатькә, Идел һәм Агыйделкәйләргә гашыйк. Шуңадыр, аның күп төсмерле, кыр чәчәкләредәй гади һәм саф шигърияте бар нәрсәдән бигрәк яшьлек рухын чагылдырып килә. <...> Аның җырлары да, моңнары да, хыял-омтылышлары да, бар нәрсәдән бигрәк, Яшьлек, Мәхәббәт, Яз турында. Мәңгелек яшьлек, мәңгелек мәхәббәт һәм мәңгелек яз турында...» [Мөхәммәдиев, б. 97], – дип билгели Р. Мөхәммәдиев. Романтик әдәбиятның нигез ташларыннан булган мәхәббәт темасы, И. Юзеев иҗатында һәрдаим үзәктә торып,

«Мәхәббәт китабы» (1978–1979) дип аталган лирик поэмасында үз үсешенең кульминациясенә җитә. Мәхәббәт һәм яшәеш турындагы уйланулар үрелмәсеннән гыйбарәт әлеге поэмада күпгасырлык төрки-татар романтик традицияләрен үзенең иҗади табышлары белән кисештереп, талантлы шагыйрь мәңгелек теманы тирән фәлсәфә, олы гомумиләштерүләр белән яңача шәрехли. Композицион төзелеше ягыннан бу лиро-эпик әсәр Урта гасырлар төрки-татар әдәбиятындагы «намә» жанрына якыная һәм Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се (1353) белән ассоциацияләшә: нинди дә булса эзлекле сюжеттан, хикәялелектән азат «Мәхәббәт китабы» уртак тема белән берләшкән аерым лирик яки сюжетлы шигырьләр (мәхәббәт тарихлары) циклы рәвешендә уйланган. Кайберләре лирик субъект тарафыннан сөйләнеп, икенчеләре башка образларның күңел монологлары рәвешендә тәкъдим ителгән бу структур өлешләрнең һәрберсе кереш өлештә яңгыратылган идеяне (*Мәхәббәт ул – телдән төшми торган / иң борынгы моңлы җыр сыман* [Юзеев, б. 207]) раслау вазифасына буйсындырыла һәм автор позициясен җиткергән фәлсәфи бетем белән төгәлләнә. Авторның турыдан-туры укучысына мөрәҗәгате, аның күзәтү-нәтиҗәләре, фикер йомгагы сыман формалашкан әлеге бетемнәрнең барысы да яшәештәге караңгылыкка каршы куелган мәхәббәтне зурлау-данлауга хезмәт итә: *Һай, мәхәббәт, / колны – патша, / патшаны кол иткән мәхәббәт* [шунда ук, б. 214]; *Мәхәббәт ул – тәннең, акыл, хиснең / өлгерүе, тулып ташуы, / чынбарлыкта туган хыялларның / канатланып күккә ашуы* [шунда ук, б. 221–222] һ.б. Автор текстларына эчтәлек ягыннан мөстәкыйль өлешләрне бер төенгә төйнәү вазифасы да йөкләнгән: һәр бетем поэманың киләсе бүлегенең эчтәлегенә ишарә иткән строфалар белән төгәлләнә, шул рәвешле, поэманың структур өлешләре арасында шартлы бәйләнеш булдырыла.

Әсәрдәге урын-вакыт бирелеше дә автор фәлсәфәсе белән алшартлана. Әйтик, поэманың башлам өлешендә үк *Мәхәббәткә ничә яшь?, Бармы җирдә мәхәббәтнең башы, бармы мәхәббәтнең азагы?* дип уйга калган шагыйрь бу мәңгелек хиснең әүвәл заманнарда ук Җирне «ызгышлардан. талашлардан, тартышлардан», «нәфрәт, дошманлык, көнчелектән» коткару чарасы буларак туган илаһи хис икәнлеген аңлый: *Җан җылысы яктыртадыр диңгезен, дала, күген, / аллаларның сөюеннән ким түгел, артык түгел! / Бу гади хис, бу гали уй тик ике җанда туган, / ике җанда гына түгел, гүя җиһанда туган* [шунда ук, б. 208]. Киләсе бүлекләрдә сөйгәне белән кавышу өчен халкына хыянәт иткән хан кызы Карачәч тарихы, үткән һәм хәзергенең каршылыгын, әхлакый кыйммәтләрнең югалуын ироник пафос белән ачып биргән карт буйдак монологы, шагыйрьнең балачак дустының фаҗигалы мәхәббәте, унбиш яшьлек ананың кызына язган хаты, аерылышу чигенә җиткән ир белән хатынның гаилә драмасы һ.б. бер-бер артлы бәян ителә. Шул рәвешле, вакыт ягыннан төрле дәверләргә караган бәяннарда мәхәббәтне

югалту – кешелек яшәешенең иң олы фаҗигасы дип раслана, шул ук вакытта әлеге илаһи-мөкатдәс хискә бөтен кешенең дә лаек булмавы турындагы фикер дә махсус калкытыла: *Сөю дигән хискә лаек / бик-бик сирәкләр генә, / иң көчлеләр, иң хислеләр, / кыю йөрәкләр генә. / Сөю өчен, әйе, бары... / бары ярату кирәк, / Һәр кешедә булмый торган / сөю таланты кирәк. / Очар өчен яраксызлар, / куркаклар, канатсызлар, / үзе өчен яшәүчеләр – / һәммәсе талантсызлар* [Юзеев, б. 235].

Поэманың «Күктә язылган шигырь» дип исемләнгән бүлеге лирик субъектның эмоциональ халәтен тасвирлауга багышланган. Якты-җылы хиссият тулы бу лирик монологны каймалап алган очу мотивы аша авторның мәхәббәт – кешенең иңнәренә канат куючы (*Мәхәббәтем – барыр юлларымда / пар канатлар иде* [шунда ук, б. 233]), тормыш-көнкүрештән югарыга күтәрүче (*Илаһи рух, омтылышлар алып / ярсу хисләреңнән, / ычкындым мин кинәт Җирнең / тарту көчләреннән* [шунда ук, б. 233]), туган җир, Ватан кебек башка сакраль кыйммәтләр белән бергә кеше яшәешенең мәгънәсен хасил иткән (*Миннән бәхетлерәк йолдыз юктыр / зәңгәр чиксезлектә: / туган илем көтә, җирем көтә, / сөйгән ярым көтә* [шунда ук, б. 234]) көч булуы турындагы инанулары җиткерелә.

Поэманың соңгы бүлеге кереш өлешнең дәвамы буларак укыла: сугышлар, кешеләрнең үзара дошманлыгы, җансызлыгы аркасында яңадан танымаслык булып үзгәргән Җир газаплары турындагы лирик монолог шәкелендәге бу өлештә лирик субъектның кешелек киләчәге хакындагы борчулы гамьнәре алга чыга. *Сөю хисен әгәр югалтмаса, / Җир суынмас мәңге, / Җир яшәр!* [шунда ук, б. 238] – дип тәкрарлап, ул сөйгән ярга, ата-анага, балага, Ватанга, гомумән, кешелеккә булган мәхәббәтнең яшәеш тамыры булуын тагын бер кат ассызыклый. Әнә шул рәвешле, шагыйрь тирән мәгънәле фәлсәфиләштерүләр юлына чыга.

Югары хисләрнең, мәхәббәтнең илаһи көчен данлау белән бергә, И. Юзеевның лирик поэмаларында сентиментальлек тә көчәя бара. «Әнкәй» (1959) поэмасы – шуның ачык мисалы. Поэма туган җиреннән читтә гомер кичергән лирик геройның күңел монологы формасында корылган. Аның әнисен сагынуы, аннан хәбәр булмауга борчылуы, ананың авыру хәбәрен алып, гасабиланып юлга ашкынуы, авылына кайту юлындагы авыр-хәсрәтле хатирәләре, әнкәсе белән күңелдән сөйләшүләре, җитәрлек кадерләмәвенә үкенүе – болар барысы да лирик сюжет өлешләре булып торалар.

Лирик поэмага хас ирекле композиция мөмкинлеген киң файдаланып, шагыйрь әсәрне вакыт һәм урын ягыннан киңәйтә: лирик геройның уйлары әле үткәнгә – ананың хәсрәт-сынаулы язмышына, әле томанлы киләчәккә йөгерә. Ахыры күренмәс сыман тоелган кайту юлында лирик геройны бары өмет яшәтә: *«Хәлең ничек?» диеп сораучыга / «Бик әйбәт!» дип дәшик, әнкәем. / Тынычлыкның кадерен белеп кенә / Озак-озак яшик, әнкәем!* [шунда ук, б. 69]. Шул рәвешле,

лирик характерны ачып бирү, аның эчке каршылыгын күрсәтү аша, шагыйрь кешенең яшәешен мәгънәле иткән кыйммәтләр турында уйландыра. Сәнгать чаралары, сентименталь чигенешләр, эмоциональ киеренкелек ярдәмендә И. Юзеев яшь геройның үкенүле гамьнәрен бөтен тулылыгы белән ача, яшьлек ашкынуыннан битарафлыкка бер адым булуын искәртә. Шушы фәлсәфи уйланулар юл образының мәгънәви кырын төрле семантик төсмерләр белән баета: бу – туган җиргә, нигезгә кайту юлы да, шәхеснең яшәү мәгънәсенә төшенүе дә, мәңгелек вакыт агышында кешелекнең бер юлчы гына булуына ишарә дә.

Поэманың үзәк образын – Ананы тасвирлауда шагыйрь күпсанлы эмоциональ-экспрессив сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итә (Ананың сулышы җылы, чәчләре ромашкадай ап-ак, йөрәге ташлар эретерлек җылы, сөю дөньядагы барлык диңгезләрдән киң һәм тирән...), аны Ана архетибына хас сыйфатлар белән тулыландыра: сабырлык (*Әнкәй түзгән барлык сынауларга, / Ул чыдаган, чыдый һәм чыдар!* [Юзеев, б. 61]), мәрхәмәтлелек (*Ташлар эретерлек / Йөрәк җылың / Яна-яна / миңа күчкәндер* [шунда ук, б. 61]), корбанчыллык (*Коры суык. Ләкин ана туңмый, / Ана бала белән җылына. / Мамык шәлен сатып икмәк алды / Өйдә калган төпчек улына* [шунда ук, б. 65]), нәсел утын сүндермичә саклау (*Сөйләмә дә телең калдырып, / Нигеземне, / Атам-бабам йортын / Ничек итеп китим калдырып* [шунда ук, б. 60]).

«Әнкәй» поэмасында билгеләнгән рухи кыйммәтләр чылбыры (әни/гаилә – нигез – туган җир – Ватан) И. Юзеевның «Туган ягым каеннары» (1983) поэмасында да үстерелә. Әсәр туган ягын данлауга зур өлеш керткән, әмма эшендә «янып», иртә җир куенына кергән Фәндүс образы ярдәмендә бер үзәккә тупланган шигъри цикл формасында иҗат ителгән. Авторның әсәрдә аерым персонаж буларак «яшәтелүе» лирик герой һәм шагыйрь арасындагы чикләрне юа: поэма якын кешесен югалткан шәхеснең реаль хисләре, күңел зары, сызлану-моңнары буларак укыла. Һәрберсе Фәндүснең шәхесен яңа яктан – туган, дус, гаилә башлыгы, җитәкче, туган җирнең тугры улы һ.б. буларак ачкан сигез бүлекне сызланулы юксыну – бакыйлыкка бик иртә күчкән якыннарны, үткәндә калган ваемсыз бәхетле балачак һәм яшьлек елларын, туган җирне, нигезне сагыну хисе иңләп уза. Конкрет шәхескә багышлап язылуына карамастан, поэма гомумкешелек проблемаларын калкыта: Фәндүс биографиясеннән теге яки бу сәхифәне укучыга тәкъдим итеп, автор туганлык җепләре, әхлаклылык, яшәү мәгънәсе, нәсел хәтере, туган җир кыйммәте турында уйландыра, җәмгыятьтә матди кыйммәтләрнең өстенлек итә баруы, экологик фаҗига куркынычы һ. б. хакында кисәтә. Фәлсәфи тирәнлек белән ачылган шушы проблемаларга, автор фикеренчә, буыннар арасындагы бәйләнешләрне саклау, туган җирне ярату һәм аның каршында җаваплылыкны онытмау ярдәмендә генә каршы торырга мөмкин.

Поэмада шагыйрьнең туган авылы Ямады рәвешендә төгәлләштерелгән туган җир образы милли дөнья сурәтендә зур урын алып торган традицион каен образы ярдәмендә тулыландырыла: *Каеннарым арттан калмый чабалар инде, / Ерагая аралар инде, / Киткән саен якыная баралар инде, / Сагынудан дәвалар инде. <...> // Гомерем буе миңа таба чабарлар инде, / Кайтмый һич тә калалмам инде* [Юзеев, б. 166]. Димәк, язмыш юллары кешене кая гына илтеп ташласа да, нинди генә дәрәҗәгә ирештерсә дә, кешенең хәтере һәрвакыт туган җиренә, нигезенә береккән булырга тиеш, хәтерне оныту рухи югалуга китерәчәк – бу идея И. Юзеевның иҗатында гына түгел, тулаем шушы чор татар шигъриятендә лейтмотив булып уза.

Лирик хикәяләү барышында каен образының тагын бер мәгънәсе ачыла: кайчандыр Фәндүснең әтисе тарафыннан утыртылган каеннар (биш баласына – биш каен) нәсел чылбырының өзелмәве, буыннар арасындагы бәйләнешләрнең ныклыгын гәүдәләндерә. Шагыйрьнең энесенә – Фәндүснең улына әйткән сүзләре шушы яссылыкта шәрехләнә: *Әткәң нигезендә үз көең тап, / Көйсез бу тормышның җаен бел, / Ак каеннар Фәндүс кебек булсын, / Син үзең дә, энем, каен бул!* [шунда ук, б. 183]). Ата-бабалар хәтерен саклау, рухи кыйммәтләрне алдагы буыннарга тапшыру – яшәешне мәгънәле иткән төшенчәләр, шагыйрь раславынча, әнә шул. (Киләчәктә туган як, туган җир, авыл язмышы турындагы уйланулар милләт яссылыгына күчерелеп, хис катламында татар халкының киләчәге хакында борчулы сызланулары алгы планга чыккан мондый лирик поэмалар Х. Әюп иҗатында аерым көч белән үсеп китәчәк.)

Гомумән, И. Юзеевның мәкаләдә анализланган һәрбер әсәре 1960–1980 еллар татар поэмасының лириклашу һәм фәлсәфиләшү юнәлешендәге жанр үзгәрешләрен күзалларга мөмкинлек бирә. Эпик поэмалардан аермалы буларак, мондый әсәрләрдә эзлекле хикәяләү, вакыйгалылык хис-кичерешләрне сөйләп-шәрехләп бару белән алмашына, яшәеш-чынбарлык вакыйгалары лирик геройның күңеле аша үткәрелә, аның рухи дөньясы алгы планга чыгарыла. Иҗатының тәүге дәверендә язган «Таныш моңнар» поэмасыннан ук үзен романтик шагыйрь итеп таныткан әдип аннан соң иҗат иткән поэмаларында инде олы фәлсәфи гомумиләштерүләргә сәләтле, интеллектуаль укучысы белән гамьле әңгәмә алып баручы фикер иясе буларак ачыла. Фәлсәфи як тирәнәя барып, аңа форма өлкәсендә эзләнүләр кушылып, поэма жанрында модернистик тәҗрибәләр хасил була («Таш диварлар авазы», 1971–1991; «Тынлык белән сөйләшү» (1966–2000 һ. б.). Шул ук вакытта соңрак язылган «Өзелгән тәсбих» (1989), «Татар моңы» (1997) кебек әсәрләр И. Юзеев иҗатында лирик поэма жанрының үзгәртеп кору чорында да үстерелүен раслый.

**Әдәбият**

*Галиуллин Т. Н.* Безнең тормыш – үзе җыр: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 152 б.

*Даутов А.И.* Илдар Юзеев шигъриятендә романтизм. Казан: Интелпресс, 2002. 152 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

*Йосыпова Н.М.* XX гасырның икенче яртысы татар шигърияте: традицияләр һәм яңачалык. Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2021. 296 б.

*Михайлов А.В.* Умчался век эпических поэм // Литературное обозрение. 1973. № 7. С. 53–57.

*Мөхәммәдиев Р. С.* Якутлар табыладыр вакыт белән. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 216 б.

*Юзеев И.* Сайланма әсәрләр: 5 томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 400 б.

*Яхин А.* Болытлар артындагы кояш // Илдар Юзеев: истәлекләр, әңгәмәләр, шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 52–57.

***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Г.Р. Гайнуллина*

# ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ 1980–1990 ЕЛЛАР ПУБЛИЦИСТИКАСЫ

В данной статье рассматривается публицистика татарского классика Амирхана Еники 1980–1990-х годов. Рассуждая о современниках, писатель делает вывод, что судьба каждого – отображение той исторической эпохи, когда они жили и творили. Анализируются статьи А. Еники, посвящённые великим татарским личностям – Г. Тукаю, Б. Урманче, Н. Таждаровой, Х. Сарьяну и т.д., а также проблеме методики преподавания татарского языка в средней школе. Основное внимание уделяется высказываниям татарского классика о величии татарского народа, об утратах, необходимости сохранения наследия великих для потомков. Целью статьи является изучение проблем, отображённых в публицистике 1980–1990-х годов классика татарской литературы А. Еники. Анализ публицистики А. Еники привел к выводу о том, что в постсоветское время остро ставилась писателями проблема сохранения наследия классиков, также татарского языка.

**Ключевые слова:** А. Еники, Г. Тукай, Б. Урманче, Н. Таждарова, Х. Сарьян, публицистика, рецензия, статья.

This article examines works of the Tatar classic Amirkhan Yeniki of the 1980s and 1990s. Talking about his contemporaries, the writer concludes that the fate of everyone is a reflection of that historical epoch when they lived and created. The article analyzes the articles by A. Eniki devoted to the great Tatar personalities – G. Tukai, B. Urmanche, N. Tajdarova, X. Saryan, etc., as well as the problem of the methodology of teaching the Tatar language in secondary school. The main attention is paid to the statements of the Tatar classic about the greatness of the Tatar people, about the losses, the need to preserve the heritage of the great for future generations. The purpose of the article is to study the problems reflected in the journalism of 1980–1990 by the classic of Tatar literature A. Yeniki. The analysis of A. Yeniki's journalism led to the conclusion that in the post-Soviet period, writers acutely posed the problem of preserving the heritage of the classics, as well as the Tatar language.

**Keywords:** A. Yeniki, G. Tukai, B. Urmanche, N. Tajdarova, H. Saryan, journalism, review, article.

Татар әдәбиятының йөзек кашы, язучы, публицист Әмирхан Еники (1909–2000) мирасының әһәмияте иң элек милли нигезләргә кайту дәвере әдәбиятын формалаштыру, «язучылар иҗатында дәвам итәчәк авангард эзләнүләрнең чишмә башы булу, милли әдәбиятны яңа сыйфат үзгәрешенә китерү» [Заһидуллина, б. 157] буларак билгеләнә.

Ә. Еникине публицист буларак бәяләп, әдәбият галиме Фәрит Хатыйпов болай ди: «Рецензияләрдә авторның интеллектуаль байлыгы, фикерләү тирәнлеге, күз үткерлеге, характерлау төгәллеге, иң кирәклесен тотып ала белүе күренә. Мәкаләләрдән талантны олылау,

ихлас хөрмәтләү хисе бөркелә. Алар кыска, җыйнак булсалар да, бик тыгызлар, фикерләр масштаблы, җитди, тирән, һәр мәкалә берәр мөһим мәсьәлә тирәсендә оешкан, укучыны ияртеп барырлык, мавыктыргыч итеп төзелгән» [Хатипов, б. 146]. Мәгълүм булганча, Ә. Еникинең 1960–1980 еллар публицистикасының төп темаларыннан берсе – остазлар, татар әдәбиятының аксакаллары, классик әдипләр һәм аларның иҗатына мөнәсәбәт [Гайнуллина, б. 56]. Бу урында язучы тәнкыйте өлкәсе бүгенге көндә әдәбият гыйлемендә шактый өйрәнелә килүенә басым ясап үтү зарур [Гайнуллина, Гыйлаҗев, Закирҗанов, Сәйфуллина, Минһаҗева, Каюмова].

Ә. Еники 1980–1990 елларда, нигездә, әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнә. Бу чорда тупланган тәнкыйди мәкаләләре ике гасыр чигендә «Кояш баер алдыннан» (1996), һәм «Биектән карап торасым килә...» (2009) дип исемләнгән китаплар булып дөнья күрә. Тәнкыйди мәкаләләр тупланган җыентыкларында Ә. Еники татарның бөек шәхесләре турында истәлекләрен тәкъдим итә, иҗтимагый мәсьәләләргә үз карашларын белдерә.

«Мәгънәле яшәү» (1987) исемле мәкаләсе татар профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салучы, рәссам, график, һәйкәлтараш һәм архитектор, Россиянең һәм Татарстанның халык рәссамы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Габделбакый Идрис улы Урманченың 90 яшьлек юбилее уңаеннан язылган. Ә. Еники бер дә икеләнмичә аны татарның милли сынлы сәнгатен тудыручы дип атый [Еники, 2009, б. 21]. Язучының скульпторга күрсәткән чиксез хөрмәте аерымачык күренә, чөнки ул аны яңа әдәбият һәм сәнгатьнең үстерүчеләре, бөек шәхесләр – Г. Тукай, Г. Кариев, С. Сәйдәшләр белән бер рәткә куя. Бакый Урманченың 100 яшьлек юбилее уңаеннан 1997 елда Ә. Еники «Шәхес» дип исемләнгән мәкалә яза. Биредә язучы танылган шәхес белән танышу тарихын сөйләп уза, төрле истәлекләргә мөрәҗәгать итә, кыска гына биографик өзекләр китерә. Ә. Еники сүзләре буенча, Б. Урманче белән аны «күп мәсьәләләрдә уртак фикер, уртак караш булу» берләштерә [Еники, 2001, б. 300]. Н. Исәнбәтнең бәясен китереп, әдип Б. Урманченың татар мәдәнияте үсешендәге ролен мәңгелеккә уеп сала: «Бездән татар поэзиясе һәм музыкасының нигезләрен салучылар кемнәр?» – дип сорасалар, без Тукай белән Сәйдәшне атыйбыз. Инде татар сынлы сәнгатенең нигезен салучы кем дип сорасалар, без Бакый ага Урманче дибез. Димәк, өчәүнең берсе» [Еники, 2001, б. 300].

«Озын гомерле дуслык» (1993) дип исемләнгән мәкалә әдәбият галиме, язучы, драматург, тәнкыйтьче Ибраһим Нуруллинның гомер бәйрәме уңаеннан языла. «Үзенчә уйлаучы, үзенчә күрә белүче» [Еники, 2001, б. 89], – дип сыйфатлый аны әдип. Ә. Еники Ибраһим Нуруллинның татар мәдәниятенә, аерым алганда, Г. Исхакый исемен кайтаруга керткән өлешен аерып куя.

«Ялганны яклау» (1992) – язылу вакытыннан егерме ел элек Тукай клубында үткән җыелышка мөнәсәбәтле эшләнгән мәкалә.

1971 елда Казан университетында философия кафедрасы мөгаллиме З.А. Ишмөхәммәтов «Тукай атеизмы» дигән китап бастыра. Ә. Еники бу язмасында китаптагы фикерләргә мөнәсәбәтле генә түгел, Тукай шәхесе, шагыйрь яшәгән дәвер турында уйлана. Язучы үз фикерләрен кыю белдерә һәм аларны шагыйрь иҗатыннан алынган мисаллар белән дәлилли. «Тукай бит ул татар халкының көчле уяну вакытында мәйданга күтәрелеп чыккан һәм милли азатлык белән гаделлекне үзенең иҗатында бик нык үрә белгән шагыйрь», – ди язучы [Еники, 2001, б. 106]. Тукай клубындагы җыелыш әдипнең өметләрен акламый гына түгел, ул аннан «рухи кыйналып, тәмам ватылып кайта» [Еники, 2001, б. 112]. Ә. Еники каләмдәше Сәйфи Кудашка хат язып җибәрә, аңарда теләктәшлек сизә, озак та үтми утыз битлек тулы җавап ала. «Сәйфи агай да Тукайның Аллага иманган һәм сыенган шагыйрь булуын раслый, шуны күп дәлилләр белән исбат итә», – дип билгеләп үтә [Еники, 2001, б. 115].

«Сарьян» (1990) исемле мәкаләсен язучы Хәсән Сарьянга багышланган истәлекләр кебек эшли. Ул каләмдәшенең вафатыннан соң, аңа 60 яшь тулу уңаеннан язылган. Әдип якташының үлеме белән бәйле үкенечен сиздерә: «Бу шулхәтле көтелмәгән, акылга сыймас бер мәгънәсез хәбәр булды ки, гүя башка төшкән кирпеч шикелле, ул мине тәмам һушсыз итә язды» [Еники, 2001, б. 71]. Мәкаләдә язучы Х. Сарьянның эчке дөньясына, холык-фигыленә, каләмдәшен борчыган мәсьәләләргә зур урын бирә. Ә. Еники Сарьянның әдәби иҗатының «җәелеп кенә» үсеп китә алмау сәбәпләре турында уйлана, «җан тынычсызлыгы һәм канәгатьсезлек кайдан ул, нәрсә аркасында, ничек туган?» – дигән сораулар куя [Еники, 2001, б. 72]. «Чын талант, хис кешесе, сәнгатьне тирән аңлаучы, әсәр язуның да бөтен нечкәлекләрен белә, әмма үз ишләреннән характеры белән нык аерыла иде үзе» [Еники, 2001, б. 72], – дип уртаклаша. Ә. Еники «каршылыклы заманның бер корбаны» дип атый Х. Сарьянны һәм «вакытсыз киткәннәр алдында без һәрвакытта бурычлы!» – дигән нәтиҗә ясый [Еники, 2001, б. 78].

«Нәгыймә Таҗдарова» (1997) мәкаләсе, асылда, 1945–1946 елларда ук эшләнә һәм китап буларак дөнья күрә. Бу вакытта Нәгыймә ханым әле исән була, ләкин каты авырый. Ярты гасыр үткәннән соң, Ә. Еники яшь буынны күренекле шәхес, талантлы артистка белән таныштыру максатыннан язманы тагын бер тапкыр бастырырга була. Ул артистканың иҗади тормышын җентекләп өйрәнә. Язманың башлам өлешендә аның портретын тасвирлый: «арык кына гәүдәле, зифа буйлы, ак чырайлы яшь ханым». Аннары танылган актрисаның тормышына тулы анализ ясап, кылган гамәлләре, уйнаган рольләре һәм яшәү позициясеннән чыгып, тулы тасвирлама бирә: «...Ул – реалистик стильдәге драматик актриса. Үткер, айнык акыллы, тирән интуицияле, индивидуаль сыйфатларга бай булган, чын мәгънәсе белән олы талантлы һәм киң диапазонлы сәхнә остасы. Тышкы билгеләре белән ул уртача буйлы, юка гәүдәле, ак озынча чырайлы, түбән

күкрәк тавышы белән сөйли, дикциясе аның бик чиста һәм ачык. Характеры белән исә сабыр холыклы, ихтыяр көченә ия, кешеләргә карата кешелекле һәм гаҗәп тыйнак, намуслы бер кеше иде», – дип яза әдип [Еники, 2001, б. 335]. Ә. Еники карашынча, Н. Таждарова авыр, хәсрәтле балачак, фаҗигалы яшьлеккә дучар ителүгә карамастан, яраткан эшенә бөтен гомерен багышлый алган, куелган максатларына ирешер өчен бар нәрсәгә дә әзер булган чын профессионал һәм яшь буын өчен үрнәк булып кала.

«Ченәкәй кем ул?» (1998) исемле мәкалә «әдәбияттан сызылган шагыйрь» Төхфәт Ченәкәкәйгә багышланган [Еники, 2001, б. 360]. Ченәкәй турында сөйләгәндә, әдип аны «шагыйрь дусты» Муса Җәлил белән янәшә куя. Ә. Еники уйлавынча, М. Җәлилнең «фаҗигалы корбан» булуы аны «күкләргә күтәрә» һәм «Ченәкәйне әдәбияттан бөтенләй сызып ташлауга китерә» [Еники, 2001, б. 361]. Билгеле булганча, Т. Ченәкәй «Хөсәения» мәдрәсәсендә тел һәм әдәбият укытучысы булып эшли, «буйга кечкенә шәкерт» Мусаның беренче хәлфәсе һәм, язучы уйлавынча, аңа «шигырь язу турында нindидер киңәшләрен дә биргән кеше» була [Еники, 2001, б. 362]. Ул елларда ике шагыйрь арасында дустанә мөнәсәбәтләр дә урнаша, ләкин озакка түгел. Октябрь инкыйлабы икесен ике төрле юлдан алып китә. «Шагыйрь шәкертне революция дулкыннары үзенә суырып ала, – дип яза әдип. – Мусаның гаҗәп тиз күтәрелә башлавын күрәбез» [Еники, 2001, б. 362]. Т. Ченәкәй исеме тарих битләреннән төшеп кала, юыла. «Онытылган шагыйрьнең» исемен кайтарыр өчен Язучылар берлеге рәисе И. Гази, Ченәкәйнең җыентыгын чыгарырга ниятләп, Ә. Еникине Үзбәкстанга материал тупларга җибәрә. «Игътибарга лаеклы бер генә кәгазь дә таба алмадым», – дип яза әдип [Еники, 2001, б. 365]. Шуңа да карамастан, Ә. Еники берничә ай утырып, бик җентекләп-чүпләп, нәшриятка тулы гына бер җыентык әзерләп [Еники, 2001, б. 366] тапшыра. Әмма ул вакыттагы Язучылар берлеге рәисе И. Гази үлеп китә һәм бу эш туктала. Ләкин Ә. Еники бервакытта да Т. Ченәкәйне татар халкына таныту максатыннан читләшми.

«Башбаштаклык» мәкаләсе Нурихан Фәттахның «Ирек булгач башбаштак» исемле хезмәтенә багышланган. Заманында Н. Фәттах хәзерге әдәби телдә бик еш кулланыла торган гарәп алынмаларына карата тискәре мөнәсәбәтен белдерә. Н. Фәттах, Ә. Еникиләр телне саклау кирәклеген әйтәләр: «Тел мәсьәләсе – ул безнең язмыш мәсьәләсе», – дип яза Ә. Еники [Еники, 2001, б. 138].

Гомумән, әдипнең публицистик язмаларында милли әдәбиятның киләчәге, урта мәктәптә әдәбият укыту, туган телдә белем бирү мәсьәләләре хакында фикерләр еш яңгырап тора. Биредә Ә. Еникинең татар мәгарифенә мөнәсәбәтле «Татар баласына урысча белмәү куркынычы янамый» (1998) мәкаләсендә урын алган фикер-карашларына тукталыйк.

Мәкаләдә аң-белем мәсьәләсенә карашлар җәмгыятьтәге милли вазгыятькә бәйле яктыртыла: «Тел мәсьәләсендә минем карашым

менә нидән гыйбарәт: татар халкының кимендә яртысы үз телен (ана телен) югалтты. Сәбәбе билгеле: большевиклар партиясенең вак халыкларны, аеруча безнең татарны, әкренләп урыслаштыру сәясәте иде... Хрущев вакытында ук Татарстан шәһәрләрендә, шулай ук күрше өлкәләрнең авылларында да татар мәктәпләре ябылып бетте диярлек...Казанда, мәсәлән, татар балаларының 93 проценты урыс мәктәпләренә күчте. Утыз ел буена без балаларыбызны ана телендә укытудан мәхрүм булып тордык. Шул вакыт эчендә урыс мәктәпләре аша узган берничә буын үз телен онытты, урыс теле генә төп тел булып калды» [Еники, 2001, б. 155].

Язучы бу «фаҗигадан чыгу юлын» мәгариф системасында күрә: «Менә шул фаҗигадан ничек чыгарга?.. Моның өчен туган телебезгә яңадан кайту кирәктер. Ә кайтыр өчен татар балалары һәммәсе дә (100 проценты белән) бары тик ана телендә укый башларга тиеш... Бөтен дөньяда ул шулай – һәр милләт баласы иң элек үз телендә укырга-язарга өйрәнә...» [Еники, 2001, б. 155].

Ә. Еникинең милли вазгыятькә мөнәсәбәте, карашлары ачык: «Безгә дә шул максатка ирешер өчен, беренче нәүбәттә, башлангыч мәктәпләрне тизрәк ачарга һәм аларның саннарын да күбәйтергә кирәк иде. Бу хакта мин «үзгәртеп кору» башлангач та язып чыккан идем. Ләкин ни сәбәптер баштарак моңа юньләп игътибар итүче дә булмады... Ә соңрак инде «нигә башлангыч мәктәп» кенә? «Юк, безгә татар гимназияләре, татар университетлары да кирәк», – дип бик ялкынланып китүчеләр дә булды... Әмма адәм баласы укуын университеттан башламый, мәктәпнең беренче сыйныфыннан башлый. Сүз бит яшь буынны «манкорт» булудан саклап калу турында бара! Шуннан соң 10–15 ел вакыт үтеп китте, ә без туган телебезнең язмышы турында һаман баш ватудан, бәхәсләшүдән узганыбыз юк...» [Еники, 2001, б. 155]. Сүз иярә сүз, язучы Казан мәктәпләрендәге туган телдә укытуга мөнәсәбәткә бәйле борчуын аерып җиткерә.

Әдипнең туган телне саклап калуга мөнәсәбәтле фикерләре аермачык, төгәл, системалы. Мәкаләдә яшь буында милли үзаң тәрбияләү, туган телебезне саклау юлында мәгариф системасы ничек катнашырга тиешле, ана телен укыту методикасына бәйле әдипнең карашлары түбәндәгечә җиткерелә: «Бу мәсьәләдә мин һаман иске карашымда торам... Мәгәр кайбер яңа тәкъдимнәр дә өстисем килә.

1. Балаларны ана телендә укыта башлау безнең Татарстанда, махсус закон нигезендә, мәҗбүри булырга тиеш. Кабатлап әйтәм: сүз укыта башлау турында гына бара. Ягъни бала үз телендә камил укый-яза белгәнчегә кадәр... Моның өчен дүртьеллык башлангыч мәктәпне тәмамлау җитәчәк. Шуннан соң баланың теләсә нинди телдә укуын дәвам иттерергә хакы булырга тиеш.

2. Татар балаларын урыс мәктәпләренең башлангыч сыйныфларына кабул итми торырга... Иң элек ул татар мәктәбенә барырга тиеш. Аннары урыс телен татар мәктәбендә дә өйрәнәчәкләр. Ләкин

беренче класстан ук түгел, яшь балага берме-икеме ел фәкать үз телен генә укыту кирәк.

3. Татар мәктәбе үзенә аерым булырга тиеш... Балаларны чорнаган мохитнең да «татарча» булуы кирәктер, мөгаен... Өч-дүрт урам саен бер башлангыч мәктәп булсын иде... Аңа зур биналар кирәкми, әнә Казанны уратып алган меңнәрчә ике-өч катлы коттеджлар да ярый торгандыр, минемчә... Бу изге эшкә хөкүмәт акча табарга тиеш» [Еники, 2001, б. 156].

Әдәби иҗатында да, публицистикасында да әдип татар шәхесләрен тәрбияләүдә XX гасыр башы милләт хадимнәре үрнәген мисал итеп китерә. Аның карашынча, туган телдә белем алу кешенең шәхес буларак оешу-формалашуы юлында иң әһәмиятле факторлардан: «Минем бу тәкъдимнәремдә яңалык юк диярлек. Татарның белемгә юлы ана теленнән башланган. Үзебездәге мәктәп-мәдрәсәләрдән соң, әгәр теләсә, югары белемне чит илләргә барып алган (Истанбулга, Бәйрутка, Каһирәгә, хәтта Сорбоннага). Әмма инде туган телен бервакытта да онытмаган. Бу җәһәттән олы шәхесләребезнең белем юлы – безгә бик матур үрнәк!..» [Еники, 2001, б. 156].

Боларга өстәп, әдип «гамәлдә никадәр күбрәк кулланылса, тел шулкадәр камилләшәчәк» [Еники, 2001, б. 156] дигән фикерне ассызыклый: «Татар һәм урыс телләре дәүләт теле булып саналгач, без шул ике тел белән әйбәт кенә яшәргә тиешбез... Әмма татар теленең ролен көчәйтү бик кирәк. Мәсәлән, халыкның 70–80 проценты татарлардан гыйбарәт районнарда идарә итү эшләре татар телендә барырга тиеш. Бу бик законлы булачак. Шулай ук дәүләт органнары тарафыннан чыгарылачак һәртөрле карар, законнар да башта татар телендә язылып, соңыннан русчага тәрҗемә ителергә тиеш. Телне эшләтә белергә кирәк» [Еники, 2001, б. 156]. Методист галимнәрнең хезмәтләрендә Ә. Еники күтәргән татар телен укыту проблемалары бүген дә яктыртыла килә [Юсупова, Юсупов].

Шул рәвешле, әдип яшь буында милли үзаң тәрбияләү башлангыч һәм урта мәктәптә туган телдә белем бирү белән бәйли, бу хакта фикер-карашларын кыю җиткерә.

Ә. Еникине татарның бөек шәхесләренең мираслары, исемнәре саклану мәсьәләсе борчый, һәр язмасында ул татар теленең саклануы проблемасын ассызыклый.

**Әдәбият**

*Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 5 т.: 1917–1956 еллар / [фәнни мөх. Д.Ф. Заһидуллина]; [төз. Р.Ф. Рахмани]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. 623 б.

*Гайнуллина Г.Р.* Әмирхан Еники публицистикасында иҗат әһелләренә хас сыйфатлар турында // Фәнни Татарстан. 2019. № 2. Б. 55–63.

*Гайнуллина Г.Р.* Образ Амирхана Еники в публицистике Фоата Галимуллина // Филология и культура. Philology and Culture. 2021. № 1(63). С. 163–168.

*Гыйлаҗев Т.Ш.* Татар әдәби тәнкыйте (1920–1930 еллар). Казан: Отечество, 2016. 240 б.

*Закирзянов А.М.* Основные направления развития современного литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). Казань: Ихлас, 2011. 320 с.

*Сайфулина Ф.С.* Культурные и общественно-политические события начала XX века в публицистике Ибрагима Биккулова // Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика: материалы Международного научно-практического семинара, посвящённого 145-летию со дня рождения классика татарской литературы Гаяза Исхаки / сост. Л.Р. Надыршина. Казань: ИЯЛИ, 2023. С. 273–276.

*Nureeva G.L., Kayumova G.F., Mingazova L.I., Petrov, A.V.* Mythopoetic and realistic image of the native land in the works of modern writers// International Journal of Criminology and Sociology. 2020. 9, S. 1072–1076.

*Еники Ә. Н.* Биектән карап торасым килә. Казан: Мәгариф, 2009. 215 б.

*Еники Ә.Н.* Әсәрләр: 5 томда. 5 т.: Публицистик язмалар, мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 479 б.

*Юсупова Н.М., Юсупов А.Ф.* Проблемные аспекты в преподавании татарской литературы // Филология и культура. 2023. № 1 (71). С. 167–172.

*Статья написана и опубликована при финансовой поддержке РНФ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта «Проведение фундаментальных научных исследований и поисковых научных исследований малыми отдельными научными группами» (региональный конкурс)» № 24-28-20211*

***Гайнуллина Гөлфия Расил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*

УДК 82-2

***Ф.Х. Миңнуллина***

# ШАМИЛ УСМАНОВ ДРАМАТУРГИЯСЕ

Статья посвящена изучению драматургии 1920–1930-х годов Ш. Усманова, где раскрывается своеобразие пьес в аспекте концепции эпохи и героя. Выявлена динамика характеров героев по принципу «героя порождает эпоха». Автором статьи показана эволюция авторской концепции эпохи и героя, определены особенности эпохи и связь времён. Через жанровый и образный анализ воссоздается историческая и художественная картина действительности.

**Ключевые слова:** драматургия, жанр, герой, драма, история.

The article is devoted to the study of the dramaturgy of the 1920–1930s by Sh. Usmanov, which reveals the originality of the plays in terms of the concept of the era and the hero. The dynamics of the characters of the heroes is revealed according to the principle of «the hero is generated by the epoch». The evolution of the author's concept of the epoch and the hero is shown. The features of the epoch and the connection of the times are determined. Through genre and figurative analysis, the historical and artistic picture of reality is recreated.

**Keywords:** drama, genre, hero, history.

1917 елгы революция һәм Гражданнар сугышы еллары халыклар мәдәниятен үстерү өчен катлаулы һәм фаҗигалы чор булып тора. Бу шаукымлы елларда Г. Исхакый, Й. Акчура, С. Максуди, Г. Баттал, М. Бигиев һ.б. илне ташлап, читкә китәргә мәҗбүр була. Дәрдмәнд, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Җ. Вәлиди, Г. Рәхим кебек каләм ияләре «эчке эмиграция»дә кала. Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, М. Галәү яңа хакимиятнең үз кешеләре булып исәпләнми. Г. Ибраһимов, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ш. Камал, Ш. Усманов, К. Тинчурин, совет системасына хезмәт итүне үзләренең бурычлары дип санасалар да, кызганычка каршы, Ш. Камалдан кала барысы да шушы хакимият тарафыннан юк ителә. Г. Исхакыйның эмиграциягә китүе, Ф. Туктаров, Г. Терегулов, Р. Ибраһимов, шагыйрә Сания Гыйффәтнең мөһаҗирлектә калуы татар совет әдәбияты өчен зур югалту булды. Бу чорда М. Гафури, Ф. Бурнаш, К. Әмири, С. Кудаш кебек шагыйрьләрнең эшчәнлеге сүлпәнәя. Октябрь инкыйлабына кадәр иҗат иткән, тарихи әһәмиятле пьесалар язган драматурглар торгынлык чоры кичерәләр. Г. Камал, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Ш. Камал кебек язучыларның бу елларда язган пьесалары шул турыда сөйли. Мәсәлән, Г. Камал агитпьесалар һәм драмалар иҗат итә башлый. Дәрдмәнд, инкыйлабны шайтани башлангычка тиңләп («Куанды ил...»), әдәбияттан читләшә һәм озакламый вафат та була [Йосыпова, 2017, б. 191].

Октябрь революциясеннән соң, совет әдәбияты инкыйлаб һәм Гражданнар сугышы вакыйгаларын төп тема итте. Фронт, сугыш, Кызыл Армия, хәрби коммунизм, дин һәм дин әһелләре белән көрәш,

хезмәт, тормыш төзү, яңа кеше, гаилә формалашу, завод-фабрикалар, хезмәт процессы, совет крестьяны психологиясе, эшчеләр көнкүреше һ.б. темалар актуальләшә, гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр дә революцион яссылыкта бирелә. Болар барысы да герой концепциясенең, идеянең үзгәрешенә этәрә. Чор әдәбиятын иңләп баручы мотивлар пәйда була: якты киләчәккә бару, көрәш, ил азатлыгы, бәхете өчен көрәш юлында һәлак булу, көрәшкә өндәү һ.б. Гомумән, 1920–1930 елларда язылган пьесаларда инкыйлабның тарту көче, тормышның давыллы каршылыклары аша халыкның революциягә килүе тасвирлана. Болар барысы да герой концепциясенең, идеянең үзгәрешенә китерә. Февраль революциясенең беренче көннәреннән үк катнашкан, шәхес культы гаепсез һәлак иткән миллионнарча корбаннарның берсе Ш. Усманов та – үз иҗатында яңа дөнья өчен көрәшне аеруча калку чагылдырган һәм үз гомерен шушы көрәшкә багышлаган шәхес.

Язучы әдәбият мәйданына Гражданнар сугышы эченнән, совет хөкүмәте өчен үз-үзен аямыйча көрәшкән кызыл гаскәр арасыннан килеп керә. Революция һәм Гражданнар сугышы шартларында Ш. Усманов хәрби карьера ясый: гади солдаттан – бригада комиссары, слесарьдан – Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең политбүлек җитәкчесе дәрәҗәләренә кадәр күтәрелә [Заһидуллина, 2023]. «Татар бригадасы безгә нәрсә бирде?» («Кызыл Армия», 1919, 24 октябрь) мәкаләсендә язучы, 25 процент тәшкил иткән татарларның рус телен белмәү, һөнәре булмау сәбәпле, «түбән хезмәтләрдә» эшләүләре хакында язып чыга. Ш. Усманов фикеренчә, татар офицерларыннан кызыл генераллар үсеп җитешкәндә генә, алар үз милләттәшләре өчен үрнәк була алачаклар. Совет хөкүмәтенең киләчәген кызыл генераллар белән бәйли ул. Мәкаләләрендә генә түгел, автор тарафыннан язылган пьесаларда да шушы мәсьәлә күтәрелә. «Мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеген җитәкләгәндә үк басма һәм әдәби сүзнең тәэсире мөһим идеология коралы икәнен аңлап алып, Шамил Усманов вакытлы матбугатны һәм әдәбиятны сәяси-агарту һәм пропаганда эшенең аерылгысыз өлешенә әверелдерә» [Заһидуллин].

Ш. Усмановның иҗат тәҗрибәләреннән булган «Канлы көннәрдә» һәм «Беренче адым» драмалары сугышның иң кызган чорында – 1919 елда языла һәм фронт сәхнәләрендә уйнала. Аның пьесалар язарга алынуы да заман таләбе белән бәйле. А. Яхин билгеләгәнчә, «язучы татар сәнгатенә аеруча зур игътибар бирә. Үзе пьесалар язу өстенә ул илнең төрле почмакларыннан талантлы артистлар чакыртып, труппалар төзүгә гаять күп көч куя. Театр сәхнәсе җыйган тамашачыларга гына риза булмыйча, уенны шәһәр мәйданнарына, урамнарга чыгара» [Яхин, 1963, б. 25]. Ш. Усманов бу эшне оештыру белән генә чикләнеп калмый, үзе дә пьесалар язарга алына. Әдип драматургиясендә дә заман үзгәрешләренә сизгер, яңа җәмгыять төзү өчен көрәшкә күтәрелгән геройларга өстенлек бирелеп, якты киләчәккә омтылу, сыйнфый көрәш идеясе белән бәйле конфликтлар үзәккә куела. Язучы: «Минем бар әсәрем тормыштагы берәр вакыйга

тәэсирендә язылa», дип, әсәрләрендә тасвирлаган вакыйгалар белән үзенең биографиясе арасында зур уртаклык барлыгын белдерә. Беренче пьесасы – «Канлы көннәрдә» әсәрен бер кич эчендә язуын әйтә. Үз чорының мөһим мәсьәләләрен күтәреп, әлеге пьесалар халык арасында популярлык казаналар. Бу уңайдан Ф. Бурнаш: «“Канлы көннәрдә” һәм “Беренче адым” сугыш дәверендә эшче-крестьян гаммәсе арасында зур бер дикъкать белән каралып, сөелеп, Россиянең төрле почмагында сәхнәдән төшми килде», – дип яза [Яхин, 1963, б. 25]. Шушы әсәрләреннән башлап, бөтен иҗаты дәвамында Ш. Госманов төп игътибарын әдәбият алдына революция куйган үзәк мәсьәләне – яңа дөнья һәм яңа кеше өчен көрәшне, яңа шәхес белән җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәтен чагылдыруга юнәлдерде [Хәкимова, 2017, б. 142]. Язучы инкыйлаб тудырган яңа кеше тормышында шәхси һәм иҗтимагый мәнфәгатьләр белән идеалларның үзара бәйләнешләрен ачуга басым ясады [Шарипова, 2023, б. 70].

Ф. Галимуллин сүзләре белән әйткәндә, язучылык автор өчен сәяси эшчәнлегендә таяныч, халыкка сәяси вазгыятьне аңлату ысулы булып торган. Әсәрләре тормышның үзеннән алып язылган. Ул, чынлап та, шул заманда зур популярлык казанган. Театрларда, төрле оешмаларда, хәрби частьләрдә аның иҗаты аеруча яратып кабул ителгән. Көн сулышын чагылдырган әсәрләргә ихтыяҗ зур булганлыктан, Ш. Усманов Татарстанның, татар халкының дәүләтчелеген төзүдә, аның мәдәниятен, сәнгатен үстерүдә әйдәүче булып барган [Галимуллин, 2023]. Шул рәвешле язучы үзенең иҗат кыйбласын билгеләп, заман вакыйгалары алып килгән үзгәрешләрне сурәтли. Билгеле булганча, Ш. Усмановның сәхнә әсәрләре, нигездә, инкыйлаб, Гражданнар сугышы тематикасын яктыртуы белән аерылып тора. Язучы «Канлы көннәрдә» (1919), «Беренче адым» (1919), «Бай кызы» (1922) драмаларында төп игътибарын яңа дөнья һәм яңа кеше, тормыш өчен көрәшне, яңа шәхес һәм җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәтен чагылдыруга юнәлдерә. Алар революция чоры каршылыкларын – бер кеше рухында, бер гаилә, туганнар, бер авыл, җәмгыять эчендәге тартышларны тасвирлыйлар. Әдәби-эстетик ягы камил булмаса да, болар татар совет әдәбиятының беренче әсәрләре исемлегенә керәләр [Заһидуллина, 2023]. «Канлы көннәрдә» вакыйгалар Оренбургта ярымэшче, ярымхезмәткәр гаиләсендә бара. Ревоюцион вакыйгаларга бәйле рәвештә, ул капма-каршы өч төркемгә бүленә: Йосыф аклар ягында, Камил белән Хәмит яңа тормыш өчен актив көрәш идеясен чагылдыруга хезмәт итәләр. Мәрьям апа, Нәфисә, Хәмзә бөтен илдә барган бу көрәштән читтә, урталыкта калырга тырышалар. Алар өчен сугышып йөрү – мәгънәсезлек. Ләкин вакыйгалар үстерелешендә фәкать Кызыл Армия генә ярлы халыкка ирек һәм бәхет алып килә, тыныч тормыш тәэмин итү өчен корал тотып көрәшкә чыгу – бердәнбер юл, дигән идея алга чыга. Заман рухына хас булганча, әсәрдә Йосыфның үз хатасын танып, яңа тормыш өчен көрәшүчеләр сафына басуы да шул хакта сөйли.

Биредә автор, туганнар арасындагы инкыйлабка мөнәсәбәтле фикер-каршылыклары булуга карамастан, аларны шәхси дошманлыкка китерми, кан кою, туган-туганын үтерү юлына бастырмый. Туганлык хисләренең рухи яктан берләшүгә китерүен ассызыклый. Шулай да, пьеса еллар таләбенә туры китерелеп, кыска һәм агитацион характерда язылган. Биредә персонажларны индивидуаль шәхес итеп карау юк дәрәҗәсендә. Геройлар тышкы билге һәм тышкы хәрәкәт буенча күз алдына бастырыла. Әлеге күренеш бигрәк тә Йосыф образында ачык чагылыш таба. Башта ак офицер булган Йосыф, яралангач, шактый кискен үзгәреш кичерә. Әмма герой аңындагы үзгәрешләр эволюциясе автор игътибарыннан читтә кала. «Беренче адым»да исә 1917 елгы Февраль революциясе алды вакыйгалары һәм эшчеләр тормышы тасвирлана. Фабрика эшчеләренең сәяси карашлары үзгәрү, бөтендөнья сугышы елларында фабрикадагы авыр хезмәт һәм тормыш шартларының эшчеләр арасында ризасызлыкны көчәйтеп җибәрүе сурәтләнә. Бу геройлар тыныч тормышта тынгысыз көрәшчеләр, завод-фабрикаларны аякка бастыруда алгы сафта баручылар буларак ачылалар. Алгы планда татар эшчеләренә фабрика хуҗаларының тормышы каршы куела һәм ике сыйныф вәкилләренең эчке дөньяларындагы каршылыкка басым ясала. Автор фабрика хуҗаларын – Фатихны, аның хатыны Мәрьям, энесе Хафизны заман үзгәрешен тоеп, сизеп эш итүче һәм шуңа яраклашучылар итеп күрсәтә. Мәсәлән, Хафиз үзенең кан дошманы Камилне дә турыдан-туры фабрикадан кууга каршы чыга, хәтта аны яхшырак урынга куярга киңәш итә. Моның белән ул эшчеләр арасында таркаулык тудырырга тели.

Гражданнар сугышы тәмамлангач, Ш. Усманов пьесаларында үзгәрешләр күзәтелә. Мәгълүм ки, 1920 елларда язылган пьесаларның нигезендә гаилә һәм никах нормаларының җимерелүе урын ала. Ш. Усмановның «Бай кызы» драмасы да шул юнәлештә иҗат ителгән. Бу пьесада алдагы әсәр белән жанр, сюжет, конфликт һәм коллизияләр охшашлыгы күзәтелсә дә, автор башка тормыш материалына мөрәҗәгать итә. Вакыйгаларның үстерелеше һәм төп каршылыкның чишелеше, якланган кыйммәтләр дә үзенчәлекле. Язучы шәхес һәм җәмгыять мәсьәләсен көрәш һәм мәхәббәт җирлегендә карый. Социаль каршылык драмадагы вакыйгаларны хәрәкәткә китерә, әсәрдә өстенлек алган мәхәббәт сюжет сызыгына драматизм, фаҗигалылык өсти. Үзәктә – күңел тынычлыгы таба алмаган, фронт тормышын сагынган геройлар. Элеккеге комиссар Хәлил тыныч тормыш рухына бирелеп яшәмәкче була. Ул гаилә корып җибәрә, бай кызына өйләнә. Хәлил һәм Зөһрә образларына бәйле рәвештә, автор мәхәббәт һәм ирек, ярату һәм үкенеч хакында сөйли. Сугыштан кайткан комиссар Хәлил һәм аның хатыны Зөһрәнең фикер каршылыкларына мөрәҗәгать итеп, ул көрәш романтикасы һәм мәхәббәт каршылыгын сурәтли. Пьесада тасвирланган Саттар, Вәли, Җәләйләр исә Хәлилне уңай чишелешкә тартучылар итеп кенә түгел, ә туып килә торган яңа җәмгыятьне төзүчеләр, җиңүче көчләр буларак тәкъдим ителә.

«Драматургиядә тарихи-революцион һәм тарихи жанрлар өлкәсендә эзләнүләр көчәя. Беренчеләренә мисал итеп, Т. Гыйззәтнең “Чаткылар” (1934) һәм “Ташкыннар” (1937), Ф. Бурнашның “Лачыннар” (1932), Ш. Госмановның “Кичеккән фәрман” (1933) кебек драмаларын алырга мөмкин. Аларда төрлерәк стиль алымнары ярдәмендә революциягә кадәрге социаль тигезсезлек, Гражданнар сугышы чорындагы көрәш күренешләре сурәтләнә» [Мусин, 2017, б. 29]. Ш. Усманов 1933 елда З. Вәлидине һәм башка тарихи шәхесләрнең милли сәясәтен күрсәтүне максат итеп куйган «Кичеккән фәрман» исемле пьесасын яза. Әсәрнең язмышы да кызыклы. Драма иң яхшы драма әсәрләренә уздырылган Бөтенсоюз конкурсында махсус билгеләп үтелә һәм сәхнәгә кую өчен театрларга тәкъдим ителә, 1935 елда Мәскәүдә «Страна родная» исеме белән бастырыла. Шуңа да карамастан 1937 елда Я. Рыжанин драмага тискәре рецензия язып чыга. Автор әсәрне бастырган нәшриятны сәяси хата ясауда гаепли, сатудан, китапханәләрдән алырга кирәклеген ассызыклый. 1938 елның 8 апрелендә Ш. Усмановның әсәрләре киң җәмәгатьчелектән читләштерелә.

Пьесада З. Вәлиди җитәкчелегендәге иҗтимагый хәрәкәтнең башкорт автономиясен булдыру юлына басуы, вакыйгалар үстерелешендә аның совет хакимияте ягына чыгуы сурәтләнә. Үзәк герой Харис Садыйковның (прототибы – Зәки Вәлиди) большевиклар ягына авышуы төрле социаль катлау вәкилләренең үзара мөнәсәбәтләре һәм конфликтлары аша бирелә. Кызганычка каршы, соңрак бу әсәр язучыны милләтчелектә, контрреволюцион эшчәнлектә гаепләүгә сәбәп була [Заһидуллина, 2023]. Мөселманнарны берләштерү турында хыялланган Харис Садыйков соңыннан бу идеянең тормышка ашмавын аңлый һәм совет властен танырга мәҗбүр була.

Гомумән, әлеге пьесалар сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан бүгенге таләпләргә җавап бирерлек дәрәҗәдә түгел. Ләкин үз вакытында алар бик популяр булганнар. Шәхси башлангычка, психологик анализга игътибар бирмәү персонажның дөньяга карашы үзгәрүне дә декларатив төстәрәк гәүдәләндерүгә китергән. Аларның рухи дөньясын, шәхси характер сыйфатларын ачуга ныклы игътибар бирелмәгән. Конфликт та характерлар бәрелешенә түгел, бәлки идеяләр һәм сыйнфый карашлар бәрелешенә нигезләнгән. Нәтиҗәдә, әсәрләр тамашачыны Совет власте дошманнарына каршы көрәшкә өндәүче агитацион пьесага әверелгән. Үзенең бер мәкаләсендә Ш. Усманов болай дип яза: «Мин язучылыкны үземә һөнәр, кәсеп итеп алган профессионал түгел. Язучылык – ярдәмчел хезмәтем генә». Гомумән, Ш. Усманов, башка язучылар кебек, үз татар әдәбиятына гадел җәмгыять төзү, шуның өчен көрәшү идеяләрен алып килә. Биредә, заман рухына хас булганча, геройның революцион идеаллары аның шәхси теләкләреннән югары куела. Шулай да, әдипнең драма әсәрләре шул заман сулышын, әле генә мәйданга чыккан заман геройларын, яңа кыйммәтләрне, халыкның тарихи үткәнен күзалларга ярдәм итүе

белән игътибарга лаек. Язучы пьесаларында сыйнфый каршылыкларны гына түгел, ә яңа җәмгыятьне төзүче кешеләр формалашуны, үз чорының канлы вакыйгаларын, Гражданнар сугышына бәйле шәхес фаҗигасын да күзалларга мөмкин. Ш. Усманов – 1920–1930 елгы сәяси вакыйгаларда кайнап, әдәбиятка бу чорның портретын тасвирлап калдырган язучы, халкының бәхетле киләчәге социалистик җәмгыять төзүдә дип ышанган, шуның өчен кулына корал тотып сугышкан, ил мәнфәгатьләрен алгы планга куеп, гаскәри, җитәкче һәм язучы сыйфатында тырышып эшләгән, һәм шул җәмгыятьнең корбаны булган зат. Билгеле булганча, шәхес культы тантана иткән 1937 елның 7 апрелендә татар совет язучысы, җәмәгать эшлеклесе Шамил Хәйрулла улы Усманов бер гаепсезгә кулга алына, милләтчелектә, Солтангалиев оешмасында катнашуда гаепләнә. Тормышта башимәс, кыю, буйсынмас әдип тоткынлыкта да шундый ук булып кала [Мостафин, 2014, б. 237–239]. Әдипнең гомере 1937 елның 3 декабрендә фаҗигалы рәвештә өзелә.

### Әдәбият

*Галимуллин Ф.* Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Шамил Усмановны искә алдылар // Тулырак: https://tatar-inform.tatar/news/tel-adabiyat-ham-sangat-institutynda-samil-usmanovny-iska-aldylar-5880547?ysclid=lt5k1o8kcp2869244 (мөрәҗәгать итү көне: 26.02.2024).

*Заһидуллин И.* Кызыл комиссар Шамил Усманов // ТАТАРСТАН. https://protatarstan.ru/news/mangelek-kyimmatlartarix/kyzyl-komissar-samil-usmanov?ysclid=lr8y6sutq5435261485 (мөрәҗәгать итү көне: 26.02.2024).

*Заһидуллина Д.* Шамил Усманов: матур тормыш төзүгә багышланган гомер // Казан утлары. 2023. № 12. Б. 150–160.

*Йосыпова Н.* Поэзия // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. 621 б.

*Мостафин Р.* Һәрберсен исемләп искә алыйк. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 237–239.

*Мусин Ф.* Әдәби хәрәкәт // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. Б. 39–63.

*Усманов Ш.* Сайланма әсәрләр: повестьлар, хикәяләр, пьеса. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 504 б.

*Хәкимова С.* Госманов Ш. // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. Б. 139–151.

*Шарипова А.С.* Татарская драматургия XX – начала XXI в.: инвариант и его исторические трансформации: дис. … д-ра филол. наук. Казань, 2022.

*Яхин А.* Шамил Усманов (1898–1938): тормышы һәм иҗтимагый-политик эшчәнлеге турында документаль очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 40 б.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# МИЛЛИ ФОЛЬКЛОР ТОМНАРЫН ТӨЗҮ: БУЛГАН ТӘҖРИБӘ, ЗАМАНЧА ТАЛӘПЛӘР, ПЕРСПЕКТИВАЛАР ҺӘМ БУРЫЧЛАР

В статье изложены основные положения подготовки академических изданий по татарскому фольклору. Автор подчеркивает, что академические издания наглядно и полно представляют национальный фольклор во всём его идейно-эстетическом богатстве и разнообразии жанров. Автором обоснованы необходимость издания новых томов, описаны главные принципы составления, определены проблемы и перспективы деятельности в издании академических томов по татарскому народному творчеству.

**Ключевые слова:** татарское народное творчество, академическое издание, свод по фольклору, фольклорные материалы.

The article outlines the main provisions of the preparation of academic publications on Tatar folklore. The author emphasizes that academic publications clearly and fully represent national folklore in all its ideological and aesthetic richness and variety of genres. The author substantiates the need for the publication of new volumes, describes the main principles of compilation, identifies problems and prospects of activity in the publication of academic volumes on Tatar folk art.

**Keywords:** Tatar folk art, Academic publication collection of folklore, folklore materials.

Бүгенге көндә халык иҗаты бүлеге алдында торган иң җаваплы эшләрнең берсе – академик «Татар халык иҗаты» күпмомлыкларын дөньяга чыгарып, җәмәгатьчелек хөкеменә тапшыру. Планлаштырылган, оригинал телдә – 25, рус телендә 15 том эшләүнең һәркайсының үзенең нечкәлеге бихисап. Милли фольклор томнарын төзү – бик четерекле, катлаулы, ныклы әзерлек таләп итә торган үтә җитди хезмәт.

Шунысы куанычлы: татар фольклор мәктәбендә мондый томнар төзү тәҗрибәсе бар иде инде, яңа томнарны төзегәндә 13 томлык (Татар халык иҗаты. 13 томда. 1–13 томнар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977–1993) кулыбызда булды. Болар үз чоры өчен югары дәрәҗәдә башкарылган хезмәт булсалар да, бүгенге көндә фән фольклорга, булган традицияләрне дә исәпкә алып, яңача карауны таләп итә, басмаларга заманча таләпләр куела, өр-яңа проблемалар күтәрелә, мөмкинлекләр дә киңәя.

Монда иң элек бер мәсьәләне ачыклап үтәргә кирәк. Академик томнар турында сүз алып барабыз икән, иң элек нәрсәне академик том дип саныйбыз, дигән сорау туа. Академик том – иң югары дәрәҗәдә башкарылган, иң тулы, камил эчтәлекле, барлык вариантлар исәпкә

алынган, төпле-нигезле, компактлы искәрмә-комментарийлар, белешмәләр бирелгән басма [Большая советская энциклопедия]. Мондый басмадагы текст аны алга таба детальләп, тирәнтен өйрәнер өчен әзерләнгән булырга тиеш. Томнар өчен материалны эшкәртеп, әзерләп формалаштыру – аерым бер фәнни процесс. Академик басманы әзерләү белән гадәттә академик оешма шөгыльләнә.

Фольклор – борынгы әдәбият һәм хәзерге чор әдәбияты кебек үк, текстологиянең бер объекты. Текстологияне ярдәм фән буларак күзаллаганда, аның проблематика һәм төп төшенчәләре (автограф, нөсхә-күчермәләр, каралама, акка күчереп язу, копия, архетип, вариант, инвариант һ.б.), гомуми методлары һәм алымнары (атрибуция, дата билгеләү, искәрмә-комментарий бирү, төзәтү-конъектуралау, күчерүче каләменә хас типик хаталарны өйрәнү һ.б. ) – болар бар да текстология турында уртак бер максаты булган фән буларак сөйләргә мөмкинлек бирә. Әмма тарихи шулай килеп чыккан ки, фольклористика ул үз принциплары, проблемалары, мөмкинлекләре, үзенчәлекләре булган аерым бер дисциплина, аерым фән булып оешкан. Шуңа да төрле фольклор текстларын җыеп, жанрга аерып, аларга аерым классификация ясап, томнар итеп чыгару мәсьәләсендә фольклористиканың үз тәртипләре, карашы, таләбе, ихтыяҗы формалашкан.

Дөрес, милли фольклор томнары төзегәндә текстологиядә кабул ителгән гомуми таләпләргә мөрәҗәгать итми мөмкин түгел, әлбәттә. Без дә текстология фәнендәге төп кагыйдәләрдән чыгып эш итәбез. Әмма, әдәбияттан аермалы буларак, милли фольклор басмалары турында сүз барганда, фольклорда жанрлар, жанр төрләре, текстларның күләме, вариантлар бирелешендәге үзенчәлекләр, беренчел чыганак принципларын саклау, уртак сюжетлы әсәрләр, текстларның теле, аны ничек бирү мәсьәләләре һ.б. җәһәтеннән хәл нык киеренкеләнә.

Фольклор – өзлексез процесс, кичә табылган үрнәк шул момент өчен иң соңгы вариант яисә күчермә булса, иртәгә инде аның яңасы табылу ихтималы бар. Мондый очракта бөтен вариантлар да кергән иң тулы басма дигән критерийны куеп булмаска да мөмкин. Әйтик, томнар төзегәндә әдәбият тарихында XIX гасыр ахырында Мәүлекәй Юмачиков тарафыннан Себер татарларыннан җыеп, шигъри формага салып, XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында Казан типографияләрендә актив бастырылган дини-героик характердагы «Салсал» дастаны хакында мәгълүматларыбыз бик аз иде. Фәкать гарәп графикасында басылган китапларда тексты сакланган һәм Г. Газиз мәкаләләрендә [Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар, б. 61] телгә алынган бу китаби дастан – хәзерге язуга күчерелмәгән, махсус өйрәнелмәгән, үз чиратын көтеп китапханәләрдә ята торган истәлекләрнең берсе. 2023 елның ахырында исә шушы сюжетка дастанның «Салсал батыр» дип аталган, XX гасырда әтисе сөйләгәннән улы отып калып, XXI гасырда кәгазьгә төшергән варианты кулга килеп керде.

Югарыдагы мисал, бер яктан, дастанның халыкта яшәве дәвам итүен күрсәтсә, икенче яктан, томнар төзелеп бетеп, чыгарга әзерләнгән яисә нәшер ителеп тә өлгергән бер вакытта теге я бу жанрга караган текстларның туктаусыз яңарып торуын, яңа мәгълүматлар барлыкка килү хасиятен дә ассызыклый. Шуңа күрә академик характердагы басмаларга куела торган таләпләрне, принципларны фольклор текстларына мөнәсәбәттә һәрвакыт бер ноктага җыеп бетерү, академиклык кысасы булдырып, шушы кысага сыйдыру үзенә бер осталык, теоретик һәм гамәли белем таләп итә. Фольклорга хас мондый вазгыять халык иҗаты томнарын төзүнең алдагы перспективасы тагын да зур булуга да ишарәли.

Төрки халыклар фольклор басмаларында булсын, рус фольклорында булсын, халык иҗаты үрнәкләрен туплаган академик җыентыклар дөнья күреп тора. Әйтик, Россия Фәннәр академиясенең Себер бүлеге Филология институты (Новосибирск) «Памятники фольклора народов Сибири и Дальнего Востока» сериясендә дөнья күргән 60 томлы мәгълүм басманы әзерләп чыгара килә. Яисә башкорт тикшеренүчеләренең халык иҗатына багышланган 3 томлыклары (1954–1959), 18 томлыклары (1972–1985), рус телендә дөнья күргән 12 томлыклары (1987–2010) – барысы да академик басма санала. Фольклор томнарына карата «академик басма» термины, материалларның вариантлары берөзлексез табылып торырга мөмкин булуны истә тотканда, шартлы кебек күренсә дә, Россия фольклористикасында мондый характердагы күптомлыклар бар һәм аларга ихтыяҗ елдан-ел арта гына.

«Татар халык иҗаты» томнарының XX гасыр азагында дөньяга чыккан 13 томлыгы да, бүгенге көндә 9 ар томы инде нәшер ителгән 25 томлы татарча, 15 томлы рус телендәге җыентыклар – бар җәһәттән академик оешма тарафыннан фәнни таләпләргә җавап бирә торган фундаменталь хезмәтләр. Теге я бу фольклор текстының барлык билгеле вариантларын сыйдырган, я инде, һичьюгы, шуларның берсе я берничәсе бирелеп, калганнары хакында искәрмә-комментарийларда сөйли, бу текстлар турында төп мәгълүматны бирә торган, жанрга, аның төрләренә, милли спецификасына, бүленеш-классификация мәсьәләләренә җентекле аңлатма бирелгән тәфсилле керешкә ия, фәнни аппараты камил, чыгару көненә шушы әсәрләр-текстлар турында тулы, күп кенә очракларда текстның информант авызыннан яздырылган аудио-язмасына нигезләнгән, академик оешма тарафыннан барлык җаваплылыгында башкарылган фәнни яки фәнни-популяр типтагы фольклор басмалары, дигән билгеләмәгә чын мәгънәсендә туры килә әлеге күптомлыклар.

25 һәм 15 томлыкларга кадәр төзеп бастырылган 13 томлы «Татар халык иҗаты» томнарының кереш мәкаләләрендә жанрга билгеләмә бирелгән, басыла торган материалларның тарихи-мәдәни әһәмияте ачыкланган, текстларның шигъри табигате яктыртылган, типология, милли үзенчәлекләр, генетик һәм контакт бәйләнешләргә кагылып

үтелгән, өйрәнелү тарихына да урын бирелгән. Гомумән, керешләр тиешле дәрәҗәдә башкарылган.

Томнарга текстлар заманы өчен объектив булырга тырышып сайланган. Әлбәттә, татарның бөтен фольклоры тулысынча боларга сыеп беткән дип әйтә алмыйбыз. Монда сәяси-идеологик карашларны читләп үтә алмаган очраклар, әлбәттә, бар. Әйтик, Казан алыну вакыйгасын яктырткан «Чура батыр» дастанының кайбер өлешләре, «Казан бәете»нең зур өлеше, төрле жанрларда дини темага кагылышлы үрнәкләрнең күбесе һ.б. томнарга керми калган. Бу томнарга фольклор текстларының үз заманы идеологик карашлары яссылыгына туры килү-килмәвенә карап сайлап алынганлыгы аңлашыла. Әмма шунысы да бар: шушы китаплар чыккан чор таләбенә мөнәсәбәттә бу 13 томлыктан да тулырак, мәгълүматлырак, баерак башка күптомлыгыбыз моңа кадәр юк иде. Татар телле фольклор үрнәкләре хакында белешмә, бүленеш принциплары, әдәби-мәдәни, тарихи әһәмияте һ.б. сорауларга җавапны иң элек әнә шул томнардан эзләдек. Шулардан текстлар алып, масса характерындагы яңа җыентыклар дөнья күрә тора. Бу текстлар – 1939 елдан бирле уздырылган экспедицияләрдә язып алынып, бик җентекле тикшерү процессы узган, шул заман культурасы өчен әһәмияте зур саналган фольклор күренешләре, фольклор материаллары.

Искәрмә-комментарийларда томга урнаштырылган текстларның тулы паспорты бирелгән, жанр кыскача характерланган, вариантлар турында мәгълүматлар, текст басылган чыганак турында белешмә китерелгән. Болар бар да билгеле бер тәртиптә, барлык томнарда да бертөрле принципларны сакларга тырышып, чыгарылмалар булса, алар турында керештә җентекле аңлатмалар бирелгән.

Ә бүгенге көндә 25 томлык төзүнең үз кыенлыклары, үз таләпләре, үз мөмкинлекләре. XX гасыр дәвамында төрле юнәлешләрдә үсеш алган татар фольклористикасы гасырлар чигендә яңа баскычка күтәрелде. Бу өлкәдә 80 нче еллардан башлап хәзерге этапка кадәр фундаменталь уңышлар 1939 елда Татар теле, әдәбияты һәм тарихы фәнни-тикшеренү институты буларак оештырылган, хәзерге Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге эшчәнлеге белән тыгыз бәйле. Халык иҗаты бүлеге бүгенге көндә татар фольклористикасы өлкәсендә алып барыла торган тикшеренүләрнең төп юнәлешләрен билгели торган фәнни үзәк ролен башкара.

Бүлек Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләрендә яшәүче татарларның рухи мирасын – фольклор материалларын җыю, халык авыз иҗаты үрнәкләрен бастыру, фольклор әсәрләренең этнолокаль һәм жанр үзенчәлекләрен фәнни тикшерү һәм анализлау, дисциплинаара тикшеренүләр үткәрү, татар фольклорын башка төрки халыклар иҗаты белән чагыштырып өйрәнү эшен һ.б. үтәп килә.

Экспедицияләр вакытында җыелган материалларны тикшерү, анализлау һәм фәнни әйләнешкә кертү белән беррәттән, соңгы елларда бүлек тарафыннан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана торган рухи мирасны барлау, өйрәнү, анда 1940 еллардан башлап туплана килгән документларны бүгенге көндә табылганнары белән чагыштыру, шул исәптән күпсанлы яңа фәнни хезмәтләр әзерләү эше дә башкарыла.

Бу юнәлештәге фундаменталь проектлар булып рус телендә 15 томлы «Татар халык иҗаты» басмасы [Татарское народное творчество: в 15 т.] һәм татар телендә 25 томлы «Татар халык иҗаты» җыентыгы [Татар халык иҗаты: 25 томда] тора. Проект җитәкчесе – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор К.М. Миңнуллин.

25 томлы «Татар халык иҗаты» академик басмасы татар фольклорының барлык жанрларын – мифлар, йолалар, әкиятләр, дастаннар, китаби дастаннар, җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, табышмаклар, мәкаль һәм әйтемнәр, балалар фольклоры, уен фольклоры, риваятьләр, легендаларны үз эченә ала. Җыентыкны әзерләүнең төп максаты исә – татарларның моңа кадәр басылып чыкмаган фольклор мирасы байлыгын киң аудиториягә җиткерү, халык иҗаты әсәрләрен популярлаштыру, тарихның билгеле бер этабында мәдәният ядкәрләрен теркәү, татар фольклоры буенча күпьеллык тикшеренүләр нәтиҗәләрен бер фәнни ноктага туплау, берләштерү. Яңа академик басманы әзерләүгә булган ихтыяҗны берничә фактор аша аңлатырга мөмкин. Беренчедән, 13 томлы «Татар халык иҗаты» басмасының барлык китаплары XXI гасыр башына күптән таралып бетте, алар чын мәгънәсендә библиографик сирәк басмага әверелде. Икенчедән, унөч томлыкка текстлар сайлап алуга үз чорында идеологик караш булу сәбәпле, күптомлык төрле жанрга караган татар фольклор үрнәкләренең барысын да үз эченә алмаган; моннан тыш, XXI гасыр фольклористикасында моңа кадәр бөтенләй читтә кала килгән жанр һәм жанр төрләре аерылып чыкты, бу жанрларга караган материаллар өйрәнелеп, алар хакында фәнни даирәдә мәкаләләр дөнья күреп килә; Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе территориясендәге фәнни үзәк фондларында, шулай ук шәхси архивларда татар халык иҗатына караган яңа материаллар бик күп җыелган.

25 томлыкка кертелгән текстлар академик томнар таләбе югарылыгында җентекле тикшерү астына алынган. Соңгы елларда Институт тарафыннан үткәрелгән комплекслы экспедициядә тупланган фольклор материаллары, архив материаллары, моңа кадәр игътибардан читтә калган үрнәкләр яки тулысы белән бер жанр, жанр төре – болар барысы да ачыкланып, томны төзүче тарафыннан тикшерелеп, билгеле бер эзлеклелеккә куеп, томнарга кертелде.

Текстларны томга сайлап алу, әлбәттә, бик катлаулы эш – иң әүвәл әсәрләрнең кайсы жанрга каравын билгеләргә, барлык вариантларын,

башка халыклардагы версияләрен исәпкә алырга, булган материалны системалаштырып һәм классификацияләп, фольклорда моңа кадәр бу һәм башка томнарны төзегәндә кулланылган принципларның барысын өйрәнеп, исәпкә алып, мантыйкый бер принципка җыяргa кирәк. Монда бик күп критерийларны истә тотып эш итү сорала. Һәрбер текст турында тулы мәгълүмат туплаганнан соң, ягъни аның фәнни әйләнештә булганлыгын, апробация үтү-үтмәвен, вариант-версияләрен, бүгенге көндә актуальлек дәрәҗәсен, татар әдәби-мәдәни процессындагы урынын билгеләгәннән соң гына материалны томга кертү-кертмәү мәсьәләсе хәл ителә. Шушылай җентекләп сайлап алынган фольклор текстлары билгеле бер балансны саклап, традицион классификацияләрне исәпкә алып, яңача бүленеш ихтыяҗыннан чыгып кына томга урнаштырылды.

Һәр жанрның үз нечкәлеге бар. Күләмле эпик жанрларга бертөрле якын килергә кирәк булса, вак эпик жанрлар башкача мөнәсәбәт таләп итә. Лирик жанрлар, лиро-эпик жанрлар шулай ук үз үзенчәлекләре белән бер-берсеннән нык кына аерылып тора, монда да җентекле классификация, сайлап алуда, текстларга искәрмә-комментарийлар бирүдә махсус методология булдырмый мөмкин түгел. Томнарның кереш сүзендә һәрбер жанр һәм жанр төренә карата, XXI гасыр фольклор төшенчәсе буларак, киң, тирән һәм төгәл билгеләмә, жанрны өйрәнү тарихы, текстларга анализ һ.б. чагылыш табарга тиеш.

Яңа томнар арасында моңа кадәр аерым китап багышланмаган томнар да бар, әйтик, «Мифология», «Йола фольклоры» томнары, әкиятләр классификациясендә «Батырлар турындагы әкиятләр» төрен аеру, дастаннар төркемендә «Китаби дастаннар» төренә аерым том багышлау ихтыяҗы, җырлар томнарында моңа кадәр томнарга кертелмәгән масса (халыклашкан) җырларын, хушавазларны, соңгы ярты гасыр лирик иҗатын ассызыклап күрсәтү, моңа кадәр аерым том итеп бирелми калган «Мөнәҗәтләр» томы, барлык томнарда да текстларның алдагы томнарга керми калган вариантларын тагын бер кат барлап чыгу, эшкәртеп, яңа томга кертү өчен әзерләү, кириллицага күчерелми калган гарәп кульязмаларын табып, өйрәнеп, томга кертү-кертмәү мәсьәләләре – боларны хәл итү яңа томнарны төзегәндә килеп туган сорауларның бер өлеше генә. Материал искиткеч күп, аларны системага салу, булган тәҗрибәгә таянып, бүгенге көндә актуаль булган якларны алгы планга куеп, мөмкин кадәр тулылыкка ирешеп, һәр томны тиешенчә формалаштыру, һәр томга җентекле фәнни кереш язу – бүгенге фольклорчының бурычы.

Томның фәнни аппараты дигән төшенчәне һәрдаим истә тотып, шушы 25 томлык өчен мөмкин дәрәҗәдә уртак принциплардан тайпылмыйча, килеп туган нечкәлекләргә керештә, искәрмә-комментарийларда тәфсилле аңлатмалар биреп, текстларны урнаштыруда оптимальлеккә ирешә алу – фольклор томнарын төзегәндә әлеге якларга тиешенчә игътибар бирелде. Текстларны томга алганда тел мәсьәләсен дә әлеге дә баягы текстологиядә кабул ителгәнчә хәл

итәргә тырышабыз: текст нарратив чыганаклар аша килгән икән, беренчел бирелешне саклау принцибы, ә информант авызыннан язып алганда исә лексик үзенчәлекләргә аңлатма бирү, фонетик үзенчәлекләрне мөмкин кадәр саклау, морфологик-синтаксик билгеләрне оригиналдагыча калдыру принцибы кулланыла.

Төзелгән һәм төзелә торган 25 томлы фольклор томнары архив кулъязмаларын һәм беренчел басма чыганакларны текстологик эшкәртеп биргән текстлар белән генә түгел, ә экспедицияләр вакытында халыктан «терелэй» язып алынган фольклор үрнәкләренең байлыгы белән дә кыйммәт. Элеккерәк елларда күренекле фольклорчылар Н. Исәнбәт, Х. Ярми, Х. Гатина, Г. Бәширов, И. Надиров, Ф. Урманчеев, Х. Мәхмүтов, М. Әхмәтҗанов, Р. Ягъфәров, Ф. Әхмәтова, Л. Җамалетдинов, А. Садекова, С. Гыйләҗетдинов, К. Миңнуллин, А. Садыйкова һ.б. экспедициядә язып алган текстларның, информантлар башкарганда яздырылган кассеталарның күпчелеге Институтның Язма мирас үзәге фондында саклана. Үзебезнең Мирасханәдән тыш Казан федераль университеты, Милли китапханә архивларында да материаллар күп. Томнарны төзү барышында әлеге кулъязмаларга һәм, сакланышы төрле дәрәҗәдә булса да, аудиокассеталарга һәрвакыт мөрәҗәгать итәбез. Бу, әлбәттә, күп вакыт сорый торган үтә четерекле һәм җаваплы эш. Ә инде соңгы елларда үзебез йөргән экспедицияләрдә тупланган язмаларга килгәндә, аларны монтажлап, кирәклесен сайлап алып, томнарны өстәмә аудиоязма белән тулыландырып чыгару 25 томлыкта каралмаган. Шулай да татар авылларында соңгы экспедицияләрдә җыелган фольклор материалы бөтен тулылыгында текстларга күчерелә һәм томнарга кертелә бара – монысы зур казаныш. Татарлар яши торган төрле төбәкләргә максатчан үткәрелә торган комплекслы экспедиция материалларының, беренчел эшкәртелеп, 2010 елдан бирле «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә чыга торган «Милли-мәдәни мирасыбыз» китапларының нәшер ителә баруы, вакытлы матбугатта фәнни һәм фәнни-популяр характердагы мәкаләләр аша апробацияләнеп торуы да томнарны фәнни әйләнешкә кертелгән фольклор текстлары белән баетырга мөмкинлек бирә.

Рус телендә чыгып килгән 15 томлык мәсьәләсенә килсәк, боларны төзегәндә дә татар телендәге басмаларны әзерләүдә кулланылган кагыйдәләр һәм принциплар саклана. Әмма үзенчәлекле ягы да бар: русча томнар милли фольклорны тәрҗемә итү проблемасы белән бәйле үтә четерекле аерым бер өлкә. Катлаулы, әмма актуаль мәсьәлә. Бу хакта махсус сөйләшү кирәктер. Шунысын гына әйтеп китик: аларның инде дөнья күргәннәре – тиешле дәрәҗәдә эшләнгән бик саллы томнар. Татар телле фольклор материалын рус теленә тәрҗемә итеп, системалы рәвештә бастырып чыгару татар фольклористикасында әле беренче тапкыр башкарыла.

«Татар халык иҗаты» томнарын академик басма югарылыгында кабат төзеп бастыру чор таләбе булды. Яңа 25 һәм 15 томлыкларны

чыгаруның төп максаты – тикшерү узган, белешмәләр бирелгән текстларны туплап, системага салып тәкъдим итү, алга таба масса характерында чыгарылачак җыентыклар өчен һәм гомумән фольклористика фәненең фәнни теориясен камилләштерү өчен база булдыру. Фольклор томнары тулысы белән шушы максатларны күздә тотып һәм аларга ярашлы итеп эшләнде һәм эшләнә. Татар халык авыз иҗатын бергә туплап, фольклорның географик киңлеген, хронологик тирәнлеген исәпкә алып, заманына күрә мөмкин кадәр тулы итеп, бер системага салып бирүне күздә тотып башкарылган «Татар халык иҗаты» җыентыкларының татар телендә дөнья күрә килә торганнары да, русча томнар да мондый төр хезмәтләргә хас булган фәнни дәрәҗәне катгый саклый. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге хезмәткәрләре әлеге кыйммәтле, зур хезмәт таләп итә торган җыентыкларны замандашлары өчен генә түгел, киләчәк буыннарны да күздә тотып тәкъдим итә.

**Әдәбият**

Большая советская энциклопедия. URL: https://dic.academic.ru/dic.nsf/bse/62104/Академическое (мөрәҗәгать итү көне – 03.02.2024)

Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Г. Рәхим, Г. Газиз. Татар әдәбияты тарихы. Борынгы дәвер. XVII–XIX гасырлар = Духовное наследие: поиски и открытия. Г. Рахим, Г. Газиз. История татарской литературы. Древний период. XVII–XIX века. Т. 2 / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Ш. Гарипова, Л.Р. Надыршина, А.М. Ахунов, И.Г. Гомәров, Г.А. Хөснетдинова. Казан: ТӘһСИ, 2022. 16 нчы чыг. 300 б.

Татар халык иҗаты: 25 томда. Т. 1. Мифология / төз., текст, иск. һәм аңлатмаларны әзерл., кереш сүз авт. Л.Х.Дәүләтшина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 541 б.

Татар халык иҗаты: 25 томда. Т. 2. Йола фольклоры / төз., текст, иск. һәм аңлатмаларны әзерл., кереш сүз авт. Л.Х. Дәүләтшина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 511 б.

Татар халык иҗаты: 25 томда. Т. 3. Әкиятләр / төз., текст, иск. һәм аңлатмаларны әзерл., кереш сүз авт. И. Г. Закирова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2023. 487 б.

Татар халык иҗаты: 25 томда. Т. 4. Әкиятләр / төз., текст, иск. һәм аңлатмаларны әзерл., И. Г. Закирова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2023. 438 б.

Татар халык иҗаты: 25 томда. Т. 5. Әкиятләр / төз., текст, иск. һәм аңлатмаларны әзерл., И.Г. Закирова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2023. 407 б.

Татар халык иҗаты: 25 томда. Т. 6. Әкиятләр / төз., текст, иск. һәм аңлатмаларны әзерл., И.Г. Закирова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2023. 407 б.

Татар халык иҗаты: 25 томда. Т. 7. Әкиятләр / төз., текст, иск. һәм аңлатмаларны әзерл., кереш сүз авт. И.Г. Закирова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2023. 359 б.

Татар халык иҗаты: 25 томда. Т. 8. Әкиятләр / төз., текст, иск. һәм аңлатмаларны әзерл., И.Г. Закирова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2023. 375 б.

Татар халык иҗаты. 25 томда. Т. 9. Дастаннар / төз., текст, иск. һәм аңлатмаларны әзерл., кереш сүз авт. И.Г. Закирова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2023. 483 б.

Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 1. Сказки о животных. Волшебные сказки / сост. тома, авт. вступ. ст. и коммент. Л.Ш. Замалетдинов. Казань: Магариф, 2008. 455 с.

Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 2. Волшебные сказки / сост. тома, авт. вступ. ст. и коммент. Л.Ш. Замалетдинов. Казань: Магариф, 2008. 447 с.

Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 3. Бытовые сказки / сост. тома, авт. вступ. ст. и коммент. Л.Ш. Замалетдинов. Казань: Магариф, 2009. 543 с.

Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 4. Загадки / сост. тома, авт. вступ. ст. и коммент. Х.Ш. Махмутов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 367 с.

Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 5. Предания и легенды / сост. тома, авт. вступ. ст. и коммент. С.М. Гилязутдинов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 383 с.

Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 6. Пословицы и поговорки / сост. тома, авт. вступ. ст. и коммент. Х.Ш. Махмутов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2017. 366 с.

Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 7. Мэзэки (народные шутки) / сост. тома, авт. вступ. ст. и коммент. Х.Ш. Махмутов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2017. 351 с.

Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 8. Дастаны / сост. тома, авт. вступ. ст. и коммент. Ф.В. Ахметова. Казань: Татар. кн. изд- во, 2019. 471 с.

Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 9. Баиты / сост. тома: Ф.В. Ахметова, И.Н. Надиров, К.Б. Замалетдинова. Казань: Татар. кн. изд-во, 2019. 479 с.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 93/94

***Г.М. Габдулхакова,***
***Л.Р. Халилова***

# КЫРГЫЗСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ОШ ШӘҺӘРЕ ТАТАРЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ-МӘДӘНИ ТОРМЫШЫ (1990–2020 еллар)

В статье рассматривается деятельность Татаро-башкирского национально-культурного центра «Илькаем» г. Ош по сохранению национальной идентичности и самобытности татар, проживающих в Кыргызской Республике. Отражены некоторые нормативные документы Кыргызской Республики, направленные на развитие интернациональной дружбы между народами, населяющими республику.

**Ключевые слова:** Кыргызская Республика, культурно-исторические связи, межнациональное согласие, татары, миграция, национально-культурное объединение, этническая самобытность.

The article examines the activities of the Tatar-Bashkir National Cultural Center «Ilkay» in Osh to preserve the national identity and identity of the Tatar people living in the Kyrgyz Republic. Some normative documents of the leadership of the Kyrgyz Republic aimed at the development of international friendship between the peoples inhabiting the republic are reflected.

**Keywords:** Kyrgyz Republic, cultural and historical ties, interethnic harmony, Tatars, migration, national and cultural association, ethnic identity.

Кыргызстан – күпгасырлы тарихы булган ил. Монда төрле милләт вәкилләре тату һәм бердәм яши. Республикада яшәүче һәрбер халык дәүләтнең бәйсезлеге һәм алдынгы җәмгыять үсешен ныгыту өчен үзенең өлешен кертә.

1991 елның 31 августында Кыргызстан Республикасы үзен суверен дәүләт дип игълан итте. Республика оешуның беренче көннәреннән үк толерантлык һәм гуманлылык культурасын үстерү, милләтара һәм конфессияара үзара аңлашуны, җәмгыятьтә гражданлык килешүен ныгыту, илнең барлык гражданнарын, аларның милләтенә һәм дини карашларына карамастан, бердәй хокуклар һәм мөмкинлекләр белән тәэмин итү дәүләт сәясәтенең иң мөһим өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып тора.

Татар диаспорасы вәкилләре, Кыргызстан җәмгыятенең аерылгысыз өлеше буларак, илнең фән һәм мәгариф өлкәләренә, кыргыз милли сәнгате үсешенә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

Татарларның бу якларга күченеп килүенә төрле сәяси һәм икътисади факторлар сәбәп булган. Телләрнең охшашлыгы, гарәп графикасы нигезендә язу һәм уртак дин, охшаш гореф-гадәтләр, яшәү рәвеше татарларның бу якларга күпләп күчеп килүенә китергән.

XIX гасырның беренче яртысында Россиянең яңа сату базарлары, яңа кәрван юлларын эзләве, тулаем алганда, Төркестандагы дала халыклары белән сәүдә элемтәләрен киңәйтүе татар сәүдәгәрләрен кыргызлар яшәгән төбәккә алып килә. Алар Кыргызстанга беренчеләрдән булып күченеп утыралар, соңрак аларга башка катлау вәкилләре дә иярә [Ярков, 1996, с. 12].

Кыргызстанның Россия составына кушылуы (1862) икенче бер тарихи вакыйга – Россиядә крепостной хокукны юкка чыгару (1861) белән туры килә. Ирек алган крестьяннар, үгез җигелгән арбаларга төялеп, Азиягә күченеп утыралар. Бу төбәккә руслар, украиннар, белоруслар, татарлар һәм башка Идел буе халыклары килә [Палагина, 2005, с. 14].

XX гасыр башында тел белгече Ш. Мусин билгеләп үткәнчә, «татарларны Сөлүктә күмер рудникларында да, Ошның эре сәүдә йортларында да һәм Пишпәкнең сәнәгать предприятиеләрендә дә очратырга була» [Ахмерова, Мурадымов, 2010, с. 94].

Татар дин әһелләре кыргызлар арасында ислам динен ныгытуда һәм аң-мәгърифәт таратуда мөһим роль уйныйлар. Ул чорда мөселман китаплары 13 типографиядә басылган, шуларның сигезе Урта Идел буе шәһәрләрендә урнашкан була. Гарәп хәрефләре белән татар телендә язылган китапларны башка төрки халыклар да укыган. Җирле халыкларның үз телләрендәге беренче китаплары Казанда һәм Оренбургта нәшер ителгән. Мәсәлән, кыргыз телендә беренче китап 1913 елда «Кәримов, Хөсәинев һәм Ко» матбагасында басылып чыга [Куцева, Ешмухамедова, 2005, с. 74]. Кыргызстанда татар мөгаллимнәре аеруча хөрмәт казанган. Татарлар 1920–1930 елларда кыргыз интеллигенциясен әзерләүгә зур өлеш кертәләр. Кыргызстан мәктәпләрендә һәм югары уку йортларында Кормаевлар, Мусиннар, Шәмгуновлар, Яушевлар һ.б. күренекле укытучы династияләре белем бирә.

Совет чорында республикада татарларның саны тагын да арта: бу Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары, 1950–1980 елларда төбәкне индустрияләштерү барышында күченеп килүчеләр белән бәйле [Мурадымов, 2012, с. 625]. Республикалар арасында чикләүләр булмау да төбәктә татарларның саны актив артуга уңай йогынты ясаган: 1926 елда Кыргызстанда аларның саны 4902 кеше, 1959 елда – 56274, 1979 елда – 71744, 1989 елда 70068 кеше исәпләнгән. СССР таркалгач, Кыргызстандагы татарлар саны, тарихи ватаннарына һәм башка төбәкләргә күченеп китү сәбәпле, күпкә кимегән.

Хәзерге вакытта (2022 ел) республикада 11219 татар яши, бу сан ил халкының (6936156 кеше) 0,2% ын тәшкил итә [Перепись населения...]. Алар, башлыча, Бишкәк (1926 елга кадәр Пишпәк, 1926–1991 елларда Фрунзе), Ош, Җәлалабад, Каракүл (элекке Пржевальск), Карабалта, Карасу, Кызылкыя, Сөлүктә, Ташкүмер, Талас, Токмак шәһәрләрендә һәм Ноокат, Араван, Атбашы, Сокылык һ.б. авылларда яшиләр.

СССР таркалгач, күпчелек халыкларда милли үзаң үсеше күзәтелә. Бу күренеш Кыргызстан татарларына да хас була. 1991 елда,

милли-мәдәни үсеш мәсьәләләрен хәл итү максатыннан, Кыргыз Республикасында иҗтимагый берләшмәләр турында закон кабул ителә [Закон...].

Татарлар күпләп яшәгән урыннарда иҗтимагый үзәкләр, җәмәгать оешмалары төзелә башлый. Бишкәк шәһәрендә генә дә шундый өч оешма барлыкка килә: Кыргызстан халыклары ассамблеясының «Туган тел» татар-башкорт мәдәни үзәге; Кыргызстан татарлары берлеге «Бердәмлек»; Кыргыз-татар дуслыгы һәм хезмәттәшлеге җәмгыяте. Шулай ук мондый оешмалар өлкәләрдә һәм районнарда булдырылган: «Илкәем» татар-башкорт милли мәдәни үзәге (Ош шәһәре); «Идел» татар-башкорт мәдәни үзәге (Җәлалабад өлкәсе); «Татулык» милли үзәге (Каракүл шәһәре); «Идел» татар-башкорт милли мәдәни үзәге (Карабалта шәһәре), «Ак барс» татар-башкорт милли-мәдәни үзәге (Токмак шәһәре) һ. б.

Бу иҗтимагый оешмаларның эшчәнлеге, беренче чиратта, татар диаспорасын берләштерүгә, аларның үзенчәлекле милли мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән.

«Илдә милләтара татулык һәм тотрыклылык өлкәсендә дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, шулай ук ил халкының бердәмлеген ныгытуда аның ролен алга таба арттыру максатларында» 1994 елның гыйнварында Кыргызстан халкының беренче корылтаенда Кыргызстан халыклары ассамблеясы оештырыла [Акматова, Нарматов, 2022, с. 167]. Кыргызстан халыклары ассамблеясының төп бурычы – республикада яшәүче милләтләрнең татулыгын, бердәмлеген ныгыту.

Җәмгыятьнең милләтара татулыгын һәм дини толерантлыгын, рухи һәм мәдәни байлыгын саклауда Кыргызстан халыклары ассамблеясының Ош бүлеге каршындагы «Илкәем» татар-башкорт милли-мәдәни үзәгенең дә эшчәнлеге игътибарга лаек. Мәдәни үзәк 1991 елда татар һәм башкорт җәмәгатьчелеге вәкилләре тырышлыгы белән Кыргызстан халыклары мәдәниятенә лаеклы өлеш кертү, милләтара татулыкны ныгыту, татар һәм башкорт халыкларының милли үзаңын күтәрү, милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне, татар һәм башкорт телләрен торгызуга, саклауга һәм үстерүгә ярдәм итү, яшьләрне иң яхшы милли традицияләр үрнәгендә тәрбияләү, БДБ илләрендә һәм чит илләрдәге ватандашлар белән мәдәни элемтәләр урнаштыру һәм аларны саклау максатларында оештырыла. Үзәкне оештыручылар Мәгуба Фәхретдинова, Мөхсинә Әхмәрова, Әлфия Яппарова, Әүхат Харрасов, Рэм Музиповлар кебек активистлар була, ә рәис итеп Рәүф Дусеев сайлана. Юстиция органнарында рәсми теркәлү турында таныклык 1995 елның 3 июлендә алына.

Бүген «Илкәем» иҗтимагый үзәгенең (рәисе – Равилә Әхмәрова) Үзген (җитәкчесе – Сәлимә Дадабаева), Кара-Суй (җитәкчесе – Җәүһәрия Шагаева), Араван (җитәкчесе – Зөһрә Нуриева), Наукат (җитәкчесе – Сабирә Әминҗанова), Алай (җитәкчесе – Әлфия Зарипова) районнарында вәкиллекләре эшли.

Үзәк каршында халкыбызның тарихын, мәдәниятен һәм туган телен өйрәнү буенча якшәмбе мәктәбе (укытучылары – Миниавгат Харасов, Дания Кудакаева, Фина Закирова, Шаимә Насретдинова һ.б.) һәм «Илкәем» җыр ансамбле эшләп килә. Якшәмбе мәктәбенә өлкән яшьтәге кешеләр дә йөри. Яшьләр оешмасы да бар. Ветераннар (М. Хәмидуллин, Я. Әмиров, Х. Әхмәтова, А. Вәлиев, Г. Канюков, Т. Шаһиморатов һ.б.) белән беррәттән бу чараларда урта буын вәкилләре һәм балалар да (М. Рахматова, А. Байбекова, Д. Байбекова, Р. Мостафин, Р. Сәйдәшева, Х. Абдуллина һ.б.) актив катнаша.

Үзәк төзелүнең беренче көннәреннән үк оешма әгъзалары һәм активистлары төбәкнең иҗтимагый тормышында катнашалар, шул исәптән: республикакүләм җыеннар, халык бәйрәмнәре һәм төрле мәдәни чаралар оештыралар, Кыргыз Республикасы Дәүләт бәйсезлеге көнен, 1 Майда Ош өлкәсе халыкларының Дуслык һәм теләктәшлек бәйрәмен, Җиңү көнен, Нәүрүз, Халыкара өлкәннәр көнен, милли-мәдәни үзәкләре булган халыкларның дуслык кичәсен һ.б. уздыруга үз өлешләрен кертәләр. Үзәк шулай ук милли мәдәният көннәрен оештыра, татар халык шагыйрьләренә багышланган иҗат кичәләре үткәрә. Апрель аенда ел саен Габдулла Тукайны искә алу һәм туган тел көне, хәйрия чаралары уза. Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Ош шәһәре мэриясе, Кыргызстан халыклары ассамблеясы ярдәме белән ел саен июнь аенда Татарстан артистлары катнашында Сабан туе үткәрелә. Сабантуйлар Ош шәһәрендә инде ике дистә елдан артык оештырыла һәм татарларны гына түгел, башка халыкларны да бер мәйданга җыя. Бәйрәмдә төрле милләт вәкилләре: руслар, кыргызлар, үзбәкләр, башкортлар, татарлар, немецлар һ.б. катнаша. Сабантуй кешеләрне берләштерә, таныштыра, дуслаштыра, туганлаштыра, бәйрәмдә милли мәдәниятнең традицион элементлары, йолалары, уеннары һ.б. күрсәтелә. Кыргызстанның башка шәһәрләре активистлары белән берлектә Үзәк әгъзалары Казан шәһәрендә уза торган Бөтендөнья татар конгрессы корылтайларында республика исеменнән чыгышлар ясыйлар.

Татар халкының күп кенә күренекле вәкилләренең тормышы һәм эшчәнлеге Ош шәһәре белән бәйле. Бу шәхесләр арасында Ош педагогия институтының беренче буын укытучылары Әкрәм Вәли улы Вәлиев, Кязим Дәүләт улы Шәмгуновны махсус атау сорала. Шулай ук яшь буын белгечләрен, галимнәрен, педагогларын тәрбияләүгә дә зур өлеш керткән шәхесләрне аерып күрсәтергә кирәк. Менә аларның кайберләренең исемнәре: физиклар Ферран Насыйп улы Заитов, Рауэль Нигъмәт улы Хәлиуллин; математиклар Җәүдәт Сабир улы Мостафин, Тавакал Мамур улы Мамуров; педагог Мәрьям Габделхак кызы Абдуллина; филологлар Равил Хәсән улы Моратов, Рэм Габит улы Музипов, Николай Михтях улы Морадымов; юристлар Равил Ягъсуб улы Мазитов, Гөлшат Әхмәтҗан кызы Хәмидулина; медицина галимнәре Римма Таһир кызы Сөләйманова, Данияр Дамир улы Рисалиев һ.б., мәгариф

өлкәсендә Рафаэль Әүхәди улы Абдразаков, Халидә Борис кызы Сабитова һ. б. педагогларның исемнәре билгеле. Социалистик Хезмәт Герое, ефәк комбинаты тукучысы Алия Габдулла кызы Сөнчәлиеваның да (1926–2016) тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Ош шәһәреннән аерылгысыз. Муса Җәлил истәлегенә багышланган очрашуларда геройшагыйрьнең «Идел-Урал» батальоны буенча көрәштәше – Рушад Билал улы Хисаметдиновның актив катнашуы билгеле.

Шул рәвешле, татарлар күпмилләтле Кыргызстанның тигез хокуклы гражданнары булып тора. Алар Кыргызстанны үз Ватаны дип саныйлар. Монда татарларның берничә буыны үскән. Шушы вакыт эчендә Кыргызстан татарлары, нигездә, үзләренең милли үзаңын, үзенчәлекле мәдәниятен саклап кала алганнар. Шул ук вакытта башка этник мохиттә, тарихи Ватаннарыннан еракта көн күрүләре татарларның социаль-мәдәни үсешенә йогынты ясап, үзенчәлекле җирле яшәү рәвешен формалаштырган.

**Әдәбият**

*Акматова А.Т. Нарматов Х.Б.* Формирование Ассамблеи народа Кыргызской Республики как основного института согласия в соответствии с концепцией «Кыргыз жараны (гражданин)» (историко-правовой аспект) // Наука, новые технологии и инновации Кыргызстана. 2022. № 10. С. 166–170.

*Ахмерова Р.М., Мурадымов Н.М.* Вовеки нельзя нашу дружбу разбить (Сыны и дочери татарского народа на кыргызской земле) // Татары в истории Киргизии. Прошлое и современность: Материалы Международной научно-практической конференции. г. Бишкек, 6 июня 2009 г. Бишкек: Изд-во Кыргызско-Российского Славян. ун-та, 2010. С. 93–98.

Закон КР от 1 февраля 1991 года № 359-XII «Об общественных объединениях». URL: https://cbd.minjust.gov.kg/860/edition/600952/ru (мөрәҗәгать көне: 5.03.2024).

*Куцева О., Ешмухамедова Л.* Татары // Этнические группы народа Кыргызстана. Бишкек: Изд-во Кыргызско-Российского Славян. ун-та, 2005. С. 69–75.

*Морадымов Н.М.* Кыргызстан Республикасы // Татар энциклопедиясе: 6 томда. Казан: «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты». 2012. 3 т.: К–Л. 716 б.

*Палагина Н.Н.* Как создавался народ Кыргызстана // Этнические группы народа Кыргызстана. Бишкек: Изд-во Кыргызско-Российского Славян. ун-та, 2005. С. 11–22.

Перепись населения и жилищного фонда Кыргызской Республики 2022 года. URL: https://www.stat.kg/ru/publications/perepis-naseleniya-i-zhilishnogo-fonda-kyrgyzskoj-respubliki-2022-goda-kniga-i-osnovnye-socialno-demograficheskie-harakteristiki (мөрәҗәгать көне: 4.03.2024).

***Габдулхакова Гөлшат Мансур кызы,***
*ТР ФА М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Татар диаспорасын өйрәнү үзәге фәнни хезмәткәре*

***Халилова Ләйсән Ринат кызы,***
*ТР ФА М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Татар диаспорасын өйрәнү үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 796

***Д.М. Абдуллина,***
***Ә.Х. Мөхәммәтҗанов***

# УКУ-УКЫТУ ПРОЦЕССЫНДА МИЛЛИ УЕННАР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ШӘХЕС ТӘРБИЯЛӘҮДӘГЕ РОЛЕ

Статья посвящена роли применения некоторых педагогических технологий в научно-профессиональной деятельности учителя физической культуры. Авторы считают, что активное использование национальных сюжетных игр создаёт здоровый психологический климат на занятиях, способствует формированию эмоционально положительного отношения к миру, развивает когнитивную функцию, творческую инициативу и познавательную активность учащихся, позволяет разнообразить процесс физического воспитания. При этом авторы статьи предлагают учитывать обязательность мотивации к той или иной двигательной активности, а также эмоциональное состояние детей. Применение народной педагогики в процессе обучения и воспитания снижает эмоциональную напряженность, улучшает комфортность взаимоотношений всех участников образовательного процесса.

**Ключевые слова**: положительная мотивация к процессу обучения, физическое и духовное развитие, здоровьесберегающие технологии, воспитание физически и психологически здоровой личности.

The article is devoted to the role of the application of some pedagogical technologies in the scientific and professional activities of a physical education teacher. The authors believe that the active use of national story games creates a healthy psychological climate in the classroom, promotes the formation of an emotionally positive attitude to the world, develops cognitive function, creative initiative and cognitive activity of children and allows to diversify the process of physical education. At the same time, the authors of the article propose to take into account the mandatory motivation for a particular motor activity, as well as the emotional state of students. The use of folk pedagogy in the process of education and upbringing reduces emotional tension, improves the comfort of relationships between all participants in the educational process.

**Keywords**: positive motivation for the learning process, physical and spiritual development, health-saving technologies, education of a physically and psychologically healthy personality.

Уку-укыту процессында физик тәрбия дәресләре укучыларның сәламәтлеген, чыдамлыгын, өлгерлеген кайгырту чарасы гына түгел, бу дәресләр балаларның психик, әхлакый һәм социаль үсешендә дә мөһим урын тота. Шуңа күрә әлеге төр фәнни-педагогик эшчәнлектә башка чаралар белән бергә сәламәтлекне саклау технологияләренә мөрәҗәгать итү әһәмиятле. Балаларга белем бирү һәм аларны тәрбияләүдә бу төр технологияне иң әһәмиятлесе дияргә мөмкин, чөнки ул мәгълүмат тапшыруның төрле формаларын берләштерүгә

нигезләнә; балаларның танып белү эшчәнлеген яхшырта; яшь үзенчәлекләрен, хәрәкәт активлыгын, күнекмәләр аша бирелә торган биремнәрнең катлаулылыгын исәптә тотуның оптималь комбинациясен формалаштыруда катнаша.

Заманча технологияләрне куллануның максаты – тәне генә түгел, акылы, психологик халәте дә сау, кызыксынучан, үз-үзе һәм тирәлек белән һәрьяклап гармонияле иҗади шәхес тәрбияләү. Бу максатка җитү өчен түбәндәге бурычларның үтәлүе шарт: мәктәптә укыган вакытта укучыга сәламәтлеген саклау һәм ныгыту мөмкинлеген тәэмин итү, сәламәт яшәү рәвеше буенча кирәкле белемнәр, күнекмәләр формалаштыру, алган белемнәрен көндәлек тормышта кулланырга өйрәтү, укучыларның һәм гомумән гаиләләрнең сәламәт тормыш эшчәнлеген төзүдә ата-аналарга ярдәм итү; укуга кызыксынучан мөнәсәбәт булдыру өчен шартлар тудыру. Бу җәһәттән дәресләрдә сәламәт психологик климат булдыруны физик тәрбия дәресләрендә сәламәтлекне саклауның төп юнәлешләреннән берсе дип саныйбыз. Мәсәлән, физик тәрбия күнекмәләре аша уңышка ирешү теләге тәрбияләү уку процессына гомумән уңай мотивация формалаштырырга булыша, шуның белән эмоциональ киеренкелекне киметә, белем бирү процессында катнашучыларның үзара мөнәсәбәтләрен яхшырта, балаларның физик яктан сәламәт, рухи яктан бай булып үсүен тәэмин итә.

Әлеге максатларга ирешү юлында уеннарның әһәмияте бик зур. Билгеле булганча, бала уйный-уйный үсә. Бала уеннар аша олы кеше булырга әзерләнә, чын шөгыльгә, хезмәткә, тормыш-көнкүрешкә дә уен ярдәмендә төшенә. Балалар уеннарының яшь буынны физик һәм әхлакый тәрбияләү, киләчәк тормышка әзерләү функциясен үтәве галимнәр тарафыннан инде расланган. Татар галимнәре дә, рус галимнәре дә, шулай ук кайбер әдипләребез дә уеннар темасына еш мөрәҗәгать иткәннәр, аларны төрле яклап өйрәнгәннәр, төрләргә бүлеп, классификацияләгәннәр, дәреслекләргә, җыентыкларга керткәннәр, педагогикада файдаланганнар, балалар өчен язылган әдәби әсәрләргә нигез итеп алганнар. Әйтик, М. Иванов, С. Кукляшев, К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Толымбайский, Н. Исәнбәт, Р. Ягъфәров кебек күренекле затлар татар балалар уеннарына күп игътибар биргән, аларны туплаган, өйрәнгән.

Бүгенге заманча технологияләр чорында педагогикада халыкның гореф-гадәтләренә туры килә торган уеннарның функциясе чикләнә төшә кебек. Әмма бу беренче карашка гына шулай. Хәрәкәтле милли уеннарны яңа технологияләр чарасы буларак тормышка ашыру, уку-өйрәнү процессына кертеп җибәрү – хәзерге көндә дә актуальлеген югалтмаган эш төрләренең берсе. Милли уеннарны уку-укыту процессында куллану укучыларны физик чыныктыра, танып белү активлыгын арттыра, аларның яшьтәшләре белән аралашуына, социаль планда җайлашуына йогынты ясый. Татар милли уеннарына мәктәпләрдә аерым игътибар бирү хәзерге заманда миллилекне саклау, үз йөзебезне югалтмау өчен дә мөһим. Халыкның элек-электән кулланыла килгән

педагогик тәрбия алымнарын заманча уку-укыту технологиясе буларак файдалану – һәрьяктан максатка ярашлы эшчәнлек. Заманча уку-укыту технологияләренә миллилекне өстәүнең уңай нәтиҗәләре [Мухаметзянов, с. 39] дәресләрдә халык педагогикасын файдалануга булган ихтыяҗның бүген дә көн кадагында булуын раслый.

Балалар күп вакытларын мәктәптә, мәктәп яны, җәйге лагерьларда үткәрәләр. Бүгенге көндә физик тәрбия дәресләрендә, дәрестән тыш чараларда, лагерьларда физик тәрбия белән шөгыльләнгәндә халыкның милли уеннарын файдалану тәҗрибәсен кече һәм урта яшьтәге сыйныфлар өчен мәктәп программаларына кертеп җибәрү мөһим. Мондый тәҗрибә азмы-күпме «Татар әдәбияты»н укытуда инде кулланылып та килә. Әйтик, башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен төзелгән электрон дәреслектә [Мөхәрләмова, Абдуллина, б. 66–71] моның уңышлы мисалларын табарга мөмкин. Дәреслектә «Сәламәт яшибез, спорт белән шөгыльләнәбез» дип аталган махсус бүлек бар. «Хәрәкәттә – бәрәкәт» принцибын алга куйган әлеге бүлекнең «Шәп дәрес – физкультура» дигән бүлекчәсендә физкультура дәресенең тән саулыгы өчен дә, рухи яктан үсү ягыннан да әһәмияте ассызыклана, балаларга физик тәрбия дәресләрендә милли уеннар уйнау үрнәкләре тәкъдим ителә, аларның тәртибе аңлатыла. Биредә «Ябалак», «Мияумияу, нинди төс» дигән уеннар аша балаларда сөйләү-фикерләү мөмкинлеге, гомумиләштерү, чагыштырып һәм янәшә куеп бәяләү күнекмәләре үстерелә.

Физик тәрбия дәресләрендә, аеруча кече һәм урта сыйныфларда, халык уеннарын әби-бабаларыбыз кечкенә чакларында уйнаганча түгел, нәкъ менә бүгенге яшьләргә-балаларга кызыклы булырлык итеп тәкъдим итү үзен аклый. Нинди дә булса уенның элементларын файдалану, уйнаганда әйтелә торган сүзләрне хәтердә яңарту да укучылар өчен шактый кызыклы һәм күнекмә буларак отышлы. Болай эшләгәндә физик тәрбия дәресләрендә этник элементлардан файдалану мөмкинлеге арта. Эзләнү барышында шунысына игътибар иттек: йөгерү, сикерү, үрмәләү, реакция тизлеге кебек физик күнекмәләр булдыруга юнәлтелгән милли уеннарыбыз шактый күп.

Уеннарның иң зур төркемен хәрәкәтле уеннар тәшкил итә. Аларның нигезендә төрле хәрәкәтләр (йөгерү, сикерү, үрмәләү, атлау, ыргыту һ.б.) ята. Хәрәкәтле уеннар бик күп һәм аларны берничә принциптан чыгып төркемлиләр. Мәсәлән, 1) уенчыларның төркемләнүе ягыннан – командаларга бүленә һәм бүленми торган төрләргә; 2) төп хәрәкәтләрнең тибы буенча – йөгерү, сикерү, үрмәләү, ыргыту күнекмәләрен үз эченә алган төрләргә; 3) килеп чыгышы ягыннан – халык, коллектив һәм индивидуаль уеннарга бүленә. Балалар уенын фольклор үрнәге буларак караганда, уеннарны композицион үзенчәлеге (структурасы) буенча төркемләү кулай [Татар халык иҗаты, б. 6–7]. Моннан чыгып, балалар өчен уеннарны сюжетлы һәм сюжетсыз хәрәкәтле уеннар дигән ике төркемдә карыйбыз.

Сюжетлы хәрәкәтле уеннарга роль бүлешеп уйнау хас, шуңа күрә аларда драматик үзенчәлек алга чыга. Шушы үзенчәлекне исәпкә алып, татар балалар фольклорында мондый уеннарны «драма уеннары» дип йөртәләр [Татар халык иҗаты, б. 18]. Рольләрне башкаручылар уен кагыйдәсе чикләреннән чыкмый. Шунлыктан аларның ни кылыры баштан ук билгеле була.

Мәсәлән, «Алырмын кош» уены тулы бер спектакльне хәтерләтә. Монда, драма жанрына ярашлы, һәр уйнаучыга билгеле бер роль бирелә: ана каз, козгын, бәпкәләр. Уен бер урында, бер вакытта бара. Ягъни драмага, театрга хас урын берлеге, вакыт берлеге кануны мондый уеннарда да күзәтелә. Театраль күренеш барган урын, әйтик, – спорт залы. Сюжет төенләнештән башлана: ана каз үзенең бәпкәләрен зал уртасына алып чыга, бәпкә ролендәгеләр үлән ашау, су эчү кебек хәрәкәтләрне имитацияли. Вакыйга үсеше бәпкәләр янына козгын килеп чыгу, аның бәпкәләр тирәли йөрү күренешләре аша ачыла. Конфликт козгынның бәпкәләрне тартып алуына, ана казның аларны саклап калырга тырышуына бәйле бирелә.

Уенны уйнаганда козгын, ана казның игътибарын бәпкәләрдән башка нәрсәгә юнәлтә торган хәйләле сүзләр әйтә. Элек уенда: «Әнә, күктән койрыклы йолдыз төшә!» кебек гыйбарәләр әйтеп, игътибарны читкә юнәлтсәләр, уенга бераз яңалык кертеп, физик тәрбия темасына имтихан алу максатына яраклаштырып тәкъдим итәбез. Бәпкәләрен козгыннан саклау барышында ана каз козгынның мондыйрак сорауларына да җавап бирергә тиеш була:

– Казанда үткән нинди зур спорт ярышларын беләсез? Нинди бөек татар спортчыларын беләсез? Футбол командасында ничә кеше катнаша? Кайсы туп авыррак: баскетболныкымы, әллә волейболныкымы? Милли көрәш кагыйдәләрен атагыз һ.б.

Баланың яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, физик культура һәм спорт темасына башка сораулар да бирергә мөмкин. Уенда козгын, сораулар бирә-бирә, бәпкә чүпләвен дәвам итә. Шуңа күрә бәпкәләр дә, ана каз да, сорауларга дөрес итеп җавап бирү белән бергә, козгын тырнагына эләкмәс өчен, бик уяу булырга тиешләр. Уен укучыларда җитезлек, өлгерлек, сүзне гамәл белән бәйли алу кебек сыйфатлар тәрбияли; башкалар арасында көчең белән дә, зирәклегең белән дә аерылып тору мөмкинлеге бирә.

«Хан» уенында күп кеше берьюлы катнаша ала. Уйнаучылар арасыннан берсен хан итеп сайлап куялар. Үзләре читкә китеп, берәр эш турында уйлап, хан янына киләләр.

– Исәнмесез, хан хәзрәтләре! – диләр.

Хан боларга:

– Исәнмесез! Кайда йөрдегез?Ниләр күрдегез? Сөйләп бирегез! – ди.

Шуннан балалар алдан уйлаган эшләрен кул хәрәкәтләре белән күрсәтеп аңлата башлыйлар. Бу хәрәкәтләрдән хан берни аңламаса, уен кабат шул ук рольдә дәвам итә. Хан эшне аңлап алып, ни турында

сөйләүләрен әйтеп бирә алса, уенчылар төрлесе төрле якка таралышалар, йөгереп качалар. Хан арадан берсен тотып калырга тиеш. Тотылган бала хан була, уен шул ук тәртиптә дәвам итә.

Бүгенге шартларда бу уенны да бераз үзгәртеп уйнарга мөмкин. Әйтик, ханның соравына җавап итеп, төрле спорт төрләрендәге хәрәкәтләр күрсәтелә. Мисал өчен, балалар чаңгы шуудагы «бер адымлы шуу» («одношажный ход»), «ике адымлы шуу» (двухшажный ход»), «адымсыз йөрү» («бесшажный ход») яисә чаңгыда таудан менгәндәге «чыршы ясау» («ёлочка») алымнарын хәрәкәтләр белән аңлаталар. Баскетбол тубын дөрес итеп кәрҗингә кертү ысулын, тупны идәндә йөртү кагыйдәсен, волейбол тубын каршы як командага бирү («подача волейбольного мяча») кебек кагыйдәләрне дә туп кулланмый гына сүзсез хәрәкәт белән күрсәтәләр. «Хан» уены темага кагылышлы белемнәрне ныгытырга, спорт төрләрен тагын да популярлаштырырга ярдәм итә, эмоциональлекне, дөрес хәрәкәтләр ясый белүне үстерә.

Үзләрен нинди дә булса образ итеп күзаллау уйнаучыларны рольгә кертә, иҗат мөмкинлекләрен ача. Физик тәрбия дәресләрендә йөгерү, сикерү, чаңгыда узышу, йөзү кебек күнекмәләрне сюжетлы хәрәкәтле уеннарга нигезләп башкару уенга тизрәк кереп китәргә, тиешле күнекмәләрне җиңел үзләштерергә булыша.

Сюжетсыз хәрәкәтле уеннар исә гел хәрәкәттән генә тора. Нинди дә булса конфликтка корылган сюжет мондый уеннарда күзәтелми, роль бүлешү дә булмый, әмма һәркайсының үз кагыйдәсе бар. «Өченче кеше артык», «Дүртпочмак», «Ун таяклы», «Уникe таяк», «Әбәкле», «Очты-очты», «Аша-ашама» кебек уеннар шундый уеннар рәтенә керә. Сюжетсыз хәрәкәтле уеннарның кайберсендә качып котылу, икенчеләрендә узышып көч сынашу, өченчеләрендә утырырга ирек бирмичә, бастырып тоту максат итеп куела. Мондый уеннар командаларга бүленеп уйнауны таләп итә. Әйтик, качыш уеннары, гадәттә гөрләүче, ягъни көтүче сайлаудан башлана. Менә, мәсәлән, «Ун таяклы» дип аталган уенда көтүчене болай сайлыйлар:

Әлчи, бәлчи,
Әни күлмәк үлчи.
Әнә тора чыпчык,
Син кал, бу – чык.

Сюжетсыз хәрәкәтле уеннар тән сыгылмалылыгын арттыру, кыюлык, җитезлек кебек сыйфатлар тәрбияләү ягыннан әһәмиятле. Алар дәрестә уңай мохит һәм бердәмлек халәте булдыруга ярдәм итә. Хәрәкәтле уеннар кешедә кыюлык, егетлек, чыдамлык, ихтыяр көче һ.б. әхлакый сыйфатлар тәрбияли. Уендагы активлык, уен һәм аның нәтиҗәсе белән бәйле шатлыклы кичерешләр кәефне күтәрә. Уен кагыйдәләре җиңүне гадел көрәштә яуларга өйрәтә, җитезлекне генә түгел, зирәклекне дә сыный. Уеннар аша бала дөньяны танып белә, матурлыкны күрергә өйрәнә. Уеннар уй-фикерләрне зыянлы гамәлләрдән читкә юнәлтә, юньле эшләр генә кылу юнәлешен күрсәтә.

Шулай итеп, хәрәкәтле уеннарның бөтен төрләре дә баланың хәрәкәткә ихтыяҗын канәгатьләндерә, шушы юнәлештә тәҗрибә туплауга булышлык итә. Халыктан да акыллырак, елгыррак, җитезрәк, хәйләкәррәк, көчлерәк, югарырак булу мөмкин түгел. Милли уеннар куллану укучының физик мөмкинлекләрен арттырып кына калмый, аң-зиһенне үстерүгә дә булыша, туган телебезне, гореф-гадәтләребезне актуальләштерә, башка милләт балаларын татарларның рухи хәзинәсе белән таныштыра. Яңартып кулланганда, милли уеннар әле дә – зур тәрбия чарасы. Халык уеннарына мөрәҗәгать итеп, аларны гамәлдә куллану шуны раслый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, мәктәптә уку-укыту процессында укучыларның сәламәт, конкуренциягә чыдам көчле шәхес булып тәрбияләнүләреннән тыш, аларның җирле һәм милли үзенчәлекләргә дә тиешле игътибар бирә белә торган, моның әһәмиятен алгы планга куючы аңлы кешеләр булып җитешүләре дә мөһим. Бу югары максатларга ирешүдә, теге яки бу хәрәкәт активлыгына мотивацияләүдә рухи мирас хәзинәләренә дә өстенлек бирү укучыларның эмоциональ халәтен дөрес юнәлешкә куюны тәэмин итә. Вербаль иҗат мәктәп укучыларын тәрбияләүдә киң кулланыла ала, ул дөньяга эмоциональ яктан уңай мөнәсәбәт формалаштыруга гына түгел, ә укучыларның когнитив үсешенә дә яхшы йогынты ясый. Балаларның мотивациясен һәм иҗади инициативасын үстерүнең яңа формаларын эзләү хисабына хәрәкәтле милли уеннарны уку-укыту процессында куллану физик тәрбия процессын төрләндерергә дә мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**


Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз уен / Төзүчесе, фәнни мәкаләләр һәм искәрмәләр авторы Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 275 б.

*Мухаметзянов А.Х.* Организация двигательной активности учащихся с использованием элементов игрового фольклора // Современные тенденции в науке и образовании: сб. науч. трудов. В 6 ч. Ч. II. М.: АР-Консалт, 2014. С. 35–40.

*Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М.* Әдәби уку. 3 сыйныф. 2 кисәктә. 2 нче кисәк. Башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (Татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен), рәс. Д. Нәүрузова. Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023. 112 б.: рәс. б-н.

Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры. Томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Р.Ф. Ягъфәров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 336 б.



***Абдуллина Диләрия Марат кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Мөхәммәтҗанов Әсгать Хатип улы,***

*Казан шәһәре Совет районының «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 167 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»нең югары квалификацияле физик тәрбия укытучысы*

УДК 791.43.03

*Е.П. Алексеева*

# 1920–1930 ЕЛЛАРДА ТАТАРСТАНДА КИНО СӘНГАТЕ БАРЛЫККА КИЛҮ
## («Татаркино»ның 100 еллыгы уңаеннан)

На основе архивных материалов автор раскрывает проблемы становления и развития киноискусства Республики Татарстан: историю создания документальных и игровых фильмов, «Булат Батыр», «Мои университеты» первой в Поволжье киноорганизации «Таткино». Рассматриваются организационные вопросы по созданию татарского отделения Союзкинохроники – Казанской студии кинохроники 1 апреля 1932 года.
**Ключевые слова:** киноискусство, Казань, татарская культура, кинотеатр, кинофильм, режиссёр, актёр.

Based on archival materials, the author reveals the problems of the formation and development of cinema in the Republic of Tatarstan: the history of the creation of documentaries and feature films, «Bulat Batyr», «My Universities» of the first film organization in the Volga region «Tatkino». Organizational issues on the creation of the Tatar branch of Soyuzkinokhronika – the Kazan newsreel studio on April 1, 1932 are considered.
**Keywords:** cinematography, Kazan, Tatar culture, cinema, film, director, actor.

Татарстанның кино сәнгате бик катлаулы иҗтимагый-сәяси шартларда барлыкка килә һәм үсә. Аның оешу еллары ТАССР төзелү белән тәңгәл килә. Совет строе урнашкан чорда Казанда сәяси хәл тотрыклы булмый. Мәскәү баштан ук «кызыл империя» картасында Татарстанны һәм аның партия оешмасын иң «кайнар нокталарның» берсе дип билгели [Султанбеков, с. 6]. 1925 елга кадәр Казанда өлкә комитеты секретарьлары ел саен диярлек алмашынып тора, Үзәк Комитет комиссияләре дә бирегә еш җибәрелә.

Шуңа да карамастан, 1924 елның 13 февралендә Казанда беренче кино оешмасы эшли башлый. Ул яшь республиканың кино җитештерү һәм кино прокатын да үз кулларына ала. Моңарчы сакланып калган кинотеатрларда кино күрсәтү белән «Совкино», «Севзапкино» прокат конторалары һәм шәхси эшмәкәрләр шөгыльләнгән. Алар арасында конкуренция көчле булган.

Озакка сузылган һәм катлаулы сөйләшүләрдән соң Татарстан Халык мәгариф комиссариаты (Татнаркомпрос) белән Дәүләт киносы (Госкино) арасында шартнамә төзелә. Шуның нигезендә беренчесе ТАССР, шулай ук күрше автоном өлкәләр территориясендә монополияле кинопрокат хокукына ия була. «Таткино» Татар кинематография берләшмәсенең уставы пай башлангычларында эшләнә.

Яңа оешмага дәүләт тарафыннан бүлеп бирелгән акча гына җитми, шуңа күрә «Таткино» дәүләт предприятиеләренә кинематография берләшмәсе пайчылары булырга тәкъдим итә. Җәмәгатьчелек әлеге тәкъдимне игътибарсыз калдыра. Шуннан соң Халык мәгариф комиссариаты кинотеатрларның шәхси арендаторлары белән хезмәттәшлек итәргә мәҗбүр була. Иң кулай тәкъдимне «Электро» кинотеатрының шәхси пайчылары В. Егоров, В. Лавров һәм А. Ширшов кертә, Халык мәгариф комиссариаты коллегиясе аны шунда ук кабул да итә. Яңа Устав раслана.

«Таткино»ның устав капиталы 25 мең сум тәшкил иткән. Халык мәгариф комиссариаты үз өлешен акчалата түгел, ә кинематография инвентаре һәм мөлкәт белән керткән (13 мең сум); шәхси пайчыларныкы 12 мең сум булып (алтын сумнарда), акча һәм төрле кинематография җиһазларыннан торган. Бәяләү-кабул итү комиссиясенең сакланып калган актында, аерым алганда, түбәндәгеләр теркәлгән: «установка для печатания кинематографических надписей, штатив для киноаппарата с вращающейся платформой, киноаппарат «Гомон», объективы, негативная киноплёнка» [НА РТ, ф. Р-144, оп. 1, д. 1, л. 8, 12].

«Таткино»да 113 кеше штатта торган, оешманың Мәскәүдәге рәсми вәкиле дә алар исәбенә кергән. Идарәнең беренче рәисе Х. Сәйфи озак эшләмәгән, аннары бу вазифада аны В. Егоров алыштырган.

1924 елның 13 февраленнән «Таткино» рәсми рәвештә эшли башлый. Эш приоритетлары Уставта беркетелә: «Акционерное общество Татарское кинематографическое объединение «Таткино» учреждается с целью обслуживания культурных запросов рабочих, красноармейцев и крестьян через кино» [НА РТ, ф. Р-144, оп. 1, д. 1, л. 8, 12]. Республика халкының татар телендәге фильмнарга ихтыяҗы зур булу ассызыклана. Кинохроника төшерүне җайга салу, Казанда һәм бөтен республика территориясендә прокат һәм кинотеатрларны эксплуатацияләүне берләштерү күздә тотыла.

1924 елның 1 октябреннән «Таткино» «чиста дәүләт учреждениесе»нә әйләнә. Берләшмә үзгәртеп корыла – шәхси капитал аның составыннан чыгарыла.

«Таткино»ның эшчәнлеге турында күпсанлы хисаплар һәм докладлар (айлап) сакланган. Бу материаллар нигезендә вакыйгаларның хронологиясен торгызырга мөмкин.

Кинопрокатны монополияләштерү максатында «Таткино» баштан ук кинокартиналар фондын оештыра. Моның өчен Мәскәүдә зур метражлы 29 кинокартина, моннан тыш, табигать күренешләре күрсәтелгән һәм комик 62 картина шәхси эшмәкәрләрдән сатып алына. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле картиналар фонды туплангач, «Таткино» үзенең игътибарын кантоннарга, ягъни республика районнарындагы шәһәрләргә юнәлтә. Кантоннарны һәрьяклап тикшерү өчен «Таткино» ышанычлы вәкилләр (7 кешесен) җибәрә, алар урыннарда аппаратураның, җиһазларның техник торышын, кинога йөрешне, эшнең гомуми куелышын өйрәнәләр.

«Таткино»га Казандагы сигез кинотеатр керә. Хосусый милекче мөлкәтендәге «Гри-Гри» (элеккеге «Олимп», соңыннан «Унион») шәхси кинотеатры монополияләштерелә, әлеге кинотеатрны картиналар белән тәэмин иткән «Севзапкино» белән килешү төзелә. Шул ук вакытта бәяләрне «Таткино» көйләп тора – барлык картиналар да аның накладнойлары буенча үткәрелә, моның өчен прокат бәясеннән 10 процент алына. Моңа өстәмә рәвештә «Севзапкино» үзе эшләгән районнарда дүрт агитация программасын бушлай куярга тиеш була.

Казанның төп кинотеатры саналган «Электро»да Октябрьгә кадәрге чордан ук музыкаль оркестр саклана. Аның составында түбәндәге уен кораллары була: беренче скрипка, альт, флейта, флейта-пикколо, контрабас, виолончель, кларнет, труба, икенче скрипка, тромбон, литавра, фортепьяно. Башка кинотеатрларда, һичьюгы, музыкаль трио эшли.

«Таткино»ның тырышлыгы белән, эшли башлап ярты ел узуга, беренче «Татар милли кинотеатры» ачыла (соңыннан «Чаткы» дип үзгәртелә). 400 урынга исәпләнгән залда «Таткино» кинолабораториясендә әзерләнгән татарча титрлы кинофильмнар күрсәтелә. Алар республикада гына түгел, аннан читтә – татарлар яшәгән төбәкләрдә дә бара. Әгәр ниндидер сәбәп аркасында татар телендәге титрлар булмаса, кинотеатрда «махсус нидачы-тәрҗемәче» эшли.

Кинога эшчеләр күпләп йөри алсын өчен, «Таткино» билгеләгән керү бәяләре 15 тән алып 25 тиенгә кадәр була, шулай ук ул эштә кредит бирү системасын кертә. Кызылармиячеләргә искәрмә ясала: алар кинотеатрларга бушлай йөри (ай саен якынча ике мең кеше). Моннан тыш, җәй көне «Таткино» атнага ике тапкыр хәрби хезмәткәрләргә түләүсез кино күрсәтә.

«Таткино» эшчәнлегендә иң мөһим юнәлешләрнең берсе – авылларда эшләү. Шушы максатны күздә тотып, бөтен республика сигез районга бүленгән булган, аларның һәркайсына күчмә кино һәм киномеханик бирелгән. Маршрут алдан ук эшләнгән, план буенча аена кимендә 20 фильм күрсәтү таләп ителгән. Шул рәвешле, 500 меңнән артык халык яшәгән 173 зур һәм кечкенә авылларга хезмәт күрсәтелгән.

Татарстан Республикасы Милли архивында бу эшләр турында мәгълүмат-фикерләр сакланган, анда Биләр авылы крестьяннарының, бигрәк тә яшүсмерләрнең, киносеансны беренче тапкыр, Көектә киноны бөтен революция дәверендә тәүге мәртәбә күрүләре искәртелә.

Казанда икенче зур («Электро»дан соң) кинотеатрны булдыру ихтыяҗы туа. Картиналарны башта аларда күрсәтеп, аннары түбәнрәк прокат бәяләреннән кантоннарга җибәрү күздә тотыла. Шәхси милекче Г. Фёдоровныкы булган «Унион»ны шундый икенче зур кинотеатр итәргә карар кылалар. Кинотеатр тулаем яңадан җиһазландырыла, мәрмәр баскычлар ясала, полотнодан яңа экран куела.

Эшчәнлек өлкәсен киңәйтергә теләп, беренче чиратта шәһәрнең эшчеләр яши торган һәм үзәктән читтәге районнары исәбенә, «Таткино» – «Адмиралтейский» һәм «Художественный»

кинотеатрларын, ә капиталь ремонттан соң Арча кырында «Палас»ны ача. Элеккечә үк «Пассаж» балалар кинотеатрында, шулай ук клубларда, шул исәптән Дәүләт сәяси идарәсе (ГПУ) клубында бушлай кино күрсәтелә.

«Таткино» эшендә ерып чыгып булмастай кыенлыклар белән дә очрашырга туры килә. Алар, аерым алганда, дәүләтнең салым сәясәте белән бәйләнгән. Салым йөкләмәсе буенча кинотеатрлар ресторан, кафе-шантан кебек сәүдә-сәнәгать предприятиеләренә тиңләштерелгән. Вак оешмалар өчен бу коточкыч авыр йөк булып чыга: 1925 елның җәендә «Адмиралтейский», «Олимп», «Палас» һәм «Пассаж» ябыла.

Прокат Татреспублика территориясендәге кантоннарны гына түгел, ә күршедәге Вотский (Удмуртия) һәм Чуваш өлкәләрен, Башкортстан республикасын да колачлап ала. Монда татарча субтитрлар белән беренче фильм – «Нерон һәм Агриппина»ның да роле зур була. «Таткино»да үзгәртеп эшләнгән картина башта «Электро» кинотеатрында күрсәтелә, аннары кантоннарга бирелә һәм күрше өлкә һәм республикаларга җибәрелә. 10 меңнән артык татар яшәгән Ижаудан хәбәр итүләренчә, фильм гаять зур уңыш казана.

Шул ук вакытта «Таткино» лабораториясе татарча «Бөек көндәш» («Великая соперница») картинасының титрлары буенча эшен тәгәлли; тагын ике зур фильм – «Эксцельсиор» балет постановкасы һәм 22 күренештән торган «Ике битлек» («Две маски») картинасы әзерләнә.

«Таткино» идарәсе «Сарай һәм кирмән» («Дворец и крепость») революцион кинокартиналарын сатып алу турында «Севзапкино» белән сөйләшүләр алып бара, әмма бәяләрнең югары булуы аркасында икенчел прокатка ризалашырга туры килә. Шул вакытта «Таткино» идарәсе рәисе Х. Сәйфи һәм аның урынбасары В. Егоров Мәскәүгә баралар. Сәфәрнең файдасы зур була: барысы 753 сумга мотор, ике счётчик, реостат һәм «Преступная рука» кинокартинасы сатып алына.

«Таткино» прокат белән шөгыльләнүдән тыш, фото-кинематография лабораториясе оештыру һәм кино төшерүне (җитештерүне) дә күздә тотыла. Әмма озак вакытлар бина булмау сәбәпле, лаборатория оештыру мәсьәләсе хәл ителми. 1925 елның маенда «Таткино» яңа бинага күчкәннән соң гына, лаборатория өчен дә урын табыла.

«Таткино» үзенең җитештерү-төшерү эшчәнлегендә республика тормышының төрле якларын колачларга тели: революциянең бер еллыгын, 1 майны, ТАССРның бер еллыгын бәйрәм итүне, Советлар съездын, совхоз һәм предприятиеләр эшчәнлеген, җитештерү тармакларының мөһим предприятиеләре эшен, мәдәният һәм көнкүреш хроникасы кебек мөһим мәсьәләләрне.

СССР Дәүләт планына Дәүләт киносы аша төшерү эшләре өчен 35 мең метр негатив кинотасма сатып алуга заявка бирелә. 1924 елның июлендә үк сынау эшләре уздырыла. Алар арасында – «кызыл очучы иптәш Бычковны җирләүне һәм Казанда империалистик сугыш инсценировкасының аерым мизгелләрен төшерү», «Казанда ян-

гын сүндерү депосының күрсәтмә материалларын төшерү», «В.И. Ленинны соңгы юлга озатканда матәм демонстрациясен кинога төшерү (өстәвенә әлеге картинада язулар татар һәм рус телләрендә)» [НА РТ, ф. Р-144, оп. 1, д. 3].

Республикада кино төшерә башлау объектив кыенлыклар белән бәйләнгән. Хисапларда билгеләп үтелгәнчә, белгечләр булмау сәбәпле эш бик акрын барган. Тәҗрибәле кинооператорлар кирәк булган. Шулай да «Казанда Октябрь революциясенең берьеллыгы» хроникасы төшерелгән. Мәскәү базарында плёнка булмау сәбәпле, хрониканы төшерү вакытлыча туктатылган, бары тик фотоаппарат белән генә төшергәннәр [НА РТ, ф. Р-144, оп. 1, д. 3].

Шуңа да карамастан, Казан кинематографистларының уңышлары хәтта башкала матбугатында да билгеләп үтелә. Премьерасы «Электро» кинотеатрында булган «Иптәш Луначарскийның Казанга килүе» хроникасы турында Мәскәүдә чыккан «Жизнь искусства» журналыннан беләбез: спектакль башланыр алдыннан Луначарский катнашучыларны хәзерге заман театрының бурычлары белән таныштыра. Наркомның сәхнәгә чыгуы шау-шулы, озакка сузылган алкышларга сәбәп була.

«Таткино» татар кинематографиясе берләшмәсе урындагы кинотеатрларда үзе төшергән кинохрониканы зур уңыш белән күрсәтә: «Луначарский Казанда» (400 метр). Якын арада республика тормышыннан һәм көнкүрешеннән берничә картина төшерү күздә тотыла» [Жизнь искусства, с. 17].

1926 елда «Таткино» татарлар тормышыннан алынган нәфис-көнкүреш фильм сценариена зур ихтыяҗ кичереп, феодализм чорыннан алып бүгенге көнгә кадәр татарларның тормыш-көнкүреше һәм хәзерге вакыткача булган казанышлар турында ике сценарийга конкурс игълан итә. Әгерҗедән яшь партия хезмәткәре Габдрахман Шакиров җиңүче була. Аның заявкасы буенча танылган кинодраматург Натан Зархи «Булат батыр» фильмының сценариен яза (режиссёры Юрий Тарич).

Безнең көннәргә кадәр сакланган «Булат батыр» фильмы «Совкино» һәм «Таткино» киностудияләренең беренче уртак постановкасы булды. Режиссёр ассистенты һәм фильмның консультанты – Каюм Поздняков (соңыннан беренче профессиональ татар кинорежиссёры).

Фильмда тарихи вакыйгалардан соң төрле лагерьларда калган аталар һәм балалар темасы күтәрелә. Тасма ниндидер сәбәпләр аркасында кенәз Потёмкинга тәрбиягә эләккән татар малае Әсфәннең язмышы турында сөйли. Прапорщик чинындагы Әсфән җәза отряды белән туган җиренә кайта һәм, баш күтәргән крестьяннар белән атасы Булат җитәкчелек иткәнен белгәч, аларның юлбашчыларын азат итә. Финалда әтиле-улллы пугачёвчылар лагеренда калалар.

«Булат батыр» картинасы тарихи вакыйгаларны тирән һәм тулы чагылдыруга дәгъва кылмый. Ярлыларны яклаган кыю, ирек сөючән кеше турындагы хикәя маҗаралы-романтик жанрда төшерелгән.

Фильм илебездә дә, чит илләрдә дә бик зур популярлык казанган. Мәскәүдә чыккан «Кино» журналында шундый кызыклы факт китерелә: Германиядә, «Булат батыр» экраннарга чыкканнан соң, ниндидер бер ак эмигрант Антонов-Иванов, проекцион будкага кереп, фильмны юк итәргә теләгән [Навроцкий].

Фильмны төшерүнең барышы турында танылган татар композиторы Җәүдәт Фәйзи болай дип искә ала: «Съёмкалар Кремльдә, Казансу ярында барды. Мин дә шунда киттем. Кремльнең сул ягында, күпергә таба кеше агыла да ага. Кремль диварлары янында, Казансу ярында, Сөембикә манарасының түбәнге катларында чуар киемле кешеләр күренә, күбесе чалма, чапаннан. Капка янындагы калкулыкларда – туплар, солдатларның башында Екатерина заманыннан калган койрыклы драгун фуражкалары.

Менә каяндыр режиссёр һәм баш оператор утырган машина килеп чыга. Режиссёр рупорга берничә команда кычкыра да китеп бара, һәм шунда Кремль капкалары янында чын сугыш башлана! Мылтыклардан аталар, кылычлар ялтырый, сөңгеләр оча. Бөтен җирдә “ура!” дип кычкыралар...» [Алексеева, с. 154].

Пугачёв восстаниесе вакыйгаларын яңадан торгызган фильмның сценариен Натан Зархи һәм Юрий Тарич язган. Аде Войцик Булатның тәрбиягә алган кызы һәм баш күтәрүдә катнашучы Әсма ролен башкарган. Актриса Галина Кравченко Казан губернаторы бертуганының кызы тискәре Елена фон Брандт ролендә уйнаган.

Тарич картинаны чын вакыйгалар булган урыннарда төшерергә карар кылган. Съёмкалар вакытында аңа пугачёвчылар белән бергә атта чапкан татар партизанкаларының зур бер төркемен дә төшерергә кирәк була [Кравченко, с. 68].

Актриса Г. Кравченкога чабыш аты билгеләнә, ипподромда күнекмәләр ясарга мөмкинлек бирелә. Татар хатын-кызлары ат өстендә Мәскәү киноактрисаларыннан бер дә ким йөрмәүләрен белдерәләр.

Кино төркеме съёмкаларны уңышлы тәмамлый, һәм Казан «алына» [Кравченко, с. 68–72].

Казанның «Чаткы» кинотеатрында «Булат батыр» ел дәвамында күрсәтелгән. Фильм Идел буендагы баш күтәргән татар отрядлары (качкыннар) тормышыннан зур тарихи боевик буларак анонсланган.



«Булат Батыр» фильмының афишасы

Узган гасырның 70 нче еллары азагында Таткинопрокат директоры Ә. Беляев Дәүләт фильмнар фондында (Госфильмофонд) «Булат батыр» фильмын көч-хәл белән генә эзләп тапкан һәм кинокартинаның биш күчермәсен ясаган. Әлеге фильм Казан кинотеатрларында бара, аны бөтен республика, шул исәптән мамадышлылар да карый, нәкъ менә шушы

районның берничә кешесе тарихи тасманы яңадан халыкка кайтару инициаторлары булалар да инде. Бала вакытта алар фильмның массовкасында төшкән булганнар, һәм шул күренешләрне кабат карарга теләүләрен әйтеп, Таткинопрокат директорына хат язганнар. Ә. Беляевның фильмны тамашачыларга кайтаруында нәкъ менә шушы хат хәлиткеч роль уйнаган да.

1930 еллар – Татарстан Республикасында документаль кино интенсив формалашкан чор: кино материалын оештыруда үзенчәлекле формалар, документалистикада төрле жанрлар барлыкка килә. Шул вакытта татар кинематографистлары өчен махсус курслар да оештырыла. Әмма шуның белән бергә бу елларда тоталитар режим, урыннарда үзәк хакимиятнең басымчаклык итүе көчәя һәм тормышның барлык (дәүләт, хәрби, икътисади, мәдәни) якларын үзәкләштерү юлы белән, унитар-бюрократик совет дәүләте торгызыла. Бу процесс кинематографны үстерү концепциясендә дә чагылыш таба.

1927 елда Татарстан тамаша предприятиеләре идарәсе (ТУЗП) оештырыла, анда барлык берләштерелгән кино предприятиеләре белән бергә «Таткино» да кертелә. ТУЗП кинопрокат эшчәнлеген уңышлы дәвам итә. Татарстан тамаша предприятиеләре идарәсе рәисе итеп Шамил Усманов (1898–1937) билгеләнә. Ул Татарстанны радиофикацияләү турында хыяллана һәм аны гамәлгә ашыруга ирешә, Казанда радиостанция төзелешенә җитәкчелек итә. Төзелеш эшләре 1927 елның ноябренә тәмамлана. Шамил Усманов «Еженедельник ТУЗП» журналының баш мөхәррире дә була. Атнага бер чыга торган әлеге басмада Казанда барган театр һәм кино программалары гына түгел, кинокартина либреттолары да, тәнкыйть мәкаләләре дә басыла.

1928 елда ТУЗП бетерелә, ә җитештерү эшчәнлеге «Востоккино» Акционерлык Җәмгыятенә тапшырыла, Татарстан Республикасы аның пайчысы була. АҖ 10 төбәкне (шул исәптән Казакъстан, Кырым, Башкортстанны, Уссурия краен) берләштерә. Татарстан Республикасының өлеше төп капиталның 40 мең сумын тәшкил итә. Шул вакыттан алып 1932 елга кадәр ТАССРда кино җитештерү һәм кинофикацияләү «Востоккино»ның татар бүлекчәсе җитәкчелегендә тормышка ашырыла.

«Красная Татария» газетасы болай дип яза: «производственный план «Востоккино» проработан под знаком наибольшего приближения тематики к важнейшим вопросам советского строительства. По этому плану на нынешний год на долю Татарской республики падает производство двух картин. Одна из них – «Комета» уже закончена и скоро поступит в прокат. Сценарий картины написан В. Туркиным. Режиссер – В. Инкижинов. Вторая картина – «10 лет Татарстана» – режиссёры М. Вернер и А.Дубровский – также будет скоро закончена» [Красная Татария, 1929, 26 сент.].

Татарстан Халык мәгариф комиссариаты кушуы буенча Х. Кәримов яңа татар кинокартинасы өчен сценарий язган. Сценарийның нигезенә Х. Кәримовның «Җан исәбен алу вакытында» («Во время

переписи душ») әсәре яткан. Вакыйгалар 1897 елга карый. Яңа картина шул заман татарларының көнкүрешен, гореф-гадәтләрен чагылдырырга һәм татар крестьян баш күтәрүләренең көчәю тарихын күрсәтергә тиеш була.

«Востоккино» кинофильмнар җитештерү белән генә түгел, үз милли кадрлар әзерләү белән дә шөгыльләнә. «Востоккино»ның Татар бүлеге идарәчесе урынбасары В. Егоровның Мәскәү кино институты кадрлар секторына җибәргән запросы сакланган. Анда «Востоккино»ның татар бүлеге Гобәйдуллина Сәгъдайның Дәүләт киносы-техникумның Актёрлар бүлеген 1930 елда тәмамлавы турында дипломын ашыгыч рәвештә инде икенче мәртәбә җибәрүен үтенә.

«Востоккино»ның беренче адымнары, ул башлаган эшләр җирле матбугатта яктыртып барыла: «Татарское отделение “Востоккино” было организовано 1 апреля 1930 года. В него вошли 6 кинотеатров, 3 фото-ателье и 1 кинопередвижка. Отделение располагает 18 кинотеатрами в Татарии, 4 кинотеатрами в Автономной Вотской области, 48 передвижками, 6 фото-ателье, киноремонтной мастерской, столярной, художественно-плакатной мастерской. В Казани создана производственная база, регулярно выпускающая кинохронику, отражающую социалистическое строительство Татарской республики. В состав отделения вошли также агентства автономных областей Удмуртской и Марийской.

Кроме улучшений, произведённых в чисто техническо-эксплуатационном отношении, выразившихся в ремонтах зданий, инвентаря и имущества принятых кинотеатров и предприятий, перевода театров на беспрерывную работу, увеличение сеансов и перевода четырёх театров на двойную смену, – главное внимание отделения обратило на политпросветработу в театрах, организацию в каждом кинотеатре красных уголков, читален, комнат для игр, выставок, лекций и докладов. Перед отделением стояла большая работа по организации массового рабочего зрителя. Проведён целый ряд курсов для киномехаников. Организованы курсы сценаристов-татар» [Год работы…].

«Востоккино»ның Татар бүлеге каршында махсус сценарий цехы төзелә. Яшь сценаристлар Татреспублика тормышын чагылдырган сценарийлар язалар. Планда түбәндәге темаларны яктырту карала: «Дин белән көрәш – социализм өчен көрәш»; «Сәетгәрәй» (бөекдержавачыл шовинизм һәм җирле милләтчелек); «Яшь барабанчы» (хуҗалык-сәяси кампанияләрендә пионериянең роле) [Вельтман, 1931].

Сценарийлар остаханәсенең эше турында тыңлаучы А. Абызов болай дип яза: «Работающие в мастерских – 14 человек – организовали две бригады по составлению сценариев для засъёмки, в первую очередь, хроник, отражающих борьбу татарской промышленности за промфинплан. Работники мастерских прикреплены к предприятиям для изучения материала, который группируется и окончательно разрабатывается на своих производственных совещаниях. Готовые сценарии обсуждались на широких конференциях рабочих зрителей, при-

влекая одновременно к сбору материала представителей предприятий и комсомол…

От деятельности мастерских неотделима работа художественно-политических советов кинотеатров, руководство ими по организации зрителя, изучение его запросов, втягивание рабочего зрителя в контроль над кино (через стенгазеты, просмотры, дискуссии и пр.) и подготовка дополнительных кинокадров» [Абызов, 1931].

Башка бер газета мәкаләсендә документаль фильмнарның тематикасы турында сүз бара: «Сценарный цех “Востоккино” (реорганизованный из сценарных мастерских) заключил договоры с «Востоккино» на изготовление трёх сценариев на темы: “Борьба с религией – борьба за социализм”, о правом уклоне в нацполитике и об участии пионеров в хозяйственно-политических кампаниях. Либретто всех трех сценариев уже готовы и посланы в Москву» [Красная Татария, 1931, 18 сент.].

1931 елның июлендә Казанда киноленталарга подписьләр эшләү лабораториясе ачылу турында хәбәр ителә. Бу яңа фильмнарны җирле экраннарга чыгаруны шактый тизләтергә, Яңалифтәге язмаларны кулланырга мөмкинлек бирә [Красная Татария, 1931, 20 июля].

Татарстан АССР Хөкүмәте республикада кинематограф үсешен даими күзәтеп тора. «Востоккино»ның Татар бүлеге карамагына, кинофабриканы җиһазландыру өчен, элеккеге Казан Богородица хатын-кызлар монастыре биналары тапшырыла, анда киләчәктә тавышлы кинофильмнар чыгару планлаштырыла.

1929 елда «Востоккино» белгечләре Казанда ике фильм төшерә: «Комета» нәфис фильмын һәм «Татарстан. Дүрт елга иле» («Татарстан. Страна четырёх рек») документаль фильмын.

«Комета» фильмын (аның сценарием кинодраматург В. Туркин Рахманкуловның «Упкын» («Пучина») пьесасы мотивлары буенча язган) режиссёр В. Инкижинов төшергән. Фильм революциягә кадәрге елларда руханилар һәм сәүдәгәрләрнең хәерче татарларны эксплуатацияләве турында сөйли. Картина сюжетына кучер белән сәүдәгәр хезмәтчесенең лирик мәхәббәт тарихы үреп бирелә. Картина безнең көннәргә кадәр сакланмаган.

Фильм турында шул чор матбугатында басылган язмадан да белергә мөмкин: «Снимающаяся в татарской части города картина ставит себе основную задачу – создание подлинно национального фильма, лишённого лживой экзотики. Режиссёр «Востоккино» В. Инкижинов поставил себе целью создать подлинно восточную картину. Он осторожен в методике съёмки. Свою работу он называет экспериментом.



«Комета» фильмының афишасы

Взят национальный материал под углом социальной сатиры. Соединённый с условностями кинометода. Одновременно углублённая работа над актёрской техникой и, что главное, – поиски специфического стиля игры для национальных картин.

В создании картины "Комета" – участвуют: Пётр Репнин – роль купца, Н. Беляев – мулла, Иван Бодров – приказчик купца и любовник его жены, Поздняков – дворник, Закий Баязетский и Бенедикт Бугаев – хальфы, Фурасов и Брусков – баи. В женских ролях – известная киноактриса – Галина Кравченко и Валентина Вод. Снимает картину оператор Франциссон.

Уже сняты базары и улицы Казани, татарская чайная, сцены в мечети и медресе и т.д. Будущее покажет нам общую ценность этой интересной работы над поисками стиля восточных картин» [Март, 1929].

Фильмда төп рольләрнең берсен уйнаган актриса Галина Кравченко исә болай дип искә ала: «Как режиссёр – В. Инкижинов был профессионален и ловок. Было очень интересно сыграть женщину другой национальности. За две недели до начала съёмок я отправилась в Казань, чтобы пожить среди татар. Меня поместили в татарскую семью, и хотя Казань была моей родиной, все же в этой семье я впервые познакомилась со многими татарскими обычаями.

Съемки проходили в основном на натуре. Актёрский состав был сильный, В. Инкижинов пригласил на главные роли лучших актёров, таких, как М. Яншин, П. Репнин, И. Бобров, В. Вод. Помнится и то, что группа в средствах не была стеснена.

"Комета" оставила равнодушными и зрителей, и критиков, потому что содержание фильма безнадёжно устарело, и никакие хорошие актёры не могли дело поправить. История мошенника-муллы, объявившего скорый конец света, а для предотвращения бедствия, потребовавшего от прихожан пожертвований в пользу мечети, могла быть по жанру только комедией-гротеском. Показывать же все это как драму, считая, что ведёшь антирелигиозную пропаганду, можно было, только забыв, что мы живём уже в 1930 году, и людей волнует куда более серьёзные проблемы.

Мне лично очень грустно, что так получилось с "Кометой", так как я в этом фильме работала с большой отдачей. К тому же это была моя первая национальная роль» [Кравченко, с. 88–89].

Актрисаның тыйнак кына бәяләмәсе В. Инкижиновның 1929 елның октябрендә Парижга китеп, аннан кире әйләнеп кайтмавы белән бәйле була. Франциядә ул кырык елдан артык яши, иллегә якын фильмда төшә, дөньякүләм кино энциклопедияләренә керә. Әмма Инкижинов 1928 елда В.И. Пудовкинның «Чыңгыз хан варисы» («Потомок Чингис-хана») фильмында катнашып, бөтен дөньяда дан казана, анда ул төп рольне (Баирны) уйный.

Кино төшерү өчен Казанга башка төбәклләрдән кинематографистлар килә. Мисалга, 1929 елда «Чувашкино» республика башкаласында «Апайка» картинасын төшерә.

Картинадагы вакыйгалар 1918 елга, Казан чехословаклар корпусы тарафыннан басып алынган чорга карый. Анда большевикларның аклар тылында яшерен эш итүе һәм крестьяннарның оештыручылар авантюрасына мөнәсәбәте күрсәтелә. Сюжет үзәгендә 40 нчы завод һәм Алафузов заводы эшчеләренең 3 сентябрьдә булган баш күтәрүе тора. Сценарий һәм режиссура Максимов-Кошкинскийныкы, ассистент Георгий Парнэ, оператор Э. Никулеско. Төп рольләрдә: Тани Юн (кер юучы Таиса роле), Тимонтаев (татар коммунисты Вәлиев) һәм Малаев (акгвардияче Глинский). Экспедиция Казанда октябрьгә кадәр эшли [Красная Татария, 1929, 17 сент.].

Ун елдан соң, 1939 елның 28 августында Казанда Максим Горький турында трилогиянең соңгы өлешен тәшкил иткән «Минем университетларым» («Мои университеты») фильмын төшерә башлыйлар.

Мәскәүдәге «Союздетфильм» студиясенең куючылар төркемен «орденлы режиссёр» Марк Донской җитәкли. Картинаның титрларында түбәндәге исемнәрне күреп була: операторлар П. Ермолов һәм И. Малов, рәссам И. Степанов, композитор Л. Шварц. Казанда съёмкалар бер айга якын дәвам итә.

Яшь Горькийның Идел пристаньнаре буйлап йөрүен күрсәткән эпизодларның бер өлеше Идел ярында, Дубки янында төшерелгән. Меңнән артык кеше катнашкан массакүләм студентлар җыены күренешен Казан Кремле янындагы мәйданда төшерәләр. Казанның XIX гасыр ахыры итеп «декорацияләнгән» кайбер урамнары да кадрга эләгә: күпер буйлап корылган фонарьлар, кибет һәм склад ишекләре өстендәге элмә такталар («Трактир С.И. Вавилова», «Булочная А.Н. Артюхина», «Книжная лавка В. Карпова», «Магазин парижской обуви М.И. Каблукова»).

«Красная Татария» газетасында фильмны төшерү мизгелләренең берсе болайрак тасвирлана: «После десятка репетиций шумная улица замерла, приготовилась к съёмке. По сигналу режиссёра поехали подводы, пёстрый поток людей заполнил улицу, раздались крики разносчиков, с чайником в руке пробежал в трактир Алексей Пешков. Когда начали звуковую съёмку, в небе неожиданно показался самолёт и треском своего мотора сорвал звукозапись «шума толпы» на улице старой Казани» [Красная Татария, 1939, 11 сент.].

Урындагы прессага интервью биргәндә, Марк Донской болай дип билгеләп үтә: «В трилогии о Горьком мы продолжаем показ молодого человека, душу которого старались исказить люди. Как известно, «университетами» для Алексея Пешкова оказалась сама жизнь. Алексею Пешкову одно время тоже казалось, что выхода нет. Как мы знаем, он поднял оружие к своему сердцу – стрелялся, оставив удивительную записку: «В смерти моей прошу обвинить поэта Гейне, выдумавшего зубную боль в сердце. Останки мои прошу взрезать и осмотреть – какой чёрт сидел во мне за последнее время». Простые русские люди, с которыми он работал у булочника Семенова по 18 часов в сутки за три рубля в месяц, эти люди показали Алексею

Пешкову, что надо бороться за жизнь, за достоинство человека, за его освобождение…» [Красная Татария, 1939, 28 авг.].

Марк Донскойның «Минем университетларым» фильмы Россия кино сәнгатенең алтын фондына керә, халыкара кинофестивальләрдә, шул исәптән Венеция һәм Эдинбургта призлар ала.

1930 елда «Татарстан» фильмы режиссёры А. Дубровский, татар шагыйре Һ. Такташ белән бергәләп, «Камил» дигән баш астында, хәзерге татар авылы тормышыннан сценарий яза. Картина көз һәм кыш айларында татар шахтёрлар яшәгән Донбасста, Казанда һәм Арча кантоны авылларында төшерелә [Новые картины…].

«Камил» нәфис фильмы турында язучы һәм тәнкыйтьче Гомәр Галинең «История одного сценария» дигән кызыклы газета мәкаләсе сакланган. Шагыйрь-драматург Һади Такташның Татар академия театрында куелган яңа пьесасын ул татар совет драматургиясендәге иң яхшы әсәрләрнең берсе дип билгели. «Не ограничиваясь представлением в театре, Такташ написал еще сценарий по этой пьесе для кино и передал этот сценарий в «Востоккино». Мы с уверенностью ждали: вот «Востоккино» начнет съёмочную работу, и в этом же году татарские рабочие и колхозники, и вся трудящаяся масса Татарской республики увидят развёрнутую картину своей жизни и борьбы за ее переделку! А на деле: мастера из «Востоккино» взялись за переделку и проработку этого сценария и до того «переделали» и «художественно обработали», что в итоге получилась никуда не годная вещь… Переделка сценария «Камиль» явилась образцовой иллюстрацией того, как иногда опошляют идею создания кинофильма о жизни народов СССР» [Гали Гумер, 1924].

Рецензия авторы фикеренчә, «Востоккино» төшерү төркеменең төп хатасы шунда ки, алар бу эшкә иҗтимагый оешмаларны (беренче чиратта, язучыларны яки театр җәмәгатьчелеген) җәлеп итмәгәннәр генә түгел, бу «үзгәрешләр»дән хәтта Такташ үзе дә хәбәрдар булмаган. Нәтиҗәдә, күпме энергия, вакыт, акча бушка сарыф ителгән.

Такташ сценарие буенча, вакыйгаларның күп өлеше Донбасста бара, анда шахталарның берсендә рус һәм украиннар белән бергә татар эшчеләре дә промфинпланны үтәү өчен көрәшәләр, удар бригадалар оештыралар һ.б. Ә «үзгәреш кертүчеләр» Донбасс урынына Мәскәү электр заводын сайлыйлар һәм анда ике татар эшчесен китереп тыгалар [Новые картины…].

Гомәр Гали «Востоккино» кинематографистларының тагын берничә ялгышын билгели, алар, аның фикеренчә, рус һәм татар эшчеләре арасындагы интернациональ бердәмлекне механик рәвештә гәүдәләндерә, татар авылында колхоз өчен барган көрәшне күрсәтми, муллаларның колхозга каршы көрәшен тасвирлаган күренешләр дә гадиләштерелгән [Новые картины…].

Татарстан тормышыннан нәфис кинофильмнар төшерү буенча да эш туктамый. «Востоккино» Каюм Поздняков сценарие шартлы

рәвештә «Затон янында» («У Затона») дип атала һәм фанер заводы эшен яктырткан нәфис фильм төшерүне күздә тота [Красная Татария, 1930, 17 апр.].

Яңа кинокартина төшерү өчен Мәскәүнең «Востоккино» фабрикасы оештырган экспедиция Казанга 1931 елның августында килә. Яшел Үзән предприятиеләре үрнәгендә сәнәгатьтә милли кадрлар әзерләү һәм тәрбияләү турында нәфис фильм төшерү күздә тотыла. Фильмның сценарие 3 нче фанер заводында аның эшчеләр активы һәм республика сценарий остаханәсе катнашында карала.

Фильмның постановкасын кинорежиссёр Каюм Поздняковка ышанып тапшыралар. Татарстанны социалистик индустрияләштерү проблемаларына багышланачак фильм «Яшел Үзән баласы» («Малыш из Зелёного Дола») дип исемләнә [Янгиров, 1987].

Режиссёр социализм төзелешендәге уңышларны тере һәм якты итеп, образлы формада күрсәтү генә түгел, ә милли чикләнгәнлек һәм дошманлыкның теләсә нинди формаларына каршы булган илебез халыклары арасындагы интернациональ дуслыкның әһәмиятен ассызыкларга да тиеш була.

Яшел Үзәндә табигать кочагында башланган съёмкалар һава шартлары начараю нәтиҗәсендә туктатыла. Оештыру өлкәсендә дә көтелмәгән кыенлыклар килеп чыга, ахыр килеп, фильм экраннарга чыкмый кала [Янгиров, 1987].

Кинематография эшендә үз кадрларыңны булдыру һәм республика турында фильмнар төшерү өстенлекле юнәлешне тәшкил итә. «Востоккино» акционерлык җәмгыяте профессиональ булмаган сценаристлар өчен иң яхшы «картина өчен либретто» конкурсын игълан итә. Татар язучыларын һәм туган якны өйрәнүчеләрне сценарий язу эшенә тарту максатыннан, Татарстан тормышыннан алынган картина өчен иң яхшы либреттога конкурс башлана. Либретто республика көнкүрешен, аның хуҗалык төзелешен, культура революциясен һ.б. чагылдырган заманча совет темасына язылырга тиеш була.

Бу конкурста профессиональ сценаристлар катнаша алмый. Либретто буенча өч премия игълан ителә: беренчесе – мең сум, икенчесе – алты йөз сум һәм өченчесе – өч йөз сум» [Красная Татария, 1929, 25 апр.].

Шулай итеп, кыска гына вакыт аралыгында киноиндустрия булдыру буенча беренче адымнар ясала, уенга корылган һәм документаль кинофильмнар төшерелә. «Таткино» һәм «Востоккино» эшчәнлеге «Союзкинохроника»ның Татар бүлеген булдырырга ярдәм итә.

«Востоккино»ның Татар бүлеге җитештерү остаханәсе базасында 1932 елның 1 апрелендә Казанда «Союзкинохроника»ның Татар бүлеге оештырыла. Әлеге датаны Казан кинохроника студиясенең туган көне дип тә санарга мөмкин.

**Әдәбият**

*Абызов.* Сценарные мастерские приступили к практической работе // Красная Татария. 1931. 12 июля.

*Алексеева Е.П.* Казань. Кинематограф. Из века в век (1897–2014-е гг.). Казань: Центр инновационных технологий, 2016. 428 с.

*Вельтман С.* О кино Татарии // Красная Татария. 1931. 30 июля.

Год работы Татарского отделения «Востоккино» в Татарии» // Красная Татария. 1931. 6 апреля.

*Гали Гумер.* История одного сценария // Красная Татария. 1931. 17 июля.

Жизнь искусства. Л. ; М., 1924. № 48. С. 17.

*Кравченко Г.* Мозаика прошлого (рассказывает киноактриса). М.: Искусство, 1971.

Красная Татария. 1929. 25 апреля.

Красная Татария. 1929. 17 сентября

Красная Татария. 1929. 26 сентября.

Красная Татария. 1930. 17 апреля.

Красная Татария. 1931. 2 июля.

Красная Татария. 1931. 18 сентября.

Красная Татария. 1939. 28 августа.

Красная Татария. 1939. 11 сентября.

*Март Вл.* Новая татарская кинокартина «Комета» // Красная Татария. 1929. 11 июля.

*Навроцкий С.* // Кино. 1935. 10 марта.

НА РТ, ф. Р-144, оп. 1, д. 1, л. 8, 12.

НА РТ, ф. Р-144, оп. 1, д. 3.

Новые картины о Татарии // Красная Татария. 1930. 17 апреля.

*Султанбеков Б.* Альфред Лепа. Судьба, продиктованная эпохой // Республика Татарстан. 2000. 10 августа.

*Янгиров Р.* Первый призыв // Советская Татария. 1987. 27 августа.

***Алексеева Елена Петровна,***
*кино белгече, тарих фәннәре кандидаты, Казан дәүләт мәдәният институтының кино һәм ТВ режиссурасы кафедрасы доценты*

УДК 782

***Г.Ф. Юнысова***

# «КАВИ – СӘРВӘР» ОПЕРАСЫ:
## әдәби-музыкаль нигез һәм куелыш үзенчәлекләре

В статье рассматриваются особенности современной татарской оперы «Кави – Сарвар» молодого композитора М. Хайруллиной. Внимание обращено на либретто произведения: его сюжет, документальную и литературную основу. Отмечено лингвистическое своеобразие текста в связи с включением персонажей разных национальностей. Анализ музыки и драматургии произведения выявил как оригинальность авторского решения, так и апелляцию к операм других композиторов в виде реминисценции. Рассмотрены трактовки действующих лиц, их воплощение в премьерном концертном показе и дана характеристика некоторым исполнителям. Предложены пути решения проблемы постановки новых сценических произведений композиторов Татарстана на театральной сцене.

**Ключевые слова:** опера «Кави – Сарвар», композитор Миляуша Хайруллина, опера «Джалиль» Жиганова, вальс Сайдашева, колыбельная песня, опера «Катерина Измайлова» Шостаковича, декламационность.

The author examines the features of the modern Tatar opera «Kavi-Sarvar» by the young composer M. Khairullina. Attention is drawn to the libretto of the work: its plot, documentary and literary basis. The linguistic originality of the text is noted due to the inclusion of characters of different nationalities. An analysis of the music and dramaturgy of the work revealed both the originality of the author's decision and the appeal to the operas of other composers in the form of reminiscence. The interpretations of the characters, their embodiment in the premiere concert show are considered and characteristics of some performers are given. Ways to solve the problem of staging new stage works by Tatarstan composers on the theater stage are proposed.

**Keywords:** opera «Kavi – Sarvar», composer Milyausha Khairullina, opera «Jalil» by Zhiganov, Saidashev's waltz, lullaby, opera «Katerina Izmailova» by Shostakovich, declamation.

Күптән түгел яшь композитор Миләүшә Хәйруллинаның «Кави – Сәрвәр» операсы республика тамашачысы хозурына тапшырылды. Ул Н. Җиһанов исемендәге VIII «Мирас» татар музыкасы фестивале кысаларында күрсәтелде. Агымдагы елның апрелендә Казанда шул ук С. Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында опера кабат яңгыраячак. «Кави – Сәрвәр»нең премьерасы җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты, матбугатта күпсанлы мәкаләләр басылып чыкты. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: соңгы ун елда Татарстан композиторлары (бигрәк тә яшьләр һәм урта яшьтәгеләр) төрле жанрдагы музыкаль сәхнә әсәрләре иҗат итү юнәлешендә актив эшлиләр. Әлеге әсәрләр күләм ягыннан зур түгел һәм аларның катнашучылары да аз. Бу күренешнең ким дигәндә (дөнья һәм төбәк масштабындагы) ике сәбәбен күрсәтергә мөмкин. Биредә дөньякүләм опера жанры үсеше тарихындагы монoопера (ягъни бер солист өчен опера) туу тенденциясен искә төшерү

зарур. Республика дәрәҗәсеннән караганда, сәбәп музыкаль сәхнә әсәренең (Р. Әхиярованың балет һәм операларыннан кала) театрда куелу-куелмау мәсьәләсе белән дә бәйле. Композиторларның бу буынына, ихтыяри-мәҗбүри, опера театрында куелышка түгел, ә концерт версиясенә юнәлеш тотып эшләргә туры килә, бу иҗат ителә торган әсәргә күп яклап чикләүләр сала. Шул сәбәпле «Кави – Сәрвәр» операсы кебек масштаблы әсәрнең концерт версиясе турындагы хәбәр шунда ук күпләрнең игътибарын җәлеп итте. Автор башкарган эшнең күләмен бары музыка сәнгате вәкилләре генә тулаем бәяли ала. Шуңа бәйле рәвештә игътибарны бер генә фактка юнәлтәсем килә. Бүген композиторлар музыкаль сәхнә әсәре иҗат итү процессында инструментовка белән шөгыльләнеп тормыйлар, аны (үзләре яки тамаша учреждениеләре вәкилләре) башка музыкантларга йөклиләр. Ә музыкаль әсәрне оркестр белән башкаруга яраштыру исә – катлаулы һәм күп көч сорый торган этапларның берсе. Мондый күренешне татар музыкасында элек тә очратырга мөмкин иде, әмма аның сәбәпләре бөтенләй башка. Мәсәлән, Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты һәм Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясен оркестрлаштыру белән Ф. Витачек шөгыльләнгән. Өч сәгать ярым дәвам иткән «Кави – Сәрвәр» операсына нисбәтле М. Хәйруллина да нәкъ шулай эшләр дип гөманлау урынлы булыр кебек. Әмма 700 биттән артып киткән партитура – авторның – композитор һәм пианист, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлап, композиция буенча укуын П.И. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясендә дәвам иткән затның үз хезмәте нәтиҗәсе. М. Хәйруллина – күпсанлы конкурслар лауреаты (шул исәптән 2022 елда Мәскәү консерваториясенең зур залында узган «Партитура» Бөтенроссия яшь композиторлар конкурсында «Опера музыкасы яисә оперетта музыкасы» номинациясендә җиңү яулаган).

Язучы Кави Нәҗми белән аның хатыны – балалар язучысы һәм тәрҗемәче Сәрвәр Әдһәмова тормышында XX гасырның 30 нчы еллары ахырында булган драматик вакыйгалар Миләүшә Хәйруллина һәм либретто авторы Айдар Әхмәдиевне музыкаль сәхнә әсәре иҗат итүгә рухландырган. Сталин репрессияләре темасын алар Кави һәм Сәрвәр гаиләсе мисалында яктыртырга алынганнар. Бәлки бу парның язмышы, канлы еллар корбаны булган кайбер башка татар язучыларыныкы белән чагыштырганда, ул кадәр үк фаҗигалы да түгелдер. Әмма әлеге нәсел варислары тарафыннан әзерләнгән һәм нәшер ителгән «Сильнее смерти и страха жизни» китабы авторларга бик нык тәэсир иткән һәм яңа опера туудa хәлиткеч роль уйнаган.

Әлеге басма документлардан, хатлардан һәм шигырьләрдән тора. Анда эпистоляр мирас – репрессия аппараты карары белән берберсеннән һәм улларыннан аерылырга мәҗбүр булган ир белән хатынның (берсе – 2,5 ел төрмәдә, икенчесе Новосибирск өлкәсендәге лагерьда, кыскартылган исеме Сиблаг, өч ел сөргендә булган) язышуы үзәккә куелган. Нәкъ менә шул иң зур хисси йогынты көченә ия булган да.

Операда уңай һәм бәхәсле моментлар да бар, алар турында алга таба әйтелер әле. Әмма шунысы бәхәссез: залның реакциясенә, фойедагы мәгълүмат планшетларын өйрәнүгә нигезләнеп, яшьләрнең өлкән буын вәкилләреннән сорашуына таянып, авторлар бу әсәр белән тамашачыны җәлеп итә алганнар, сәяси репрессия корбаннарына, бер-берсен өзелеп яраткан ир белән хатынның хисләренә һәм тугрылыкка музыкаль һәйкәл торгызганнар, үткәндәге вакыйгаларга гына түгел, гомумән, татар әдәбиятына, аның аерым вәкилләренә карата зур кызыксыну уята алганнар.

«Кави – Сәрвәр» операсы пролог һәм эпилогы булган 13 күренештән гыйбарәт. Алар ике өлешкә бүленгән. Ике блок та үзенең музыкаль колориты белән аерылып тора. Беренчесе интонация ясауда декламацион стильне сайлау (бу – текстны тизләтелгән темпта җиткерергә ярдәм итә), бүлекләрнең көчле динамикада тәмамлануы (композиторның тынлы һәм бәрмә уен кораллары төркеменә өстенлек бирүе сизелә), геройларның вакыйгаларга көчле реакциясе, персонажларның үзара тиргәшүләре аркасында аеруча экспрессив булып күренә. Шул ук вакытта декламационлык өстенлек итсә дә, монотонлык хисе тумый. Операның беренче өлешендә музыкаль спектрның төрлелегенә билгеле бер чаралар ярдәмендә ирешелә: бишек җыры, шаян җыр һәм вальс жанрларын куллану, бер персонажның тембрга корылган уены. Моннан тыш, М. Хәйруллина шул заман көйләре символы (ориентирлар) буларак чит музыкаль материаллар – татар халык җыры көен, шулай ук «Наемщик» драмасыннан С. Сәйдәшев вальсын кертеп җибәрә. Шунысы үзенчәлекле: бу спектакль беренче тапкыр 1928 елда күрсәтелсә дә, әлеге вальсның 1948 елгы икенче редакциядә барлыкка килүе турында мәгълүматлар бар, ә «Кави – Сәрвәр» операсына нигез булган вакыйгалар XX гасырның 30 нчы еллары ахырында бара. Операда сөйләм (вокализацияләнмәгән) тексты да урын алган. Соңгысы закон вәкилләре партиясенә хас. Аларның җылылык белән өретелгән җырчы тавышыннан мәхрүм ителүе бу персонажларның әллә ни үзенчәлеккә ия булмавын һәм рәхимсезлеген ассызыклый.

М. Хәйруллина операда үз музыкаль теленнән файдалана. Әмма кайбер ситуацияләрнең, аларның драматургия ягыннан һәм музыкаль чишелешенең, аерым персонажларның (бигрәк тә әсәрнең беренче өлешендә) прообразы, чыганагы бар. Советлар Союзы герое, шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган «Җәлил» операсы шундыйлардан булды (өстәвенә, нәкъ менә режиссёр М. Панджавидзеның соңгы сәхнә версиясендә). Бу постановка турындагы рецензиядән алынган бер генә өземтәне китерәбез: «подача событий в другом ракурсе, политических и других реалий советской жизни того времени, порой противоречащих достоверным фактам. Так, например, жена поэта также оказывается в застенках, но уже НКВД, как супруга, обвиненного в предательстве поэта. На самом же деле она осталась на свободе [Юнусова, с. 250].

Н. Җиһановның «Җәлил»ендәгегә охшаш хәл-хәләтләргә «Кави – Сәрвәр» операсындагы Тансыкны (Кави белән Сәрвәрнең улы)

йоклату, Яңа ел каршылау, Сәрвәрнең шагыйрь Самат Бикташев белән сөйләшү күренешләрен кертергә кирәк. М. Җәлилнең нәни кызы йоклап китү күренешендә оркестр тукымасына татар халкының бишек җырын керткән Н. Җиһановтан аермалы буларак, М. Хәйруллина үзенчәлекле көй язган. Әмма тугыз яшьлек малайга бишек җырлары җырлыйлармы икән, дигән сорау туа (буклетта Тансыкның тугыз яшьтә булуы искәртелгән). Самат Бикташев персонажы үзе дә, аңа мөнәсәбәт тә каршылыклы. Сюжет буенча ул – шагыйрь, республикабызның Язучылар берлеге әгъзасы, аның иҗатын матбугатта тәнкыйть утына тотканнар, аннары хатыны кулга алынган. Үзе өстендә болытлар куерганын сизеп, ул Татарстан Язучылар берлеге рәисе Кави Нәҗминең фатирына язма рәвештә ярдәм сорап килә. Үзе өйдә булмагач, аның хатыны Сәрвәргә мөрәҗәгать итә, үтенечен иренә җиткерүен сорый. Үтенүдән янауга күчә. Әмма Сәрвәрнең, аның түтәсенең, соңрак Кави Нәҗминең дә ачуы чыгуга бу гына сәбәп булмый. Алар шагыйрьне куалар, чөнки үзләре өчен куркалар. Мондый вазгыять соңрак Кави Нәҗми белән бәйле рәвештә дә кабатланачак. Сәрвәр ирен әдәбиятчыларның иҗат оешмасы рәисе вазифасында алыштырган Мирсәй Әмирдән Кавины яклавын сорый, һәм тегесе нәкъ шул сәбәп аркасында бу гаиләгә булышудан баш тарта. Самат Бикташев образын аңлатуда (җырчы – Денис Хан-Баба) Н. Җиһановның «Җәлил» операсыннан ике персонаж бергә кушыла кебек: болар – сатлык лейтенант Канзафаров («Кави – Сәрвәр»нең башында Бикташев та шундый) һәм герой-шагыйрь үзе (әсәрнең икенче яртысында). Самат Бикташевка тискәре характеристика характерлы тенор тембры яңгырашы аша бирелгән. Аның тавышындагы юмакай ноталар Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсындагы ялагай киңәшче Урмай партиясен искә төшерде. Үз героеның ярарга тырышучанлыгын, «бөгелү-сыгылуын» артист, закон вәкиле алдында берничә тапкыр сикереп торып, тән хәрәкәтләре белән дә ассызыклады. Аның каравы операның икенче өлешендә ул – бөтенләй башка персонаж, үзенең табигый матур тенор тавышы белән кыланмыйча гына җырлый. Хәтта үлем җәзасына барганда да үзен горур һәм лаеклы тота. Бу күренеш Н. Җиһанов операсындагы Җәлилнең китүен хәтерләтә.

Операның икенче өлешендә персонажларның интонация ясау һәм аралашу өлкәләрендә сизелерлек үзгәрешләр күзәтелә: декламация күләме кими (ул үзенең әйдәп баручы позицияләрен кантиленага бирә) һәм моңарчы аерым кисәкләр рәвешендә генә очраган рус теле, аралашу теле буларак, актив кертелә башлый. Болар барысы да, барыннан да элек, Сиблагтагы тоткын кызларны күрсәтү, аларның интернациональ составы белән бәйле. Әсәрнең икенче өлешендә музыканың интонацион төзелеше тыңлаучыларга аңлаешлырак булып чыкты. Биредә визуаль рәттәге кайбер мизгелләр, мелос (бигрәк тә үткен Нинка җырлары, аларны Л. Добрынина ачык, матур һәм тәэсирле итеп башкарды) Дм. Шостаковичның «Катерина Измайлова» операсы белән билгеле бер охшашлыклар тудырды. М. Хәйруллина

операсында шул ук икенче өлешкә туры килгән патетик кульминация тамашачыны да баш геройлар – Кави Нәҗми һәм Сәрвәр Әдһәмова белән бергә тирән кичерешләр аша узарга мәҗбүр итте. Бу рольләрне талантлы опера җырчылары, Татарстанның атказанган артистлары Артур һәм Эльза Исламовлар башкарды. Соңгы (мәсәлән, җырчы З. Хисмәтуллина юбилеена багышланган) концертларда Эльза Исламова үзенең тавышы һәм югары һөнәри осталыгы белән бигрәк тә аерылып тора. «Кави – Сәрвәр» операсының кульминациясен булдыруда Э. Исламова кантиленасының роле зур.

Операның премьерасы булды. Ул шыгрым тулы залда зур уңыш белән узды. Әмма барыбер операны карарга теләүчеләр бихисап әле. Мондый зур музыкаль сәхнә әсәрләре бер генә тапкыр күрсәтелергә тиеш түгел. Аларны иҗат итү һәм сәхнәгә кую өчен күпме көч һәм вакыт сарыф ителә. Шуңа күрә ким дигәндә өч мәртәбә күрсәтү сорала. Башка теләкләр безнең соңгы вакытта шактый тиз үсә башлаган Татарстан кинематографына адреслана.

Анда музыкаль сәхнә әсәрләрен экранлаштыру кебек махсус юнәлешне аерып чыгарырга иде. Бу – классик татар музыкасына, шулай ук яңа һәм архивларда кулъязма хәлендә сакланган әсәрләргә кагыла. Совет чорының яхшы экранлаштырылган опералары нигезендә укымышлы меломаннарның берничә буыны тәрбияләнде. Моннан тыш, театр сценографиясенең мөмкинлекләре (кинематографтан аермалы буларак) чикләнгән.

Алда әйтеп үтелгәнчә, М. Хәйруллина – пианист та, композитор да. Казанда укуын тәмамлап, Мәскәүдә белем алуын дәвам итә. Бу яктан ул билгеле бер дәрәҗәдә композитор С. Гобәйдуллинаның язмышын кабатлый сыман. Кайчандыр Дм. Шостакович тарафыннан безнең атаклы якташыбызга карата әйтелгән сүзләрне аңа да адреслыйсыбыз килә: «Я Вам желаю идти Вашим “неправильным” путем» [Смирницкий, с. 5]. Бу очракта мин ниндидер гомуми үрнәкләргә таянырга тәкъдим итмәс идем.

### Әдәбият

Сильнее смерти и страха жизни. Кави Наджми – Сарвар Адгамова: история любви: документы, письма, стихи / [авт.-сост.: С.М. Ахтямова, Т.К. Нежметдинов; под ред. А. Карапетяна; худож. О. Маковский; пер. с татар. С. Ахтямовой, А. Карапетяна, Е. Аксенова]. Казань: Агентство «Информ-клуб ЭС». 2004. 158 с.: фотоил., факс., портр. (Документальная серия). На обл. и тит. л. в надзагл.: Негасимый свет любви.

*Смирницкий Я.* Свекольный блюз // Московский комсомолец. 2007. 16 фев.

*Юнусова Г.* Опера «Джалиль» Назиба Жиганова: авторский замысел и современная постановка // *Юнусова Г.Ф.* Мир музыки: сборник статей и материалов. Казань. 2022. С. 246–254.

***Юнысова Гүзәл Фәйзрахман кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 792.09

***Е.Н. Шевченко***

# ДРАМАТИК СПЕКТАКЛЬДӘ ПЛАСТИКАНЫҢ РОЛЕ ТУРЫНДА (Г. Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры тәҗрибәсеннән)

Статья посвящена роли пластического компонента в современном драматическом спектакле. Сегодняшний театр тяготеет к использованию художественных средств других видов искусства, в частности, музыки и танца. В этом направлении активно работает Казанский татарский ТЮЗ им. Г. Кариева, стремясь сделать сценический язык более зрелищным, выразительным и тем самым привлекательным для юного зрителя. В статье анализируются показательные с этой точки зрения спектакли театра. Сделанные в ходе исследования наблюдения выводят на важную теоретическую проблему синтеза искусств в драматическом театре, а его практические результаты могут быть использованы в деле дальнейшего изучения современного театрального процесса.

**Ключевые слова:** синтез искусств, драматический спектакль, танец, пластика, перформанс, Казанский татарский театр юного зрителя им. Г. Кариева, зрелищность.

This article is devoted to the role of the plastic component in the modern dramatic performance. Today’s theater tends to use the artistic means of other types of art, in particular music and dance. The Kazan Tatar Youth Theater named after G. Kariev is actively working in this direction, striving to make the stage language more spectacular, expressive and thereby attractive to the young audience. The article analyzes the performances of the theater that are indicative from this point of view. The observations made in the course of the study lead to an important theoretical problem of the synthesis of arts in the drama theater and its practical results can be used in the further study of the modern theatrical process.

**Keywords:** synthesis of arts, dramatic play, performance, dance, plastic, Kazan Tatar Theater of young spectator named after G. Kariev, entertainment.

Соңгы елларда драма театры кинематограф, мультипликация, рәсем, музыка һәм хореография алымнарын актив кулланып, интермедиаль характерга ия була бара. Афишаларда сәнгати тәэсирлелекнең яңа ысулларын эзләүне, үз драма формалары һәм алымнары палитрасының башка эстетик системаларга мөрәҗәгать итү хисабына баюын раслаган пластик һәм төрле перформатив спектакльләр еш күренә. Европада XX гасырның соңгы утыз елында күзәтелгән бу процесс танылган театр теоретигы немец галиме Хансу-Тизу Леманга хәзерге заман театрын башлыча «постдраматик» дип билгеләргә мөмкинлек бирде. Үзенең күпләргә билгеле «Постдраматик театр» китабында ул яңа дәвердә театрның күбрәк тамашачыга йөз белән борылуын ассызыклый: алар – театрны сәхнәгә кую һәм театрны тамаша дип карау. Әдәби

нигез театр өчен бары тик мөмкин булган аслыкларның берсенә әверелә [Леман, 2013, с. 20]. Галим болай ди: «<…> постдраматический театр предлагает себя как место встречи различных искусств, а потому развивает (и даже напрямую требует) и некоего нового потенциала восприятия, который уходил бы прочь от драматической парадигмы (и даже от литературы вообще). А потому неудивительно, что любители других искусств (изобразительного искусства, танца, музыки <…>) зачастую чувствуют себя куда увереннее в его сферах, чем завзятые посетители обычного театра, привыкшие к литературным, нарративным театральным формам» [Леман, 2013, с. 50].

Әлеге процессларны аерым мисаллар аша күз алдына китерү өчен, Г. Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итик.

2022 елның июнендә Г. Кариев исемендәге яшь тамашачы театры сәхнәсендә театрның баш режиссёры, Россиянең атказанган артисты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Ренат Әюпов тарафыннан «Йосыф» спектакле куелды. Аның нигезенә Урта гасырларда яшәгән мәшһүр болгар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы (XIII гасыр), шулай ук Коръәннең Йосыф пәйгамбәр тормышы турында сөйләүче 12 нче сүрәсе ята. Спектакльне сәхнәгә куючылар төркеме бик көчле: рәссам Игорь Капитанов (Мәскәү), костюмнар буенча рәссам Фәгыйлә Сельская (Мәскәү), ут кую буенча рәссам Евгений Ганзбург (Санкт-Петербург), композитор Йосыф Бикчәнтәев (Казан) һәм хореограф Марат Казыйханов (Казан). Абыйлары тарафыннан коллыкка сатылып, Мисыр фиргавененең наместнигы булып, гөнаһ кылулардан сакланып калып, үзенең туганнарын гафу итеп, кабат әтисен һәм туганнарын тапкан гүзәл Йосыф тарихы пластик һәм музыкаль чаралар белән тәэсирле күрсәтелә. Көндәлек сөйләм теле символик тел белән аралашып, куелышны тамашага әйләндереп кенә калмаган, ә чын-чынлап кызыклы иткән. Бик күп эпизодларга пластика кертелгән. Йосыфның абыйлары һәм геройларны гөнаһлы гамәлләр кылырга этәрүче Шайтан (Альбина Ногманова) катнашкан күренешләр аеруча эффектлы. Актрисаның пластикасы шулкадәр ышандыра ки, хәтта явызлыкның тылсымлы тарту көчен тоя башлыйсың.

А. Гринның шул ук исемдәге повесте буенча куелган «Ал җилкән» спектаклендә дә (режиссёры Ренат Әюпов) пластик чишелеш өстенлек алды. Аның премьерасы 2023 елның сентябрендә булды. Пластика буенча режиссёр Артур Шәйдуллин һәм хореограф Григорий Кириллов белән бергә Ренат Әюпов гәүдә теле, эффектлы пластик миниатюралар ярдәмендә матрослар, обывательләр образларын һәм Артур Грэйның (Искәндәр Низамиев) үтә символик җитлегү һәм балигъ булу юлын булдырган. Спектакльдә театр училищесы студентлары да катнаша, хореографик чишелешне гамәлгә ашыру, нигездә, алар өстенә төшә. Йосыф Бикчәнтәев музыкасы, Евгений Ганзбургның ут партитурасы, Анна Новикова сценографиясе, Фәгыйлә Сельская

костюмнары, Сергей Алаевның саунд дизайны һәм Максим Кунин видеопроекцияләре белән тыгыз бәйләнештәге пластика өлеше билгеле бер стильдәге матур сәхнә формасы тудырырга ярдәм иткән.

Режиссёр Илсур Казакбаевның «Ромео һәм Джульетта» спектаклендә пластика «GAUGA» Казан рок-төркеме башкаруындагы тере музыка белән бергә театр теленең мөһим өлешен тәшкил итте. Аның премьерасы 2022 елның октябрендә булды. Бу – интермедиаль характердагы атаклы пьесаны авторның үзенчә бирүе. Спектакль өстендә рәссам Сергей Кретенчук (Санкт-Петербург), Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, ут кую буенча рәссам Евгений Ганзбург (Санкт-Петербург), хореограф Ольга Даукаева (Уфа), композитор Мәгулә Мезинова (Уфа), «GAUGA» төркеме (Казан) эшләде. Куючылар уйлавынча, спектакль үз алдына яңа буынның Шекспирны үзе өчен ничек ачуын, хәзерге заман яшьләренең сюжет һәм образларны ничек кабул итүен тикшерү бурычын куя. Спектакльдә күп кенә экстравагант алымнар кулланылган. Болар – Ромео (Булат Гатауллин) һәм Джульетта (Рузанна Хәбибуллина, Алия Фәйзиева) аңлашкан чукрак-телсезләр теле; тере музыка – сәхнәдә үзләре иҗат иткән әсәрләрне башкаручы рок-төркем бар; персонажларның хәрәкәтчән сурәтләре төшерелгән, тоныкланып ялтыраучы ут-экраннар; неаполитан җырлары, аларны азарт белән Бенволио (Муса Камалов) җырлый; гендер рольләрнең алмашынуы – Эскал, Верона герцогы, кәкре башлы таяк тоткан өлкән яшьтәге хатын образында (Халидә Сөнгалина) пәйда була һ.б.

Күренеш драматик яктан гына түгел, пластик яктан да корыла, һәм монда төп авырлык хореограф җилкәсенә төшә. П. Пави билгеләвенчә, пластика театры – театраль форма ул, анда селтәнүгә һәм тән хәрәкәте экспрессиясенә өстенлек бирелә, әмма сүзләр, музыка һәм мөмкин булган барлык сәхнә чараларын *a priori* куллануны да кире какмый [Пави, 1991, с. 357). Илсур Казакбаев спектаклендә без нәкъ менә шуны күрәбез дә. Ромео белән Джульеттага гайре табигый – ватык-сынык, ертык пластика хас, әйтерсең рәхимсез дөнья гашыйк балаларны кыйный. Монтекки (Илнар Низамиев, Альбина Гайзуллина) һәм Капулетти (Фәнис Кәлимуллин, Диләрә Зиннәтова), нәфрәттән ташка әверелеп, хәрәкәтсез калганнар. Хәтта финалдагы күренештә дә, балаларын югалтып, авыр хәсрәт кичергәннән соң да, алар кыюсыз гына бер-берсенә каршы барыргамы-юкмы дип, бер генә секундка икеләнеп торалар, әмма катып калган кирелекләре барыбер җиңеп чыга.

Татар яшь тамашачы театры перформансларында пластика аерым роль уйный. 2022/2023 еллар сезонында театр форма һәм сәнгати бурычлары ягыннан төрле өч перформанс куйды.

2022 елның декабрендә «Ремесло» XIV Бөтенроссия яшь режиссура фестивалендә анда катнашучыларга һәм кунакларга режиссёр Булат Минкинның «HOMO SAPIENC» шигъри перформансы тәкъдим ителде. Ул лаборатория эскизыннан үсеп чыкты – 2022 елның

июнендә Кариев театры татар шигъри текстларына багышланган IV «Tamga» режиссёрлык лабораториясен үткәрде. Эскизларда шагыйрьләр Р. Әхмәтҗанов, Н. Гамбәр һәм Зөлфәт шигырьләре яңгырады. Әмма перформансның максаты сәнгати фикерне музыкаль-акустик чаралар ярдәмендә формалаштырудан гыйбарәт иде. Шуңа күрә төп роль музыкаль партитурага (композитор Илнар Фәйзетдинов) бирелде, әмма пластика кире кагылмады. Күренеш «концерт»тан башланды – бәйрәмчә киенгән персонажлар, пюпитрлар алдына басып, туган як турында матур җыр башкардылар. Шул ук вакытта һәркем үзенең кабатланмас манерасында җырлады. Ләкин Булат Гатауллин башкаруында маймылны хәтерләткән тупас, усал җан иясенең пәйда булуы әлеге идиллик картинаны җимерде. Гармония какофониягә әйләнде, матур шигырьләр һәм догалар үзләреннән үзләре көлү булып ишетелә башлады, матур кызлар фурияләргә әверелде, кешелек сыйфатларын югалткан затлар бердәм рәвештә, саф-саф булып, коточкыч хорга кушылып җырлый-җырлый, марш белән монстр артыннан иярделәр. Кыргый приматның хәрәкәтен имитацияләгән пластика (аксаклап йөрү белән бергә) агрессив, примитив һәм куркыныч җан иясе образын тудыруда мөһим чара булып тора. Перформансның башында кызларның туры төз гәүдәсе, зифа буйлы силуэтлары һәм нәфис позалары күзне иркәли, әмма бу күренеш экстатик бию – җен карчыкларының чын гыйш-гыйшрәте белән алмашына. Татар шагыйрьләренең шигырьләре, җыр, дога текстлары спектакль контекстында мәдәният һәм рухият кыры барлыкка китерә. Менә шушы кыр агрессив наданлык һәм тупас хайвани көчнең һөҗүменә дучар була да инде. Нәтиҗәдә, 30 минутлык перформанс кыргыйлык һәм индивидуальлекнең коллективта эреп юкка чыгуы алдында мәдәниятнең көчсезлеге турында метафора булып яңгырый. Бары тик актриса Алсу Шакированың финалда дога кылып елавы гына бер генә «гакыллы кеше»не булса да коткаруга бераз өмет уята.

2023 елның 25 апрелендә, Габдулла Тукайның туган көне алдыннан, театр фойесында «100 Тукай» шигъри-пластик перформансы күрсәтелде (Режиссёры – театр артисты Эльдар Гатауллин). Перформансның төп эчтәлеге «үз Тукаеңны» эзләүдән гыйбарәт. Күренешне труппаның корифее, Татарстан Республикасының халык артисты, Россия Федерациясенең атказанган артисты Нуриәхмәт Сафин ачты. Актёр шагыйрь турында формалашкан, каноник карашны җиткерде: Тукай шундый һәм башкача була алмый. Алга таба Н. Сафин, шагыйрьнең тимер чыбыктан ясалган сынын үзенә үлчәп карагандай итеп, бер читкәрәк китеп басты һәм сүзсез генә күзәтүгә күчте. Ә менә перформансның яшь катнашучылары, алар яшендәгеләргә хас булганча, бернәрсәгә дә ышанмыйлар. Алар шагыйрь образыннан ялтыравыкны алып ташларга һәм аңарда үзләре, бүгенге белән бәйләнешле тере кешене күрергә омтылалар. Шул максат белән алар үзләренә үзләре сорау бирәләр: Ни өчен Тукай? Бүген минем өчен Тукай кем ул? Аның турындагы мәгълүматларның кайсысы

ышанычлы, ә кайсылары юк? Ни өчен без аны апрельдә генә искә алабыз, ә аннары онытабыз.

Сценография, кыска булуына карамастан, тәэсирле һәм концептуаль. Ул җиңел металл каркастан гыйбарәт булып, анда шагыйрьнең фотосурәтләре, аның әйткәннәре, шигырьләреннән өзекләр китерелгән зур кублар беркетелгән. «Тукайны эзләгәндә» актёрлар алар белән һәрдаим бәйләнештә торалар: бер-берсенә ыргыталар, алардан төрле фигуралар төзиләр, язмаларны укыйлар, үз фикерләрен язып куялар һәм бетереп ташлыйлар. Шул ук вакытта алар шагыйрь исемен иҗекләп, җырлап укыйлар, аны аерым хәрефләрдән җыялар, гүя ишетеп тә, күреп тә, капшап та карыйсылары килә.

Спектакльдә алты актёр катнаша. Гомуми ансамбльдә һәркемнең үз нотасы, үз миссиясе бар. Булат Гатауллин шагыйрьгә үзенең хатын укый, Альбина Гайзуллина – үзе язган шигырьне, кемдер Тукай шигырьләрен сәнгатьле итеп сөйли, кемдер җырлый. Эльдар Гатауллин, режиссёр буларак, бөтенесен бер картинага туплаган. Бу уңайдан йомгак мөһим метафора булып тора, катнашучылар, бауны акрынлап сүтә барып, бер-берсенә ыргыталар. Бу – үзенә күрә бер сорау һәм җавап эстафетасы да, чөнки алар бер-берсенең җавапларын кабул итәләр, һәм бер-берсенә Тукайга мөнәсәбәтләрен тапшыручы буыннар бәйләнешенең визуальләштерелгән идеясе дә.

Катнашучылар перформансның вербаль-пластик стихиясендә органик рәвештә яшиләр. Вербаль компонент биредә түбәндәгечә тәкъдим ителгән: сөйләмә һәм график формадагы Тукай шигырьләре, катнашучыларның лирик һәм прозаик текстлары, аларның риторик сораулары, шагыйрь шәхесенә кагылышлы бәхәсле һәм субъектив бәяләмәле фикерләр. Әмма спектакльнең пластик партитурасы ярдәмендә генә Тукайның шәхесен һәм шигърияттен аңларга, шагыйрь дөньясына үтеп керергә мөмкин. Кара фигуралар берөзлексез хәрәкәттә булып, әллә нинди гаҗәп график бизәкләр барлыкка китерәләр (хореограф Елена Музеева). Шул ук вакытта пластиканың характеры режиссёрлар үз алдына куйган бурычлар белән турыдан-туры бәйле. Нәтиҗәдә, спектакльдә 100 Тукай – күпкырлы шагыйрь образы туган, һәм ул актёрларның аңа карата шәхси мөнәсәбәте белән тулыланган.

2022 елның сентябрендә Кариев исемендәге яшь тамашачы театры каршындагы мәйданда «Яралу» музыкаль-хореографик перформансы булды. Аның темасы – спектакль туу. Ул спектакль яралуның барлык этапларын колачлаган сигез өлештән тора: «Эпилог», «Пьеса авторы», «Режиссёр», «Артистлар», «Костюмнар әзерләү», «Администраторлар», «Ут кую», «Туу». Перформансны иҗат итүчеләр бу процессны дөньяга үлән шытып чыгу белән чагыштыралар, ул калын туфрак катламын тишеп, кояшка үрелә һәм акрынлап көчле, матур үсемлеккә әверелә бара – «Яралу» исеме дә шуннан. Идеясе – актёр Булат Гатауллинныкы (куючысы да үзе) һәм спектакльнең үзенчәлекле, матур һәм тәэсирле пластик рәсемен тудырган хореограф Елена Музееваныкы.

Перформанс кире эзлеклелектә, «Эпилог» тан башлана. Һәм тагын тамашаны өлкән буын артисты Нуриәхмәт Сафин ачып җибәрә. Ул спектакльнең төп образларыннан берсе булган үлән образын үз эченә алган шигырьләрне укый – иске үләннәр аша котылгысыз яңасы шытып чыга. Бу фикер театрда буыннар алмашынуы турында һәм спектакльне булдыручылар өчен бик зур әһәмияткә ия. Булат Гатауллин ассызыклавынча, алар «яшьләр тусовкасы» форматында калырга теләмәгәннәр, иҗат төркеме өчен үз театрларын оештыручыларның, беренче башлап юл салучыларның эшен дәвам иттерүләрен күрсәтү мөһим булган.

Спектакльдә Һ. Такташ һәм М. Әгъләмов шигырьләре яңгырый, әмма барыбер аның төп стихиясе вербаль түгел, ә музыкаль-хореографик диясе килә. Өстәвенә, лирик башлангыч белән комедия үзара гармониядә яраша. Зирәк, гротесклы пластик зарисовкалар аша драматургның (Булат Гатауллин) иҗат газаплары җиткерелә, аны образлар һәм идеяләр борчый; режиссёрның (Эльдар Гатауллин) эзләнү һәм шикләнүләре, ул өстәвенә роль таләп итүче актёрларның ярсулы һөҗүменә дучар була; костюмерның (Рамил Вафин) тәкъдим ителгән күлмәкләрне төрле якка ыргыткан ачулы хатыннан (Лилия Гәрәева) куркуы; торба кычкыртып, халыкны тамашага чакырып йөргән администраторларның мәшәкатьләре. Перформанс «Ут кую» һәм «Туу» күренешләре белән тәмамлана: тылсымлы якты нурлар астында (ут куючы рәссам Дмитрий Солопов) актан киенгән актёрлар шатланып бииләр, бу – спектакль тууны күрсәтә.

Анализланган спектакльләрдән чыгып, шуны әйтергә мөмкин: драматик спектакльдә пластика теле әдәби (драматургик) текст, музыка һәм башка сәнгать системалары белән гармониядә яши ала. Ул драматик спектакльнең тамашалылыгын һәм визуаль тәэсирлелеген тәэмин итә, эстетик һәм эмоциональ йогынты көчен арттыра. Пластиканың күләме һәм бу төр куелышлардагы формасы авторлар куйган максат һәм бурычлар белән билгеләнә. Шулай итеп, интермедиальлек законнары буенча яшәүче сәнгать әсәре барлыкка килә.

**Әдәбият**

*Леман Х.-Т.* Постдраматический театр: пер. с нем. М.: Изд. программа Фонда развития искусства драматического театра режиссёра и педагога Анатолия Васильева, 2013. 311 с.

*Пави П.* Театр пластический // Пави П. Словарь театра: пер. с фр. М.: Прогресс, 1991. С. 357.

***Шевченко Елена Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.09

***Фәхрелислам Агиев***

# «КӨНДЕЗГЕ СӘХӘР»

В 1911 году в лито-типографии Харитонова в Казани был напечатан рассказ классика татарской литературы, писателя и публициста Фатиха Амирхана (1886–1926) «Көндезге сәхәр яки рузасызлар». Рассказ был издан отдельной книгой и получил положительные отзывы, в том числе рецензию татарского детского писателя, журналиста и издателя Фахрелислама Агиева (1887–1938). Настоящая публикация содержит текст его рецензии.
**Ключевые слова:** татарская периодическая печать, татарская литературная критика, Фатих Амирхан, Фахрелислам Агиев.

In 1911, the Kharitonov litho-printing house in Kazan published the story of the classic of Tatar literature, writer and publicist Fatih Amirkhan (1886–1926) «Kondezge səkhər yaki ruzasyzlar». The story was published as a separate book and received positive reviews, including a review by the Tatar children's writer, journalist and publisher Fakhrelislam Agiev (1887–1938). This publication contains the text of his review.
**Keywords:** Tatar periodicals, Tatar literary criticism, Fatih Amirkhan, Fakhrelislam Agiev.

*Татар әдәбияты классигы, язучы һәм публицист Фатих Әмирханның (1886–1926) «Көндезге сәхәр яки рузасызлар» хикәясе 1911 елның июлендә языла һәм шул ук елны, «Ташмөхәммәд» имзасы белән, Казанда Харитонов лито-типографиясендә аерым китап булып дөнья күрә. Басылып чыгу белән хикәя матбугатта үз бәясен ала – «Идел» газетасының 1911 елгы 6, 11 сентябрь саннарында татар балалар язучысы, журналист һәм нашир Фәхрелислам Агиевның «Көндезге сәхәр» исемле рецензиясе басыла. Тулаем алганда, әсәр автор тарафыннан уңай бәяләнә, әдәбиятыбызда тәнкыйть мәкаләләренең азлыгына да басым ясалып, күбрәк Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Габдулла Тукаев, Галиәсгар Камал кебек олуг язучыларыбыз тарафыннан гына язылуы искәртелә. Мәкалә гамәлдәге язуда беренче тапкыр тәкъдим ителә.*

*Фатих Әмирханның «Көндезге сәхәр яки рузасызлар» хикәясе бүгенге көндә дә үз бәяләүчеләрен көтә.*

## Әдәбият мәсьәләләре

*Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан*
*Вә юлны тапмый калмый һәр адашкан.*
(Габдулла Тукаев)

I

Соңгы көннәрнең берендә тормышыбызның иң нәни кисәгене харикылгадә[1] осталык белән тасвир кылган Ташмөхәммәд әфәнденең «Көндезге сәхәр» исемле 16 сәхифәлек китабы әдәбиятымыз мәйданына атылды. Зан итәмез ки[2], «Көндезге сәхәр» кеби әдәби ноктаи нәзардан[3] караганда (хакыйкатьне тасвир кыла белдеке өчен), әлбәттә, әдәбиятымызда бөек урын алырга хаклары улан әсәрләре матбугат аркылы тиешле кадәр каршы алу көннәре җитте инде; чөнки яшь әдәбиятымыз: «Явызлыкның җәзасы», «Ачлык кушты», «Бичара Бибиҗиһан» кеби түгел, милли әдәби әсәрләр рәтенә керү, хәтта әдәбият аталырга тиешле булмаган чүпләр белән тула башлады. Яшь әдәбиятымызның ялган бер агым белән китүе яисә, бер тарафтан – яшьтән булачак әдипләремез, вә икенчедән – әдәбиятымызның үзе өчен нихәтле зарарлы икәнчелеге һәркемгә ачык мәгълүм...

Әдәбиятымызда бу көнгә хәтле «Олуг кешеләр һәм анларның әсәрләре»ннән башка рәтле тәнкыйть булганы юк; һәм шуңар күрә әдәбиятымыз һаман үзенең зәгыйфьлегендә дәвам да итә булырга кирәк; чөнки әдәбият атамыз Гаяз, Фатих Әмирхан, Габдулла Тукаев, Галиәсгар Камал[4] әфәнделәрнең хакыйкый әдәби ноктаи нәзардан караганда, үзләренең әсәрләрендә нихәтле хаталыклар кылуларына сәбәп булган нәрсә дә – әдәбиятымызда тәнкыйтьнең булмавыдыр... Хәзерге зикер ителгән бөек адәмнәремез, алдагы көннән алып бу көнгә хәтле дәвам иткән хатларына мәбна[5], әдәбияты нәфисә галәмендә (ихтыярсыз) беркадәр таплар калдырырга мәҗбүр булган булсалар, анларга тәкълид кылып[6] язган мөхәррирләремез бу тапларны нихәтле зур итәргә кирәклеге үзеннән-үзе күренеп тора. Бу башларында әдәбилек таҗларыны йөртергә хаклары улан адәмнәремезнең хаталарыны күрсәтергә вә анларның әсәрләреннән мөштәмил улдыгы[7] фикерләрене укучыларга аңлатырга җөрьәт итәргә тиеш булган тәнкыйтьнең максуды нидән гыйбарәт булырга кирәк?! Бу сөальгә

---

[1] Харикылгадә – гадәттән тыш.

[2] Зан итәмез ки – уйлавыбызча.

[3] Ноктаи нәзардан – караштан.

[4] Зикер ителгән (*телгә алынган)* әдипләремез тугрысында киләчәк көннәрдә хосусый әйтермез *(Ф. Агиев иск.).*

[5] Мәбна – нигезләнгән.

[6] Тәкълид кылып – ияреп.

[7] Мөштәмил улдыгы – җыелган.

киләчәктә хәлемездән килгән кадәр шаяд[1] җавап бирә барырмыз, әмма хәзер максатка кучүемез артык.

II

Ташмөхәммәд әфәнде «Көндезге сәхәр»ендә тасвир кылган каһарманнарына, нә гыйлемдә вә нә фикердә – иштиракъ итми[2]; әмма әдипкә махсус булган үткен күзләре белән, бәлки шул ук шаулы бүлмәнең бер почмагында бүлмәгә яшеренеп килүче әфәнделәрнең сөйләшләрене тыңлап вә кыланышларыны карап кына тора...

Әдип карый, уйлый... Бүлмәдә булган моназараны бозмаенча гына мәйданга куюны үзенең бөек максаты дип белә. Инде мөхәррир максатына ирешә белгәнме? Бүлмәдәге күренеш хакыйкатьтән ерак түгелме?.. Сөальләрене биреп китү вә сөальләремезгә мөмкин хәтле җаваплар бирү – безем мәкаләнең иң теләгән максатыдыр. Дөрест, «Көндезге сәхәр»не бәгъзе бер яшьләремез, хосусан, Кәримнең бүлмәсенә җыелган мирза малайлары, мирза туташлары, яхуд «мирза малайлары!» дип, иптәшләрене мыскыллап, иптәшләреннән көлеп, иптәшләре өстенә (әмма үзе бу эшләрене бик «кызык» дип белеп) төрле ифтиралар[3] ябып йөрүче бай угылларымыз да – яшьләр адресы белән мөхәррир тарафыннан булган һөҗүм дип тә атарлар... Хәер, мирза малайларының үзләреннән анларның әдәбиятка мирза күзе белән генә карауларында вә әдәбият тарафыннан булган хаклы һөҗүмгә каршы мирзаларга гына махсус булган «чувство своего достоинства»[4]ларының азаплануында безем бер тиенлек эшемез юк. Анлар теләсәләр нәрсә уйласыннар: мөхәррирне сүксеннәр, аңар мәшһүр «байкот»ны изһар итсеннәр[5] – әмма без Ташмөхәммәд әфәндене «Көндезге сәхәр»е өчен чын күңелдән тәбрик итеп, киләчәк көннәрдә бу кеби нәфис, хакыйкатьне яшерүдән ерак булган рухының кыйммәтле җимешләрене мәйданга атканда исемне яшермәвен генә үтенәмез. Чөнки мөхәррир әфәнденең яшерен исеме «Ташмөхәммәд» безне аның «Көндезге сәхәр» белән бөтен әсәрләре арасында гомуми булган фикерләре тугрысында бәгъзе әлбәттә әйтелергә тиеш булган сүзләремезне әйтүдән туктальрга мәҗбүр итә...

16 сәхифәле «Замана хикәячеге»ндә тасвир кылынган моназара боннан гыйбарәт: киңрәк кенә бер бүлмә; зур өстәл, аның өстендә унбиш стакан, Кәримнең, мирза малайларының, мирза туташларының вә бай малайларының алып килгән татлы әйберләре, бер заманнан – зур самавыр, тагы бер заманнан – унбиш кеше; бонлар көләләр (нәрсәгәдер, белмим), шатланышалар, бер-берләренә көлке сүзләр

[1] Шаяд – бәлки.
[2] Иштиракъ итми – катнашмый.
[3] Ифтиралар – ялалар.
[4] Кирилл хәрефләре белән.
[5] Изһар итсеннәр – күрсәтсеннәр, мәйданга чыгарсыннар.

әйтеп мыскыллашалар, калын гына «богословъ»[1]тан фәтвалар[2] сорыйлар, бер заман өйдә сулыш алырга мөмкин түгеллегене сизгәч (ни хәтле ачыкканнар бичаралар!), тәрәзә ачу мәсьәләсене күтәрәләр: берләре ачу вә берләре дә ачмау тарафдарлары (бу вакыт мирза туташларыннан берсе калын гына «богословъ»[3] әфәндедән тәрәзә ачу тугрысында Корьәндә бер-бер «стихъ»[4] юкмы дип сорарга оныткан булырга кирәк!) булып кычкырышалар да, ахыр алар тәрәзәне ачалар. Менә урамда булган «саф» һава белән бергә тәрәзәләре алдыннан үтеп бара торган, аягына оек белән кәвеш кигән картрак кына татар хатынының бонларга хитаб итеп[5]: «Чукынчыклар! Йөзеңез каралар! Оятсызлар!» – дип сүгенгән, колакны яңгыратырлык тавышлары да керә. Ләкин бу сүзләрне карчык татар хатыны үзе кычкырмый, бәлки гасырлар белән мирас булып килгән игътикады[6] кычкыра дип аңларга мәҗбүрмез. Бондый карчыкларның кычкыруларына каршы мәдәни адәмнең җавабы да фәкать кайгыдан гыйбарәт булырга тиеш. Әмма безем мирза малайлары бу тугрыда башка фикердәләр; анлар – үз телләре белән әйтелгәндә, «не падая духомъ»[7] татар хатынының сүзләренә каршы, башларында булган бөтен зарафәтләрене[8] ходка йибәрәләр! Бүлмә эчендә булганнарыннан берәвесе: «Оста сүгенәсең икән, абыстай. Карының ачрак булса, шулай сүгенерсең!» – дип кычкырып көлә. Тыштагы ак якалы егет исә абыстайның артыннан:

Тәләт, и син абыстай,
Кем дип әйтим – белмим исмеңне –
Кисәкләп ташласын козгын
Кабан күленә җисмеңне! –

дип, матур гына кычкыра. Бүлмәдә көләләр, шаулыйлар...

Бу хәтле урынсыз вә шунлыктан начар булган зарафәтләрне фәкать мирза малайларыннан гына ишетергә мөмкин. Чөнки ни рус вә ни дә татар рухында булган тәрбия белән тәрбияләнгәнгә, анлардан (хәер, студентлар булсалар да) гакылга сыярлык, мәдәни адәмгә махсус булган сүзләрне ишетү мөхальлеге[9] һәркемгә ачык мәгълүм. Соң бу мирза дигәннәребез кемнәр? Анларны ничек иттереп башка кешеләрдән аерырга кирәк? дип сораучылар да бәлки булыр. Бондый сөальләргә җавап – карт мирзаларның рәсемене күрәсеңез килсә, әдәбият атамыз Гаяз әфәнденең яңа гына әдәбият мәйданына чыккан

---

[1] Кирилл хәрефләре белән.

[2] Фәтвалар – нинди дә булса бер эшне эшләү, дини яктан дөресме-түгелме икәнен күрсәтеп бирү.

[3] Кирилл хәрефләре белән.

[4] Кирилл хәрефләре белән.

[5] Хитаб итеп – эндәшеп.

[6] Игътикады – ышануы, инануы.

[7] Кирилл хәрефләре белән.

[8] Зарафәтләрене – тәрбиялелекләрен.

[9] Мәхальлеге – мөмкин булмаганы.

«Җәмгыять» исемле комедиясене укуыңызны үтенәбез; әмма яшь мирзаларның рәсемнәре «Көндезге сәхәр»дә җитәрлек сурәттә яхшы тасвир кылынган, дип кенә китәмез. Сез тагы: «Ташмөхәммәд»нең бу әсәрендә мирзалар гына тасвир кылынган; бонда учительләр дә бар, бай угыллары да бар, ак якалы егетләр дә бар, хәтта бер приказчик та бар...» диярсез. Һич җавабым юк: «Көндезге сәхәр»дә барысы да бар, әмма барысы да ләфзан[1], мәгънә белән йөртелергә тиеш булган мирза димез; чөнки бу ике кыйсемгә бүленгән мирзалар арасында аслан[2] аерма күрмимез; фәкать карт мирзаларның кабахәтлекләре табигый булганда, яшь мирзаларның кабахәтлекләре тәкълиди[3] дияргә мәҗбүрмез; бонда зур аерма юк. Бу ике кыйсем мирзаларның бер-берләренә охшадыкларыны ачыграк сурәттә күрсәтер өчен түбәндәге мисаллары китерәмез[4]:

Муса мирза – «Вәт беркөн бер миссионер килгән. Директордан бер баланы урыс итәргә акча биреңез», – ди. Мин дидем: «Несми[5], закон юк!» Бирмәделәр. Мин булмасам, вәт, бирерләр иде...», – дип, үзенчә имеш законга мәбни[6] «директор»га һөҗүм итә һәм аны «законга» мохалиф[7] эш эшләдеке өчен куркыта, аның өстенә гайрәт чәчә. Әмма «Көндезге сәхәр»дәге чибәр егет: (кичә конюшняда кучерымызны ашап торган йирендә тоттым. Тетәм гайрәт чәчеп! Ничек кешедән оялмыйсың? Ничек Ходайдан курыкмыйсың? Әтигә әйтсәм, бер көн тотмый куып чыгарыр бит!.. дип, шулай). Юк, үзенә күрә бер (законга) мәбни, үзләренең Рамазанда ашап яткан кучеры өстенә һөҗүм итә; һәм аны – Ходайдан, халыктан курыкмаган кучерны атасы белән куркытырга азаплана... Хәзер генә мисалга китергән ике әдибемезнең сәтырларында[8] мөштәмил[9] улдыгы рухның раслыгы вә хаклыгы безне гаҗәпкә калдырып, бу тугрыда артык сөйләп торуның да кирәксезлегене ачык күрсәтә. Фәкать бу ике мирзаларның эчләре ни хәтле кабахәтлекләр, ни хәтле инсафсызлыклар, вә ни хәтле вөҗдансызлыклар белән тулган, дип кенә калырга мәҗбүрмез. Карт мирзасы, ичмасам, Бохара чүплекләрендә ятып, миләрене череткән «хәзрәтләр» белән козгын кеби үз файдаларыннан бөтен куәтләре белән качарга тырышкан, халыкны алдап көннәрене үткәрә килгән, кешеләрне алдап, калын корсаклар каршысында сәҗдә кылып, бөтен гомере буенча теләп килгән «гласныйлык» дәрәҗәсене алырга тырыша...

[1] Ләфзан – сүзләрнең мәгънәләренә карамыйча.
[2] Аслан – һичбер.
[3] Тәкълиди – ияреп.
[4] «Җәмгыять», 18 нче сәхифә.
[5] Несми – не смей.
[6] Мәбни – нигезләнеп.
[7] Мохалиф – каршы.
[8] Сәтырларында – язу юлларында, ягъни язмаларында.
[9] Мөштәмил улдыгы – үз эчендәге.

Әмма бу яшь мирзаның иптәшене алдап ятудан максаты нәрсә икән?!

Хәер, безем яшь мирзалар бер-бер эшкә башлаганда «максат» дигән нәрсәне игътибарга алмыйлар, дөрестене генә әйткәндә, алар белмиләр булырга кирәк! Чөнки югарыда әйтдекемезчә, анларның бөтен тормышлары тәкълидтән[1] гыйбарәт. Әмма анларның тәкълид кылынышлары урынлымы, юкмы – яшь мирзаларымызга барыбер. Бу тугрыда «Көндезге сәхәр»дәге «Бетте баш, кипте яшь...» җырыны мирза малайларының бер кылы өзелгән гитара тавышына җырлаулары үзе ачык дәлилдер, дия зан идәмез. Дөрест, Кәрим бүлмәсендәге кеби яшьләрнең җыелышуларында, көлке вә уйнашлар белән бергә, әлбәттә, җырлашулар да була, ләкин бондый мәҗлесләрдә булган җырлар һәрвакыт мәҗлеснең рухына карап булырга тиешлеген дә хәтердән чыгармыйк. Бит укучым, «Бетте баш...» җыры, бер тарафтан, «Көндезге сәхәр»дәге мирза малайларының рухларына, тормышларына аслан мөнәсәбәте юклыгы өстенә, икенчедән дә – анлар тарафыннан җырлана торган җыр түгел. Бит бу җыр фәкать күңеле сыныккан, рухы сүнгән, тормышның барлык агырлыклары белән изелгән, тормышының киләчәктәге якты көннәреннән өмиде өзелгән, әмма шулай да әллә нинди катылыкларга, әллә нинди җәзаларга, әллә нинди кысынкылыкларга буйсынырга хәзер булган бер адәм тарафыннан җырлана торган җыр ич! Бит бу җырның соңгы сүзләрене әйтергә өлгерә алмаенча, җырлаучының күзләре ачы яшь белән тулган булырга, йөрәге, дөньяда күргән хәсрәтләре белән парчаланган йөрәге, соңгы акрынлык белән тибәргә тиеш! Бит бу җырны җырлаган адәмнең тавышында, гүя тормышында «якты» дип саналган көннәренең дәкыйкасы[2] хис ителә вә шуңар күрә җырчы үзен үзе «язмышының ихтыярына ташлады да, киләчәктәге көннәре тугрысында: «Азармын, тузармын шулай мин йөреп, язмышның бурычын тик үтәрмен...» – ди. Боннан соңгы тормышны фәкать бер Алла гына белүче!

Әмма бу җырдан соң безнең мирза малайларының каршысына: «Озакламый самавыр да керә; кунаклар һәммәсе үзләре китергән капчыклы нәрсәләрене бушатырга тотыналар. Өстәл өсте булкилар, слойкалар, кондитерскийларда пешерелгән сумсалар, савытлы икралар...». Тагы әллә нәрсәләр, тагы әллә нәрсәләр..., әлхасыйль[3], өйләренә кайткач, мирза малайларыны «слабитель»[4] эчәргә мәҗбүр итмәгән барлык нәрсәләр өстәлгә тезеләләр.

Вөҗданән әйткәндә, шушындагы өстәлгә тезелгән ашлар тәрәзә яныннан үткән татар хатынына (хәтта берничә баласы булса да) бөтен сәхәр вә ифтарларыны үткәрергә җитәр иде! Ләкин безем мирза

[1] Тәкълидтән – иярү, охшатып эшләүдән.

[2] Дәкыйкасы – минутлары.

[3] Әлхасыйль – нәтиҗәдә.

[4] Кирилл хәрефләре белән.

малайларыны бу тугрыда уйлап вә фикерләр йөртеп, башларыны ватып, бер тарафтан, табигать үзе вә икенчедә дә «почтенный»[1] аталары саклаган. Хәтта мирза туташлары шул хәтле «назнин»[2] вә «нәфис» тәрбия алганнар ки, Рамазан аенда руза тотып азаплануны мөттасил[3] «серый»[4] халыкка гына тиеш дип беләләр. Менә сезгә мирза кызы Гайшә туташның тәтәсе белән урамда барганда бер «старъевщикъ»[5]-ның тәмәке тартып барганыны күргәч, гаҗәпләнгәне:

– Хәзер «простонародие»[6] арасында уразаны «соблюдать»[7] итми торган кешеләр бар, ахрысы...» – дип сөаль бирә... Бөек Раббым! Бу туташ Кәримнең иптәше өендә озын күлмәкле (әлбәттә, изүе чишелгән булырга кирәк), камзулчан гына өстәл артына утырып, кояш баегач, ифтарга дәгъвәт ителгән[8], иске мәдрәсә почмакларыны черетүче бер чыкылдаган татар хәлфәсенең чәй эчеп утыруыны күрсә, бәлки тагы да кабахәтрәк – дүрт сүзле җөмләнең өчесе рус сүзләреннән мөрәккәб[9] булган – бер сөаль бирер идеме? Бирер иде?.. Бирер иде! Чөнки «назнин» вә «нәфис» тәрбия алган мирза кызлары өчен, үз телләре белән әйткәндә, «некультурный»[10] татар теле белән сөйләшү ифрат дәрәҗәдә хурлык икәнчелегене хәтеремездән чыгармау тиешле!

Сүземез озакка китә башлады бугай. Мирза кызлары, мирза малайлары тугрысында сөйли-сөйли мәкаләмез «Көндезге сәхәр»дән зуррак булмасын дип курка башладык. Шуңар күрә тагы берничә сүз, аннан соң мәкаләгә хәтем[11].

## III

Шулай итеп, 16 сәхифәле «Көндезге сәхәр» тормышымызның нәни генә кыйсемендә вә һәрдәм[12] була торган бер моназараны [13] – тел җәһәтеннән ифрат матур вә әдәби җәһәтеннән гаять нәфис сурәттә тасвир кылып, безем күз алдымызга куя. Хакыйкатьне бойлә[14] ачык, раст вә үткен булган татарның әдәби теле белән язып мәйданга куя белүе, әдәбиятымызның мирза малайларының ялтыравыклы төймәләренә, мирза туташларының «назнин» тәрбияләренә,

---

[1] Кирилл хәрефләре белән.
[2] Назнин – иркә, назлы.
[3] Мөттасил – тоташ, өзлексез.
[4] Кирилл хәрефләре белән.
[5] Кирилл хәрефләре белән.
[6] Кирилл хәрефләре белән.
[7] Кирилл хәрефләре белән.
[8] Дәгъвәт ителгән – чакырылган.
[9] Мөрәккәб – оешкан, кушылган.
[10] Кирилл хәрефләре белән.
[11] Хәтем – тәмамлау.
[12] Һәрдәм – һәрвакыт.
[13] Моназараны– фикер алышу, бәхәсләшүне.
[14] Бойлә – шулай.

үзләрене мирза калебе[1] белән үлчәргә «тырышкан» бай малайларының хәтерләре калуына бер тиенлек әһәмият бирмәве, аны – әдәбиятымызны, тагы биегрәк тәхеткә утырта һәм безем дә киләчәк көннәрдә аның тарафыннан хакыйкатьне мәйданга куя белүенә иманымызны тазарта! Һәм безем бу ышанычларымызга 16 сәхифәле «Көндезге сәхәр» сәтырларының аз сүз белән мирза малайларының мәдәнияттән бик ерак саналган вәхши холык, кылынмый торган кыланышларыны матур бер моназара итеп тасвир кыла белүе үзе ачык дәлилдер.

Ләкин «Көндезге сәхәр»нең әдәбиятымыз мәйданына чыгуы безне ни хәтле шатландырса да, аны «әдәбиятымызның кечерәк кенә йолдызы» дип атарга мәҗбүр итсә дә, «Замана хикәячеге»нең сәхифәсенә, ямьсез вә хакыйкатьтән ераклыгы белән күңелләрне болгатырлык бер тап төшерү уе белән, Ташмөхәммәд әфәнде бөтенләй үк булмаса да, әмма кәефне боза. Бу кәефне боза торган сәтырлары да боннан гыйбарәт:

Ташмөхәммәд әфәнде: «Халык берничә минутка бары ашау-эчү белән генә мәшгуль булганга күрә, мәҗлес бу вакытта тавышсыз-тынсыз кала. Бераз ашалып, әүвәлге стакан чәйләр эчелгәч, акрын сүз башланып китә. Рус мәктәпләрендә укулар башлану, укучыларның Казанга килә башлаулары, Л. Андреевның[2] соңгы әсәре, татар дарелмөгаллимине, татар мөхәррирләреннән берсенең соңгы хикәясе вә башка күп нәрсәләр сөйләнеп узалар», ди. Бу сәтырларны ямьсез бер «тап» дип атавымызга сәбәп булган нәрсәләрдә: бер тарафтан – мөхәррир әфәнденең (белмим, ни өчендер!) мирза малайларыны араларга тырышып (ягъни анлар болай уйладылар, тегеләй сөйләштеләр, фәләнчә фикерләр йөртештеләр дип) үзенә адвокатлык портфелене алуы; вә икенчедән, мирза малайларына, көчләп, анларның барлык тормышларына, анларның рухларына кире булган фикерләрне бәйләведер. Мирза малайларының рус мәктәпләре вә анларда укулар башланулары тугрысында сөйләшүләре (ләкин без мирза малайларының бу тугрыда сөйләшүләрене «Көндезге сәхәр» дә күрмимез) бер фараз, дөрест тә булсын; әмма анларны А. Андреев әсәрләре, татар әдәбияты, яхуд татар дарелмөгаллимине хакында сөйләштеләр дип әйтү үзе әдипнең яңлыш адымыны күрсәтә; әдипнең йөзене кызарта торган, бер көлке сүз генәдер. Хәер, адәм хатадан хали[3] түгел, диләр. Һәм безем дә мөхтәрәм әдибемез киләчәктә мәйданга куярга хәзерләнәсе әсәрләрендә бондый хаталарыны тәкрар итүдән саклана белер дип өмидемезне өзмимез.

Мәкаләмезнең башында мөхәррир әфәнде «Көндезге сәхәр»дәге «яшьләр»нең фикердәшләре түгел диган идек һәм бу тугрыда сүзне

[1] Калебе – күңеле, йөрәге.
[2] Кирилл хәрефләре белән.
[3] Хали – буш.

озатмаенча, фәкать «Замана хикәячеге»нең соңгы сәтырларыны гына зикер итүне[1] мәгъкуль күрер идек.

Әдибемез: «Бу әфәнделәрнең тук вә нәшатлы[2] йөзләренә, нык вә таза йөрешләренә, шатлыклы сөйләш вә көлешләренә карагач, бик күп карендәшләреңезнең нәкъ шушы вакытта ачлык вә сусызлыкта икәнлекләрене оныттыгызмы әллә? дип сорыйсы киләә», – ди. Беземчә, бу сәтырлар Ташмөхәмәд әфәнденең «Көндезге сәхәр»ендә хәрәкәт иткән каһарманнарына ни күз белән карадыгыны ачык вә хатасыз белдерә беләләр.

*Идел. 1911. 6, 11 сентябрь.*

*Басмага әзерләде:*
***Галимҗанова Эльмера Мәхмүт кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге мөдире*

[1] Зикер итүне – искә алуны.
[2] Нәшатлы – шатлыклы.

УДК 930.271

***В.М. Усманов***

# ЮТАЗЫ ТӨБӘГЕНЕҢ ТАШЪЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена исследованию сохранившихся эпиграфических памятников на мусульманских кладбищах сёл Ютазинского района. В результате проведённой экспедиции было выявлено и зафиксировано более двухсот арабографических артефактов. Основная часть эпитафий выполнены из местных непрочных песчаников, которые под воздействием отрицательных природных факторов отслаиваясь легко разрушаются, выветриваются и уходят в небытие. И поэтому, при таких обстоятельствах, есть неотложная необходимость сохранения сведений «каменного архива», хотя бы путём составления свода эпиграфических памятников в виде каталога с последующей публикацией для введения в научный оборот в наиболее полном объёме.

Более 80% информации мы получаем через зрительные органы. А в эпиграфике главным носителем информации является сам объект, в данном случае, фотографии соответствующего качества, оттиски, эстампажи или прорисовки. В связи с этим, как приложение к данной статье предлагаются графические изображения – иллюстрации.

**Ключевые слова:** мастера письма по камню, эпиграфические памятники, резчики письма, каллиграфы, прорисовки.

The article is devoted to the study of the preserved epigraphic monuments in the Muslim cemeteries of the villages of the Yutazinsky district. As a result of the expedition, more than two hundred Arabographic artifacts were identified and recorded. The main part of the epitaphs are made of local fragile sandstones, which, under the influence of negative natural factors, flaking off, are easily destroyed, weathered and go into oblivion. And therefore, under such circumstances, there is an urgent need to preserve the information of the «stone archive», at least by compiling a set of epigraphic monuments in the form of a catalog with subsequent publication for introduction into scientific circulation in the fullest possible volume.

We receive more than 80% of the information through the visual organs. And in epigraphy, the main data carrier is the object itself, in this case, photographs of appropriate quality, prints or drawings. In this regard, graphic illustrations are offered as an appendix to this article.

**Keywords:** masters of stone writing, epigraphic monuments, carvers of writing, calligraphers, drawings.

2023 елның 18–27 сентябрендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган комплекслы фәнни экспедиция Татарстан Республикасының Ютазы районына кергән татар авылларында эшләде. Максаты – бу якларда сакланып калган мәдәни ядкәрләрне, шул исәптән эпиграфик һәйкәлләрне дә барлау, теркәү, исәпкә алу иде. Ютазы төбәгендәге татар кабер ташлары, фәнни чыганак

びларак, А. Борһанов [Бурханов, 2012], М. Закирова, А. Ибраһимова, Ә. Хаҗиева [Закирова, Ибраһимова, Хаҗиева, 2022] һ. б. тарафыннан күпмедер күләмдә өйрәнелгән.

Иң борынгы истәлекләрдән Иске Урыссу авылы янында урнашкан калкулыктагы ике балбал – «Таш хатын» сыннарының (X–XII гасырлар) булуы мәгълүм. Кызганычка каршы, алар 1940–1960 елларда җимерелеп юкка чыкканнар.

Ташъязма истәлекләрдән, иң әүвәлгеләре – Иске Урыссудагы Муса кызы Зөһрә һәм Бәйрәкәдәге Йосыф Котлыгмөхәммәд угылы Тәфкилев каберләренә 1767 һәм 1773 елларда куелган ташлар. Чагыштырмача, ташъязмаларга бай зиратлар Бәйрәкә, Иске Урыссу һәм Кәрәкәшле авылларында урнашкан. Сакланып калган борынгы кабер ташларының саны түбәндәгечә:

Акбаш авылы – 22 (ташъязма);
Акъюл авылы – 7;
Байлар авылы – 0;
Бәйрәкә авылы – 29;
Бәйрәкә Тамак авылы – 3;
Дим Тамак авылы – 7;
Әпсәләм авылы – 7;
Иске Каразирек авылы – 11;
Иске Урыссу авылы – 40;
Кече Урыссу авылы – 4;
Кәрәкәшле авылы – 26;
Көрәш Бүләк авылы – 3;
Колчан авылы – 1;
Салкын Чишмә авылы – 0;
Ташкичү авылы – 8;
Урыссу авылы – 8;
Ютазы авылы – 19;
Яңа Каразирек авылы – 19;
Яссы Тугай авылы – 12.

Кабер ташларының күбесен кем язганлыгы төгәл билгеле түгел, әмма шунысы аңлашыла – алардагы язу-бизәкләрнең шактые җирле укымышлы кул осталары (еш кына дин әһелләре) тарафыннан башкарылган. Кайбер кабер ташларындагы авторлары безгә төгәл билгеле булмаган ташъязмалар читтә эшләтеп китерелгән. Мондый үрнәкләр Башкортстан һәм Татарстан республикалары чигендә урнашкан районнарда еш очрый. Кабер ташларының бер өлеше профессиональ осталар тарафыннан ясалган, шулар арасында берничәсе гади кятиб кенә түгел, ә чын мәгънәсендә хаттат дип саналырга хаклы. Кайбер кятибләр ташларда үзләренең исемнәрен дә уеп-язып калдырганнар, мәсәлән: *«Ошбуны яздым Габделҗәлил»* (Акбаш авылы), *«Кятиб Гали бине Мөхәммәдсадыйк»* (Акбаш авылы; Дим-Тамак авылы), *«Кятиб Зыяддин бине Хисамеддин, Чупай карьясе»* (Бәйрәкә авылы),

«*Ошбуны язучы Шәрифулла*» (Акбаш авылы), «*Кятиб Хәсән*» (Ташкичү авылы). Эш барышында соңгы дәвер осталарының да исемнәрен язып алдык: мәсәлән, Акъюл авылында Заһид Инсаф улы Фәттахов (1951–2005), Наиль Кави улы Фәттахов.

Ташъязма ядкәрләрнең күбесе шул урындагы карьерлардан (тау башларыннан, елга буйларыннан) чыгарылган «өлгереп җитмәгән» йомшак һәм уалып барган ком-ташлардан ясалган, шул сәбәпле эпитафияләрнең бер өлеше җуелып юкка чыккан яисә бик начар хәлдә сакланган. Аларның шактые катлам-катлам аерылып һәм ярылып җимерелә бара. Арада ныклы һәм каты ком-ташлар да бар, аларны еш кына шомартып, нечкә генә хәрефләр белән уеп-чокып язганнар.

Фаразларга караганда, кайбер известьташлар Әлмәт ягындагы Чупай карьерыннан китерелгән: мәсәлән, Зыятдин кятиб кулы белән язылган рельефлы таш. Ядкәрләр арасында мәрмәрдән яисә граниттан ясалган затлы ташлар табылмады.

Кайбер кабер ташларында нәсел тамгаларын очратырга мөмкин, әмма бу – сирәк күренеш, гомумән бу төбәктә борынгыдан килгән ыру билгеләре сакланмаган диярлек. Күп кенә зиратларда кабер өсләрен бура яисә кыргый ташлар белән уратып алганнар, алар күп түгел, әмма кайберләре безнең көннәргә кадәр саклана алган.

Ютазы ягындагы зиратларда гүр ташы урынына имән агачыннан ясалган кабер казыгы урнаштыру очраклары да бар, бу төбәктә аны башказык дип атап йөртәләр. Күрәсең, борынгы заманнарда, мондый гади башбаталарга[1] нәсел тамгалары уелып ясалган булгандыр. Хәзерге көннәрдә башказыкның киртләп алынган өлешендәге яссылыкка мәрхүмнәрнең исем-шәрифләренең баш хәрефләрен кисеп язганнар. Күпмедер вакыт үткәннән соң, матди мөмкинчелектән чыгып, башказык янәшәсенә язулы кабер ташы да куелган. Соңгы берничә дистә ел дәвамында мәрхүмнәрнең портретларын мәрмәр ташларга ясап, кабер өстенә веноклар кую кебек читтән кергән гадәтләр дә өстенлек ала башлаган. Кабер ташларындагы язуларның кайберләре тимер калайга (пластинкага) язылып, чардуганга беркетелгән.

Аңлашыла ки, борынгы яисә элекке гүр ташлары гарәп язуында башкарылган һәм бу традиция өзелмәгән, безнең көннәргә кадәр сакланып кала алган. Дөрес, хәзерге вакытта, кабер ташларындагы текстларның төп өлеше тулысынча кирилл хәрефләре белән татарча языла. 1929–1940 еллар аралыгына караган язма ядкәрләр арасында латин хәрефләре белән башкарылганнары да бар. Аларның күбесе, әйткәнебезчә, уеп язылган, иң күркәм композицияләрнең күп өлеше калкытып язу ысулы белән рельефлы рәвештә эшләнгән. Гадәттә, татар осталары гарәп хәрефләренең кырларын кыек итеп кисеп язганнар һәм, шул рәвешле, ташъязмалардагы бизәкләрне төрле төсмерләр, сыгылмалы сызыклар белән баетып, сәнгати әсәр тудырырга тырышканнар. Кабер ташларында, нигездә, татарча шигъри

[1] Үлгән кешенең каберенә язып куелган кабер ташы.

юллар теркәлә, әмма бу төбәктә андый үрнәкләр күренмәде. Ютазы төбәге эпитафияләренә генә хас булган аерым үзенчәлекләр юк дәрәҗәсендә, гомумән, биредә татарларда очрый торган ташъязма традицияләре саклана.

Ютазы районы авыллары зиратларында 2023 елда үткәрелгән комплекслы фәнни экспедиция барышында үзебез игътибар иткән каберташ язмалары текстларын һәм аларның транслитерацияләрен тәкъдим итәбез. Транлитерация фәнни камиллеккә дәгъва итми, әмма мөмкин кадәр төгәллекне сакларга тырышып, аерым очракта тәрҗемәсен дә бирергә омтылып эшләнде.

[**Ишкенә**] каберенә куелган таш.
Акбаш авылы, 1 нче зират





| Текст | | Транслитерация |
|---|---|---|
| لا اله الا الله محمد رسول الله | 1 | Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлуллаһ[1] |
| لا جل ایشکنه | 2 | ли әҗели Ишкенә[2] |
| اوشبونی مین یازدم عبدالجلیل | 3 | ошбуны мин яздым Габделҗәлил |

[1] *Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлуллаһ* – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.

[2] *Ли әҗели Ишкенә* – Мәрхүм Ишкенә өчен.

**Йосыф** Котлыгмөхәммәд улы каберенә куелган таш, 1773 ел. Бәйрәкә авылы[1]





| Текст | | Транслитерация |
|---|---|---|
| ... | 1–5 | ... |
| تاريح مسحيه ايله | 6 | тарих мәсихия илә |
| ١٧٧٣ يلده مرزه يوسف | 7 | 1773 йылда морза Йосыф |
| قوتلوغ محمد اوعلى | 8 | Котлугмөхәммәд углы |
| شهد شهيد شربتن نوش | 9 | шәһәдән шәһид ширбәтен нуш |
| قيلب ٥٥ عمر كچروب دارفنادين | 10 | кылыб[2] 55 гомер кичереб дарелфәнадин |
| داربقايه رحلت قيلدى | 11 | дарелбәкая рихләт кылды |

[1] Бу турыда төгәлрәк: *Закиров Ә.Ә., Закирова М.Н., Хаҗиева Ә.Х.* Бәйрәкә: тарих, мәгърифәт, шәхесләр. Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2020. Б. 40–42; Ютазинский регион: проблемы истории и культуры. Село Байряка и Ютазинский район в системе культур и цивилизаций Юго-Восточного Татарстана и Волго-Уральского региона: материалы конф. // Серия «Восток – Запад: диалог культур и цивилизаций Евразии». Выпуск 11. Под редакцией А.А. Бурханова. Казань: Изд-во «ЯЗ», 2012. С. 352.

[2] *Шәһәдән шәһид ширбәтен нуш кылыб* – Шәһид булып үлем ширбәтен эчеп (вафат).

**Исхак** Муса улы каберенә куелган таш, 1895 ел.
Бәйрәкә авылы



| Текст | | Транслитерация |
|---|---|---|
| كل نفس ذائقة | 1 | Көллү нәфсин заикател- |
| الموت ثم الينا تر جعون | 2 | мәүт сөммә иләйнә түрҗәгунә[1] |

[1] *Көллү нәфсин заикател-мәүт сөммә иләйнә түрҗәгунә* – Әлбәттә, үлем ачысын һәркем татыячактыр, соңра кубарылып, Миңа кайтырсыз («Ганкабут» сүрәсе, 57 нче аять).

| | | |
|---|---|---|
| هذا مرقد شريف | 3 | hазә мәркадь шәриф[1] |
| اسحاق بن موسى | 4 | Исхак бине Муса |
| دار فنادان | 5 | дарелфәнадән |
| داربقايه رحلت | 6 | дарелбәкая рихләт |
| قيلدى تاريخ مسيحيَّه | 7 | кылды тарих мәсихийә |
| ايله ١٨٩٥ سنه ده مارط | 8 | илә 1895 сәнәдә март- |
| ننک ۶ نچى كوننده ياشى | 9 | ның 6 нчы көнендә |
| ۶٣ ياشنده | 10 | 63 яшендә |

**Мөхәммәдсадыйк** каберенә куелган таш. 1885 ел.
Дим-Тамак авылы




| Текст | | Транслитерация |
|---|---|---|
| لا اله الا الله محمد رسول الله | 1 | Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлуллаһ |
| صاحيب هده القبور | 2 | сахиб hазә әл-кабер |
| محمد صاديق | 3 | Мөхәммәдсадыйк |
| كاتب على | 4 | Кятиб Гали |
| ١٨٨٨ يلده | 5 | 1888 йылда |

[1] Бу кабер иясенең хөрмәткә лаек кеше булуына ишарә.

Муса мулла Габделҗәлил ... улының кызы **Зөһрә** каберенә куелган таш, 1767 ел. Иске Урыссу авылы



| Текст | | Транслитерация |
|---|---|---|
| تاريخ منكدا يوزده | 1 | тарих меңдә йөздә |
| سكسان برنچى | 2 | сиксән беренче |
| يلنينك اىچندا ايردى | 3 | йылының [эчендә] ирде |
| جمادل الا خر ايندا قزان ايوزينك | 4 | җомадиәл-ахыр аенда Казан өязенең |
| آلاط يولنك مرضالار اوروسينك | 5 | Алат юлының Морзалар Ырысының |
| موسى بن ملا عبد الجليل مر...تلى | 6 | Муса бине мулла Габделҗәлил Мор...тлы |
| اوغلينك قزى زهرا قبردور | 7 | углының кызы Зөһрә кабередер |

**Габдулла** Әхмәдшаһ улы каберенә куелган таш,
1901 ел. Иске Урыссу авылы





| Текст | | Транслитерация |
|---|---|---|
| ۱۹۰۱ یلده ۳۰ نچی مارط ده | 1 | 1901 йылда 30 нчы мартда |
| بسم الله الرحمن الرحيم | 2 | Бисмиллаһир ир-рахман ир-рахим[1] |
| دارفنادان داربقایه رحلت قلدی | 3 | дарелфәнадән дарелбәкая рихләт кылды |
| وفات مرحوم عبد الله ابن | 4 | вафат мәрхүм Габдулла ибне |
| احمد شه بن ملّا محمد | 5 | Әхмәдшаһ бине мулла Мөхәммәд- |
| امین بن ابراهیم رحمت الله | 6 | әмин бине Ибраһим рәхмәтуллаһи |
| تعالی رحمتً واسعتً | 7 | Тәгалә рәхмәтән васыйгатән |
| ... آمین | 8 | ... амин |

[1] *Бисмиллаһир ир-рахман ир-рахим* – рәхимле, шәфкатле Аллаһ исеме белән.

**Мөэминә** Арыслан кызы каберенә куелган таш, 1802 ел.
Кәрәкәшле авылы





| Текст | | Транслитерация |
|---|---|---|
| ١٨٠٢ يلدا حوت | 1 | 1802 йылда хут- |
| ننک ٢١ ندا ... | 2 | ның 21 ндә ... |
| مقبرسنڭ صحبى مرحو | 3 | мәкъбәрәсенең сахибе мәрхү- |
| مه [مؤمنا] بنت ارصلان | 4 | мә [Мөэминә] бинте Арыслан |
| .... | 5 | ... |

Ютазы районы кабер ташларын өйрәнгәндә бик кызыклы мәгълүматларга да тап булдык. Мәсәлән, Риза Фәхретдинов үзенең хезмәтләрендә хәтта гади генә ташъязмаларны да исәпкә ала барган. Шуларның берсе – Урыссу авылының иске зиратындагы эшкәртелмәгән ташка уеп язылган текстлардан булып, билгеле шәхес – Тайсуган имамы Габденнасыйрның бабасы Әхмәр бине Габделмәннан каберенә куелган таш [Фәхретдинов, б. 22–23]. Ютазы районы зиратларында мәрхүм булган мәшһүр дин җитәкчеләренә куелган эпиграфик истәлекләр дә бар, шуларның кайберләре – мулла Гобәйдулла, мулла Муса, мулла Сәлимҗан, мулла Хөсәен, шәех Габделгали, мулла Мөхәммәдгази, мулла Габделҗәлил, мулла Әхмәдшаһ, мулла Мөхәммәдәмин, сәүдәгәрләрдән – Мөхәммәдшәриф Габделмәҗид углы һәм Хаҗи.

Бу төбәк эпитафикасын өйрәнү шуны күрсәтте: кырыс табигать шартларында комташтан ясалган ядкәрләрнең күбесе зыян күрсә дә, мондагы халык аларны кадерләп саклый белә. Бу уңай күренеш дин һәм мәгърифәт үзәкләренең берсе булган бай тарихлы Бәйрәкә авылына аеруча хас. Авылдагы элекке мәдрәсә биналарының да, иске зираттагы ташъязмаларның да, шул исәптән, данлыклы муллаларының каберләре дә караулы булуына һәм тәртиптә саклануына

игътибар иттек. Кайбер кабер ташларында шәһәр-авыл исем-атамалары да телгә алына, мәсәлән: әл-Бәйрәкәви, «Чупай карьясе», «Алат юлының Морзалар Ырысы», Бурсык авылы, Казан.

Эш барышында ташларның саклану дәрәҗәсенә карап сайларга һәм исәпкә алырга тырыштык, алардагы язуларны укыдык һәм фоторәсемгә күчердек. Бер җыентыкка тупланган бай һәм кызыклы тарихи чыганаклар төбәк һәм татар тарихын өйрәнүчеләргә файдалы кулланма булыр дип ышанабыз. Мәдәни язма ядкәрләр көннән-көн җимерелеп юкка чыга бара, шул сәбәпле, максатыбыз – бу кабер ташларындагы мәгълүматларны кәгазьләргә һәм электрон ресурсларга күчерү юлы белән киләчәк буыннарга җиткерү, фәнни әйләнешкә кертеп җибәрү.

Эпиграфиканы өйрәнгәндә төп мәгълүмат бирүче объект – ташъязма, ягъни, безнең очракта, кабер ташының сыйфатлы фоторәсеме, эстампажы яисә рәсем-күчермәсе. Шул сәбәпле, фән өчен аеруча әһәмиятле булган рәсемле чыганакларга зур игътибар бирелде. Кабер ташларын вакытында фотога төшереп, рәсемен ясап калырга кирәк. Бу эш башкарылмаган очракта, кабер ташларының югалу ихтималы зур. Фотодокументация булдыру, аны туплау киләчәк буын галимнәренә ташъязмаларны өйрәнергә, тикшерергә, укылышларны төгәлләп камилләштерергә мөмкинлек бирә.

## Әдәбият

*Бурханов А.А.,Мухаметшин Д.Г.* Очерки истории Ютазинского региона (Ютазинский регион в системе культур Восточного Татарстана и Волго-Уралья. Древность и средневековье). Материалы Первой региональной научно-практической конференции «Ютазинский регион: проблемы истории и культуры. Село Байряка и Ютазинский регион в системе культур и цивилизаций юго-восточного Татарстана и Волго-Уральского региона». // Серия «Восток – Запад. Диалог культур и цивилизаций Евразии». Выпуск 10. Под редакцией А.А.Бурханова. Казань: Изд-во «ЯЗ». 2012. С. 150.

Ютазинский регион: проблемы истории и культуры. Село Байряка и Ютазинский район в системе культур и цивилизаций Юго-Восточного Татарстана и Волго-Уральского региона. Материалы конференции. // Серия «Восток – Запад: диалог культур и цивилизаций Евразии». Выпуск 11. Под редакцией А.А. Бурханова. Казань: Изд-во «ЯЗ», 2012. С. 352.

*Закиров Ә.Ә, Закирова М.Н., Хаҗиева Ә.Х.* Бәйрәкә: тарих, мәгърифәт, шәхесләр. Казан: «Школда» редакция-нәшрият үзәге, 2020. 696 б.

*Закирова М.Н., Ибраһимова А.А., Хаҗиева Ә.Х.* Бәйрәкә. Кайтарылган тарих (беренче өлеш). Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2022. Б. 456.

*Закирова М.Н., Ибраһимова А.А., Хаҗиева Ә.Х.* Бәйрәкә. Кайтарылган тарих (икенче өлеш). Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2022. Б. 408.

*Фәхретдинов Ризаэддин.* Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. Б. 22–23.

***Усманов Венер Мөдәррис улы,***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 82.09

*И.Л. Данилова*

# ФӘНГӘ ФИДАКЯР ХЕЗМӘТ
## (галим Й.Г. Нигъмәтуллинаның тууына 95 ел тулу уңаеннан)

В данной статье показан огромный вклад в науку, особенно в филологию и культурологию, заслуженного профессора КФУ, заслуженного деятеля науки ТАССР и РСФСР Ю.Г. Нигматуллиной. В её трудах разработаны теоретические и методологические основы системного комплексного изучения художественного творчества, прогнозирования художественной культуры и синэргетического подхода к изучению «срединной культуры». Прослежено последовательное развитие её теории стохастических процессов в разных изучаемых явлениях от литературного произведения до диалога культур в рамках цивилизационных изменений. Большого внимания заслуживают её теория диалогических отношений и функциональных связей в процессе развития культуры, а также отношения типов культур и цивилизаций в истории культуры.

**Ключевые слова:** методология литературоведения и культурологии, системное комплексное изучение художественного творчества, диалогические и функциональные отношения в культуре, типы культуры и типы цивилизаций, синергетический подход в литературоведении, прогнозирование литературы и искусства, стохастические процессы в культуре, «срединная культура» как гармонизирующий фактор.

This article shows the great contribution to science, especially to philology and cultural studies, by Honored Professor of KFU, Honored Scientist of the TASSR and RSFSR Yu.G. Nigmatullina. Her works developed the theoretical and methodological basis for a systemic comprehensive study of artistical creativity, forecasting artistical culture and a synergetic approach to the study of the «middle culture». The consistent development of her theory of stochastic processes in various studied phenomena from a literary work to the dialogue of cultures within the framework of civilizational changes is traced. Her theory of dialogic relationships and functional connections in the process of cultural development, as well as the relationship between types of cultures and civilizations in the history of culture, deserves great attention.

**Keywords:** methodology of literary analysis and cultural studies, systematic comprehensive study of artistic creativity, dialogic and functional relationships in culture, types of culture and types of civilizations, synergetic approach in literary criticism, forecasting literature and art, stochastic processes in culture, «middle culture» as a harmonizing factor.

Быел бөек галим, филолог һәм культуролог, КФУның атказанган профессоры, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе Й.Г. Нигъмәтуллинаның тууына 95 ел тула. Ул сәнгати иҗатны системалы һәм комплекслы өйрәнү, сәнгати мәдәният үсешенә прогноз бирү һәм «урта мәдәният» процессларын өйрәнүгә синергетик якын килү методологиясен булдырды.

Йолдыз Галимҗан кызы шәхес буларак фәннең асылына төшенүдә, сәнгать һәм мәдәният кыйммәтләрен танып белүдә бөтен күңелен салып эшләде, аларның хәзерге заман белән бәйләнешләрен, шулай ук тарихи перспективада киләчәккә хәрәкәтен тирәнтен аңлап эш итте. Шуңа күрә башка тикшерүчеләр күрмәгән (бәлки күргән), әмма кызыклы итеп аңлата алмаган күренешләр аның өчен аермачык күренде. Гайре табигый эрудициягә ия булуы, дөньяга карашының гаҗәеп киңлеге һәм югарыдан бирелгән иҗат ялкыны аңа гуманитар фәннәр өлкәсендә акрынлап яңа горизонтлар ачарга мөмкинлек бирде.

Әгәр дә хәзер без ул теоретик һәм методологик яктан эшләп калдырган һәм формалаштырган проблемаларны эзлекле рәвештә санап чыксак, шулай ук ирешелгән практик нәтиҗәләрне дә исәпкә алсак, сәнгати һәм мәдәни процессларның универсаль кануннарын тирәнтенрәк аңлый башларбыз. Ул бу юлны ачык күргән, үзенең шәкертләрен һәм дәвамчыларын шул юлдан алып барган.

«Национальное своеобразие эстетического идеала» дип исемләнгән докторлык диссертациясе аның бөтен фәнни эшчәнлегенең чишмә башы һәм башлангычы булып тора. Бу хезмәттә сәнгати иҗатта гамәлгә ашырылган универсаль модель буларак эстетик идеалны системалы һәм процессуаль өйрәнү проблемасы ачык һәм кыю итеп куелган. Бу модельнең эчтәлеге һәм функцияләре милли чынбарлык һәм сәнгатькярнең иҗади йөзе, милли яшәешнең гомумкешелек эчтәлеге һәм кешенең индивидуаль фикерләү үзенчәлекләре белән билгеләнә [Нигматуллина, 1970]. «Эстетический идеал, формируясь, воздействует на художественное мышление писателя, воздействуя, формируется вновь и вновь в каждом творческом акте создания художественного произведения, сохраняя, однако, свою структуру», – дип яза Й.Г. Нигматуллина [Нигматуллина, 1971, с. 3]. Бу хезмәтендә Йолдыз Галимҗан кызы тикшерену предметын үсештә үзенчәлекле, күпкырлы итеп күрү принципларын ачкан. Алар аның үзе һәм эшен дәвам итүче галимнәр тарафыннан уртак коллектив хезмәтләрдә алга таба да кулланылыш тапкан.

1970 елларда әдәбият, сәнгать һәм сәнгати иҗат комплекслы өйрәнелә башлады. Нәтиҗәдә, «өйрәнү объектының, әйтик, әдәбиятта синкретизм күренешләре, сәнгатьләрнең үзара бәйләнеше һәм синтезының структур яктан катлаулы булуын» аңлый башладык [Нигматуллина, 1980, с. 5]. Аларны өйрәнүнең философия, системалар теориясе, кибернетика, психология, сәнгать белеме ысулларын синтезлауга нигезләнгән комплекслы методологиясен булдырырга кирәк иде. Методлар синтезы системалы методологиягә, фәнни дисциплиналар иерархиясен аңлауга таяна.

1979 елның апрелендә Казан университеты каршында СССР Фәннәр академиясе комиссиясенең Казан базасы төркеме расланды, аңа КДУ, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, КАИ (СКБ «Прометей»), КДПИ, Мәдәният институты фәнни хезмәткәрләре,

укытучылары һәм аспирантлары, шулай ук язучылар һәм тәнкыйтьчеләр (барлыгы 40 ка якын кеше) керде. Профессор Й.Г. Нигъмәтуллина әлеге фәнни берләшмәнең җитәкчесе иде. СССРда гуманитар фәнне үстерү, тарихи перспективада глобаль проблемаларны хәл итү өчен әлеге юнәлешнең масштаблылыгын һәм зарурилыгын ассызыклау таләп ителде.

СССР Фәннәр академиясенең Дөнья мәдәнияте тарихы буенча фәнни советы басмалары да комплекслы методологияне үстерүнең актуальлеген раслый [Содружество наук..., 1968; Психология процессов..., 1980; Художественное творчество..., 1983]. Ул вакытта, комплекслылык дигәндә, философлар, тарихчылар, әдәбиятчылар, психологлар, лингвистларның тырышлыкларын берләштерү күздә тотылды. Әмма Й.Г. Нигъмәтуллина уртак эшкә математикларны, физикларны, социологларны, шулай ук системалар теориясе буенча белгечләрне һәм кибернетикларны да җәлеп итте. Шуңа күрә аның җитәкчелегендәге Казан юнәлеше әдәбият үсешенә прогноз бирү проблемаларын синергетиканы эшкә җигеп [Нигматуллина, 1984; 1988; 1990; 2008], ә аннары «урта мәдәният»не структур һәм процессуаль аспектларда тикшерү аша сәнгати мәдәнияттәге катлаулы процессларны өйрәнүгә [Нигматуллина, 2008; 2011; 2013; 2019] күчеп, зур нәтиҗәләргә иреште.

Ул тәкъдим иткән анализ методологиясе сәнгать үсеше закончалыкларын һәм детальләрен ихтимал тотылган модельләштерү нигезендә мәдәни процессның гомум хәрәкәте контекстында өйрәнергә мөмкинлек бирә [Нигматуллина, 1983; 1984]. «Методология комплексного изучения художественного творчества» дигән икенче китабында Йолдыз Галимҗан кызы матур әдәбиятка прогноз бирүнең ике аспектын аерып күрсәтә [Нигматуллина, 1983, с. 65–69]. Беренчесе – башка функцияләр системасында әдәбиятның прогноз бирү функциясен өйрәнү, икенчесе – өстенлекле структура – эстетик идеалны аерып чыгару нигезендә сәнгать үсешен фаразлау. Беренче аспектта эстетик идеал матур әдәбият әсәренең структура ясагыч принцибын тәшкил итә, икенче аспектта язучы – әсәр – укучы системасын оештыра. «Являясь высшим критерием идейной и эстетической оценки действительности, эстетический идеал содержит в своей структуре представление о родовой мере вещей. В рамках этой меры и осуществляется прогноз в художественной литературе» [Нигматуллина, 1983, с. 68].

1983 елның маенда «Әдәбиятта һәм сәнгатьтә сәнгатьлелек критерие» дип аталган фәнни конференциядә сәнгать әсәренең *ихтимал тотылу табигатен* прогнозлау һәм өйрәнү проблемасы көн тәртибеннән алына. Бу – уртак эштә аеруча мөһим вакыйга булып тора. Әлеге конференциянең максаты төрле югары уку йортлары галимнәре өчен сәнгатьне күп функциялелеккә ия һәм диалог процессында тормышка ашырыла торган катлаулы система буларак өйрәнү концепциясен эшләүдән гыйбарәт иде. Сәнгатьлелек критерие эстетик

идеалны тормышка ашыру, әсәрне оештыруның системалы принцибы буларак, шулай ук аның «потенциаль эчтәлеген» тудыручы һәм укучы буыннар диалогында «сәнгать әсәренең ихтимал тотылган табигатен» булдыручы ихтимал тотылган процесс итеп каралган [Нигматуллина, 1984, с. 6–7]. Эстетик идеалның ролен аңлауда яңалык әнә шул булды. Теоретик мәсьәләнең катлаулы булуы барлык катнашучыларның докладларына карата зур кызыксыну уятты. Чөнки аларда фольклор, әдәбият, сынлы һәм гамәли сәнгать, музыка, театрдагы сәнгатьлелек һәм диалогик мөнәсәбәтләргә хас төрлелек чагылыш тапкан иде. Мөгаен, чын мәгънәсендә алга китеш һәм катлаулы проблематикага күчеш (1990 елларда әлеге юнәлеш җитәкчесенең хезмәтләре шуңа багышлана) шул вакытта булгандыр. Сәнгати үсешкә тарихи-типологик һәм тарихи-функциональ якын килүләрне берләштерү, сәнгать әсәрен диалогик планда аңлау, аның бүгенге укучыга гына түгел, ә киләчәккә юнәлгәнлеген өйрәнү математик ихтимал тотылганлык теориясен һәм ихтимал тотылган анализ ысулларын куллануга (мәсәлән, прогноз модельләрен төзүгә) сәбәп булды. Шулай итеп, мәдәниятнең интегратив көчләрен өйрәнүнең төп шарты барлыкка килде.

Системалы анализ методологиясенә багышланган өченче китабында («Комплексное исследование художественного творчества») [Нигматуллина, 1990] Йолдыз Галимҗан кызы прогноз бирү проблемалары өстендәге унъеллык эш тәҗрибәсен гомумиләштерде һәм аерым әсәрне дә, аерым язучы иҗатын да, фольклор, әдәбият һәм башка сәнгать төрләренең жанр һәм стиль үсешен дә фараз итеп анализлауның конкрет юлларын һәм ысулларын күрсәтте [Нигматуллина, 1990, с. 58–59, 134]. Китапта әсәр системасындагы эчке трансформацияләрнең төрле вариантлары прогнозлы картографияләү ысулы нигезендә карала. Й.Г. Нигъмәтуллина раславынча, теләсә нинди сәнгати системаның эчке хәрәкәтчәнлеге ихтимал тотылган үзгәреш параметрларына һәм тәртип параметрларына ия, анда «бердәм нигезне, әһәмиятле үзгәрүчәнлек инвариантын» табарга кирәк, аңа таянып, әдәбият һәм башка сәнгать процесслары турында фараз кылырга мөмкин [Нигматуллина, 1990, с. 138].

Методология үсешенең һәр этабы бик тә мөһим һәм кирәкле була, акрынлап эзлекле рәвештә сәнгати процесс үсешен яңача аңлауның нигез ташлары салына.

Бу вакытта ил тормышында зур социаль борылыш күзәтелә. Прогноз бирү проблемаларына мөнәсәбәт үзгәрәме соң? Бу – әлеге юнәлештә эшләгән һәркемнең тормышында бик авыр чор була. Коллектив монография авторларының күбесе үзара хезмәттәшлек итүдән баш тарта һәм мөстәкыйль эшләүгә өстенлек бирә. Әмма социаль системада 1990 еллар башында күзәтелгән җитди үзгәрешләр әдәбиятка һәм сәнгатькә прогноз аша якын килүнең дөрес булуын исбатлый, алар аны кире какмый. Социум, ягъни «прогнозлау фоны» үзгәрә, ә классик әдәбият әсәрләренең системалы бердәмлеге һәм аларны укуда «мөмкинлекләр җилпәзәсе», эстетик идеалның киләчәккә

юнәлгәнлеге, киресенчә, әле оешмаган, билгесез, социаль чынбарлык фонында ачыграк кабул ителә башлый. Әдәби процесс катлаулана, нәкышь теле үзгәрә. Проза, поэзия һәм драматургиядә барлыкка килгән постмодернистик әсәрләр җәмгыятьнең җимерелүе турындагы реалистик һәм хәтта натуралистик очерклар һәм драмалар белән тигезләшә, күңел ачуга корылган бульвар әдәбияты агымы билгеләнә, балалар өчен басмалар күбәя. 2000 еллар башына кадәр әдәби процесс акрынлап катлаулана һәм байый бара, ә әдәбият һәм сәнгать белемнәрендә, сәнгати мәдәниятне өйрәнүдә ихтимал тотылган прогноз бирү ысулларын куллану актуальлеген югалтмый, дип әйтә алабыз. Йолдыз Галимҗан кызы сүзләре белән әйткәндә, тупланган белемнәр безнең һөнәри тәҗрибәгә «рәсемгә төшерелеп», аналитик инвариантлар сыйфатында компактлы рәвештә килеп керде һәм алга таба тикшеренүләрдә файдаланылды.

2004 елда Й.Г. Нигъмәтуллина юнәлеш тарихына багышланган китапта сәнгати иҗатны системалы, комплекслы тикшерү тәҗрибәсен гомумиләштергәннән соң, тормыш бер урында гына тормаганлыктан, тукталып калырга ярамавын исбатлый. Теоретик һәм методологик яктан гомумиләштерүнең яңа дәрәҗәсенә күтәрелүдә чираттагы адым синергетикага күчүдән гыйбарәт була.

Йолдыз Галимҗан кызы прогнозлау объектларын синергетик аспектта карауның мөмкин булган перспективасы турында алданрак – 1990 елда язган иде: «При изучении качественного скачка (в процессе развития сложной системы) важно уточнение самого «механизма» перехода детерминированного процесса в вероятностный и обратно – рождение из неопределённости новой меры. Стремление решить этот вопрос вызвало к жизни ряд новых научных дисциплин – теорию катастроф и синергетику. … В синергетике акцент сделан на роль управляющих параметров в качественных изменениях» [Нигматуллина, 1990, с. 129, 131]. Синергетика сәнгатьтә һәм мәдәнияттә үзлегеннән оештыру һәм үзлегеннән үсеш проблемаларын карауны, синергетик аспектны кулланудан сәнгать әсәренең күп дәрәҗәле системасына таба баруны, әдәби жанрлар һәм сәнгать төрләренең үзара тәэсир итешү системасында сыйфат үзгәрешләре инвариантларын эзләүне аңлата [Нигматуллина, 1990, с. 127–135]. Ул цивилизацияләрнең үзгәрүенә бәйле рәвештә, мантыйкка таянып, әдәбият үсешен һәм аларны китереп чыгарган мәдәниятләрне өйрәнүгә һәм чагыштыруга күчә.

«Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур» [Нигматуллина, 1996] дигән җентекле хезмәтендә Й.Г. Нигъмәтуллина әдәби үсешнең катлаулы, аңлашылмаучан, каршылыклар һәм парадокслар белән тулы процессларын зур үлчәмнәр – «фикерләү тибы», «мәдәният тибы», «цивилизация тибы» категорияләре призмасы аша анализлый. Бу категорияләр әдәби һәм мәдәни үсешнең үзлегеннән оешу системасында «тәртип параметрларын» билгеләүче детерминантлар буларак карала.

Әдәби әсәрләр һәм хәтта татар һәм рус әдәбиятындагы жанр үзгәрешләре «азатлык элементлары» итеп карала, алар төрле һәм чагыштырмаслык булып күренә. Әмма алар гомуми процесска һәм тигезсез үсешкә ия цивилизацион процесс мизгелләре буларак кертелгән. Ләкин мондый күренешләрне охшаш булмаганнарда күрү һәм гомуми процессның мантыйгын ачу күпкә кызыклырак. Мәсәлән, китап авторы төрле милли әдәбиятларның үсеш үзенчәлекләрен күрсәтеп, төрле вакытта мәдәниятнең яңа төренә күчешләрне чагыштыра. XVIII гасыр рус классицизмында (ул әсәрләрдә ныклы мантыйкка корылган бәйләнешләргә омтылган синтаксик мәдәният төренә керә) милли әдәбият формалашу этабында мәдәниятне европалаштыруга күчеш күзәтелә. Тарихка мөрәҗәгать итү һәм традициягә кушылу зур кыйммәт санала, трагедия жанры «монументаль-тарихи стиль» традициясенә кушылып тирәнәя, шуның белән авторлар жанрның максималь яңгырашына ирешәләр [Нигматуллина, 1990, с. 100]. XIX гасыр башында татар әдәбиятында да эстетик аңны европалаштыруга күчеш күзәтелә, әмма бу синтаксик мәдәният тибына түгел, ә капма-каршы асемантик һәм асинтаксик типка күчү була, һәм бу аерым язучыларның эстетик аңы үзгәрүгә йогынты ясый [Нигматуллина, 1990, с. 101]. Кешенең табигый, антропологик асылы төп кыйммәт булып кала. Шуңа күрә бу күчеш парадокс аша гамәлгә ашырыла: татар әдәбиятында мәгърифәтчелек идеаллары мөселман мәдәнияте традицияләре белән органик рәвештә кушыла [Нигматуллина, 1990, с. 102]. Охшаш күренешләрнең синхрон булмаган үсешен анализлау үрнәге әдәбият тарихында калыплашкан карашларның кыю рәвештә яңадан каралуы турында сөйли. Шул рәвешле, монография авторы IX гасырдан алып XX гасырга кадәр татар һәм рус әдәбияты үсешенең биш этабын, алар арасындагы бәйләнешне күрсәтә. Һәр аерым бүлектә этап үзенчәлекләрен билгеләгән мәдәният параметрлары карала. Нәтиҗәдә, милли әдәбиятларның конкрет юллары билгеләнеп, бердәм үсеш процессының катлаулы картинасы барлыкка килә.

Системалы-комплекслы юнәлеш тарихында бу тарихи-типологик тикшеренүнең нәтиҗәләре турында Й.Г. Нигъмәтуллина болай дип яза: «На основе рассмотренного материала сделаны выводы о том, что типы культур татарской и русской литератур совпадали в периоды Волжской Булгарии и Киевской Руси (переходный тип культуры); на всех этапах средневековья (семантико-синтаксический тип культуры) и в литературе социалистического реализма. На других же этапах – этапе становления национальной литературы (в XVIII веке русской, в XIX веке татарской), а также в начале XX века по типу культуры татарская и русская литературы значительно расходились [Нигматуллина, 2004, с. 157]. Мәдәниятләрнең төрләре туры килгәндә, үсеш процесслары охшаш булган, әмма алар аерымланса, һәр әдәбият үзенең кабатланмас юлын эзләгән. Димәк, монографиядә татар әдәбиятының рус әдәбияты белән диалогта объектив үсеш процессы яктыртылган.

Монографиянең прогнозлы анализ тәҗрибәсенә таянган методологиясе, процессның системалы бәйләнешләрен һәм яшерен тенденцияләрен күрергә мөмкинлек биреп, компаративистика мөмкинлекләрен шактый киңәйтә.

Й.Г. Нигъмәтуллинаның татар әдәбияты һәм нәкышендәге модернизм һәм авангардизмга багышланган ике монографиясе аеруча игътибарга лаек. Алар элеккеге эшләрнең катлаулы методологик нигезләре белән бәйләнмәгән дә кебек, әмма, һичшиксез, «урта мәдәният» проблемасы белән бәйле тикшеренүләрнең чираттагы этабына әзерлекне тәэмин итәләр.

«Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве» [Нигматуллина, 2002] монографиясендә Россия һәм Көнбатыш Европа мәдәниятләре диалогы фонында Татарстан язучылары һәм рәссамнарының модернистик сәнгате телен формалаштыру процессы күзәтелә. Автор әлеге сәнгати күренешнең табигатен аңлау максатын куя: «Запоздалым он воспринимается потому, что полнокровное его развитие в татарском искусстве происходит лишь в 1970–1980-е годы, хотя возник он ещё в начале XX века (символизм Дардменда, Х. Такташа, футуризм А.Кутуя, имажинизм К. Наджми; модернистские тенденции в живописи Б. Урманче, Ф. Тагирова), «блеснул» на миг, не успев оформиться как автономное художественное течение, обладающее самостоятельной эстетической ценностью…» [Нигматуллина, 2002, с. 13–15]. XX гасыр башында «ялтыраган модернизм очкыны» һәм аның 1970 еллар ахырындагы нык үсеш алган формасы арасындагы бәйләнешне Й.Г. Нигъмәтуллина «идеяләр романтизмы»ның мәдәни парадигмасы белән бәйли, аның оригинальлеге һәм катлаулылыгы «Типы культур и цивилизаций…» монографиясендә бәян итәлә [Нигматуллина, 1996, с. 110, 123]. Автор фикеренчә, «Романтизм идей» возрождается в конце XX века с доминированием философского содержания и стимулирует подъём «национального самосознания в духе новых требований эпохи» [Нигматуллина, 2002, с. 15]. Монографиядә модернистик тенденцияләрнең оригинальлеге генә түгел, ә милли мәдәният формалашу процессындагы әһәмияте дә ассызыклана.

Татар әдәбиятында һәм нәкышендә «соңга калган модернизм»ның фәлсәфи эчтәлеге этник үзбилгеләнү процессында милли тарих һәм мәдәниятне яңадан төшенү белән бәйле: «не менее важную роль играет и желание понять место своего народа в общей истории человечества, а также ответить на глобальные вопросы: человек и история, человек и космос, цивилизация и природа, цивилизация и духовная жизнь общества и т.д.» [Нигматуллина, 2002, с. 15]. XX гасыр рус һәм Европа модернистик сәнгатенең семиотик системасы белән чагыштыру өчен «гомуми нигез» барлыкка китереп, Йолдыз Галимҗан кызы татар мәдәниятендә бу проблемаларны аңлау үзенчәлеген семиотик планда күрсәтә. Модернизмда нәкышь һәм әдәбият теле абстрактлаша, универсальлеккә омтыла, кешелек сәнгате теле булып

эверелә һәм шуңа күрә борынгы лабиринт һәм арабеска символларын үзләштерә, борынгы һәм хәзерге фикерләүне бәйләүче, шулай ук Җирдә кешенең антропологик яшәү мәгънәсен тапшыручы архетип һәм мифологемалардан файдалана [Нигматуллина, 2002, с. 90–110].

Автор нәкышь һәм әдәбиятның сәнгати теле аермалары проблемасын Ю.М. Лотманның семиотик эквивалентлар теориясе нигезендә хәл итә. Шуңа охшаш фәлсәфи позицияләр сүзтамга һәм символларны текстта үтәли эзлеклелектә кулланган әдәбияттагыча түгел, ә бәлки нәкышьнең «дискрет булмаган» пространство телендә башкача чагылдырыла. Аларда эчтәлек төрлечә тапшырыла, дөнья төрлечә модельләштерелә, әмма чын кеше кичерешләре һәм дөньяны аңлау мәдәният хәтерендә сакланган эчке тәрҗемәләр системасына таяна [Нигматуллина, 2002, с. 111–112]. Шуның нигезендә мәгънәләрне тәрҗемә итү өчен нәкышь һәм әдәбият арасында эквивалентлар эзләү китә.

Й.Г. Нигъмәтуллина яңа сәнгати тел формалаштыру процессының, Татарстан рәссамнары һәм язучылары яклаган әхлакый һәм эстетик кыйммәтләрнең бердәмлеген исбатлады. Европа һәм рус сәнгатеннән аермалы буларак, биредә модернистик стильләр реализм белән синтезлана. Синтез процессында татар милли традицияләренә хас стильләр яки стиль тенденцияләре өстенлек итә: келәм туку, халык уенчыклары, шәмаил сәнгатендәге садәлек, декоративизм традицияләре, шулай ук реаль дөнья күренешләре һәм предметларының илаһи нурланышы турындагы мөселман сәнгате идеяләре [Нигматуллина, 2002, с. 160]. Шул ук вакытта модернизм белән бәйле һәм Европа сәнгатендә зур әһәмияткә ия булган постмодернизм татар сәнгатендә фрагментар рәвештә, «аерым алымнар дәрәҗәсендә» генә чагылыш таба [Нигматуллина, 2002, с. 163].

«Запоздалый модернизм» монографиясе татар әдәбияты һәм сәнгатендә зур әһәмияткә ия була, чөнки өйрәнелә торган процесс XXI гасыр дөнья мәдәниятендәге глобаль үзгәрешләр күзлегеннән «әдәбият һәм сәнгать эволюциясе алгоритмнары алышыну» контекстында карала. Бу үзгәрешләр исә әлеге алгоритмнарның Шәрык һәм Гареб мәдәниятләре диалогына яңа яссылыкта кертелүгә бәйле.

Алдагы, күләме буенча зур булмаган «ТатАвангард и современный цивилизационный процесс» [Нигматуллина, 2011] хезмәтендә Й.Г. Нигъмәтуллина дөньяга яңа караш һәм яңа нәкышь теле барлыкка килү процессында иҗади шәхес һәм рәссам индивидуальлегенең ролен ассызыклый.

Йолдыз Галимҗан кызы тарафыннан эшләнгән концепция буенча, мәдәни һәм цивилизацион үсеш процесслары бер-берсенә туры килми. «Типы культур и цивилизаций…» [Нигматуллина, 1996] монографиясендә дәлилләнгәнчә, бер цивилизация эчендә берничә мәдәният төре бергә яши ала. Бу фикер хәзерге динамик цивилизацияне аңлау өчен аеруча актуаль. Цивилизация локаль мәдәниятләрнең төп (адаптив һәм иҗади) функцияләре туры килү аркасында

тотрыклылыгын саклый. Шулай да һәр мәдәният, үзлегеннән оешкан катлаулы система буларак, шактый дәрәҗәдә билгесез һәм тотрыксыз була. Мәдәниятне нинди эчке процесс тотрыклы итә соң? Й.Г. Нигъмәтуллина фаразлавынча, бу – «урта мәдәният». Терминны фәнгә, мәдәниятнең үзәк зонасын билгеләү өчен, үзенең «Цивилизации. Универсалии и самобытность» (М.: Наука, 2002) китабында Б.С. Ерасов кертә. Үзәк зона төп кыйммәтләрне саклый һәм мәдәни конфликтларга китерә торган чик-каршылыкларны юкка чыгара, әмма «урта мәдәният» семиотик система буларак аңланган мәдәниятнең үзәге белән туры килми. «Урта мәдәният» мәдәни традицияләрнең гомумкешелек кыйммәтләре нигезен сакларга һәм интеграцияләргә ярдәм итә һәм «тәртип параметры» да булып тора.

«ТатАвангард и современный цивилизационный процесс» китабында автор XXI гасыр башында Татарстанда «урта мәдәният» функциясен авангардчы рәссамнар һәм аларның «Тамга», «Чыңгызхан» кебек иҗади берләшмәләре башкарган, дигән гипотезаны алга куя. Рәссамнар мифологик тамырлы милли сәнгать кодларын кулланып, яңа сәнгать теле тудыралар, хат-төргәкләрдә («Хәбәр») идеяне образлы чагылдыруның яңа формаларын булдыралар, вакытның борынгыдан бүгенгегә хәрәкәтен «Тәгәрмәч» арт-проектында гәүдәләндерәләр.

Җирдә кешелекнең иминлеге кебек глобаль проблемаларны чагылдырган, ТатАвангард рәссамнары иҗатында кабатланган инвариант темаларны аерып күрсәтү аларның хәзерге мәдәнияткә йогынтысы турында тулы картина булдырырга мөмкинлек бирде. Болар – яшәү мәгънәсе, дөньяда бердәмлек югалу; кешеләрнең эчке дөньясының чорлар бәйләнешен символлаштырган борынгы мифологик образлар белән бәйләнешы; кешенең галәм көченә төшенүе темалары.

Бу темаларның образлы чагылышы борынгы архетипларны куллану, мифларны аңлату, кеше һәм чиксез космос мөнәсәбәтләрен символик рәвештә гәүдәләндерү белән бәйле. Шәрык мәдәни кыйммәтләренең хәзерге цивилизация үсеше өчен зур әһәмияткә ия булуы турындагы аларны берләштерүче идея дә төрлечә белдерелгән.

Х. Шәрипов, М. Хаҗиев, В. Петров (Праски Витти), Х. Латыйпов, Н. Байбурин, Н. Латфуллин, И. Ханов, Л. Әхмәтов иҗатында сәнгать теленә һәм дөньяны индивидуаль күзаллауга җентекле анализ төрле-төрле сәнгати ачышларның бинаһая зур картинасын тудыра, шул ук вакытта «урта мәдәният» күренешенең аерым катлаулылыгын, күпкырлылыгын ача. Бу очракта соңгысы этник кабатланмаучанлык һәм халык сәнгате хәтере үзенчәлекләрен саклаган Евразия үзаңы үзенчәлекләрен гәүдәләндерә. Й.Г. Нигъмәтуллина ТатАвангард сәнгатенең «урта мәдәният» составында актив эшләвен оста күрсәтә, чөнки бу сәнгать дөньяның яңартылган картинасын цивилизация үсешенең бер өлеше буларак аңлауны стимуллаштыруда зур гомумиләштерү көченә ия.

«Урта мәдәният»не алга таба да аерым рәссамнар иҗаты аша борынгыдан алып безнең көннәргә килеп җиткән традицияләрнең

төрле вакыт катламнарын берләштергән, дөньяда яшәгән төрле халыкларның образлы күзаллауларын үзләштергән, сәнгать телен оештырган, үзлегеннән идарә ителгән процесс буларак аңлау өчен бу тикшеренүнең әһәмияте гаять зур булган. Бу процессның киләчәккә юнәлдерелгәнлеге һәм үсеш потенциалына ия булуы бик яхшы билгеләнгән.

«Урта мәдәният»нең структур үзенчәлекләре һәм процессуальлеге проблемалары өстендә эшне дәвам иттерү нәтиҗәсендә бу категориянең төрле төр һәм жанрларның, шулай ук бердәм мәдәният системасында әдәбият һәм сәнгатькә хас вакыт катламнарының ролен яңача күрергә мөмкин булган. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве» монографиясе концепциясендә Й.Г. Нигъмәтуллина XX гасыр дәвамында «семиосферада» әдәбият һәм сәнгать телләренең үзара бәйләнешен күрсәтү өчен мәдәнияттә үзәк һәм периферия мөнәсәбәтләренең семиотик теориясен нигезле куллана [Нигматуллина, 2002, с. 16, 111–112]. Ләкин мәдәни кыйммәтләрнең югала баруына, юкка чыгуына каршы торырлык көч бармы? дигән сорау ачык кала.

Йолдыз Галимҗан кызы фикеренчә (ул төрле сәнгать төрләрендә «урта мәдәният»нең чагылышы турында беренче коллектив җыентыкта урын алган «Культура как примиритель» мәкаләсендә белдерелгән), «урта мәдәният»нең йогынтысы үсеш процессында каршылыкларны «алып ташлауга» (Гегель буенча), яки каршылыкларны «саклауга» (философ Нисида Китаро буенча) нигезләнгән һәм бу процессларны бергә карарга кирәк [Нигматуллина, 2013, с. 12–14]. «В обоих вариантах речь идёт о развитии на основе противоречий и о развитии новых качеств. По «западному» варианту феномен эмерджентности (переход в новое качество) возникает за счёт актуализации потенциального содержания предыдущего состояния системы в процессе «отрицания отрицания», по «восточному» – в результате включённости явления в систему универсального взаимодействия между отдельным и общим» [Нигматуллина, 2013, с. 14]. Әлеге функцияләр ярдәмендә «урта мәдәният», мәдәният хаоска тартылганда, тәртип параметрларын «кертә, шул ук вакытта Й.Г. Нигъмәтуллина аны мәдәниятне синергетик аспектта тикшергәндә «сәер аттрактор» буларак карый [Нигматуллина, 2013, с. 18]. Мәдәни үсешнең катлаулы процессларын синергетик аспектта ничек тикшерергә, шулай ук әдәби әсәрләрне өйрәнү мөмкинлекләрен ничек анализларга? Бу мәсьәләләр югарыда әйтелгән берничә хезмәттә күтәрелгән [Нигматуллина, 1988; 1990; 2008].

«Урта мәдәният»нең синтезлау роле үзенчәлекләрен өйрәнү әдәбият, театр, музыка белгечләренең «Между гармонией и дисгармонией» җыентыгына кертелгән мәкаләләрендә, рәссамнарның аерым чыгышларында билгеләнгән.

Алга таба Й.Г. Нигъмәтуллина инвариант төшенчәләр эзләүдә тагын да катлаулырак бурычлар куя. Алар ярдәмендә «урта мәдә-

ният» билгеләрен ачыклау һәм характерлап бирү, тану, башкача әйткәндә, фән дөньясына әлеге катлаулы күренешнең «визит карточкасы»н тәкъдим итү мөмкинлеге ачыла. Чираттагы мәкаләләр җыентыгының эчтәлеге «урталык» күренешенең эчке мантыйгы һәм структур инвариант буларак бинар һәм тринитар диалектика проблемалары тирәсендә формалаша. Әлеге идея Й.Г. Нигъмәтуллинаның «Срединная культура: диалог бинарного и тринитарного мышления» мәкаләсендә нигезләнә һәм үстерелә. «Урта мәдәният» логик-семантик аспектта карала, «мәгънә мантыйгы»ның төрле фәнни концепцияләре күзлегеннән мәгънә ясау тенденцияләре аерып чыгарыла [Нигматуллина, 2019, с. 3]. Бу фәндә яңа сүз, әле тәмамланмаган, әмма кызыклы перспективалы теориянең бер өлеше була.

«Урта мәдәният»нең яшерен механизмнарын өйрәнү һәм интегратив иҗат көче ярдәмендә кешелекне берләштерү өчен аның потенциаль мөмкинлекләрен ачыклау дәвам итәчәк, бу мәсьәлә беркайчан да актуальлеген югалтмаячак.

Йолдыз Галимҗан кызының фән юлы катлаулы һәм уникаль, бу юлда халыкара масштабта танылу алган галим шәхесенең бөтен катлаулылыгы һәм тиңдәшсезлеге чагыла. Компромиссызлык, үҗәтлек һәм фәнни даирәгә таләпчәнлеге, зур һәм кечкенә бәхәсләрдә гаделлеге аның фикерләү киңлеге белән бәйле. Галимә фәнни идеяләрне гадиләштерүгә һәм бозуга нык каршы тора. Фәндә шундый катгый, таләпчән булуы белән бергә ул бик тә кече күңелле, игелекле, кунакчыл, якты, ачык кеше иде. Аның исеме һәм шәхесе барлык дусларына, укучыларына, иҗат кешеләренә яктылык, өмет бүләк итә һәм максатчанлык үрнәге булып тора иде.

КФУның атказанган профессоры, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе Й.Г. Нигъмәтуллинаның үзе тарафыннан төзелгән «Путь научных поисков» дип исемләнгән фәнни басмалары исемлегендә 75 хезмәт, шулай ук фәнгә кертkән өлеше турында 40 мәкалә һәм бәяләмә бар. Аның фикере һәрдаим киләчәккә юнәлтелгән һәм танып белү теориясенең вакыттан тыш үлчәмнәре белән тоташкан. Әгәр без Йолдыз Галимҗан кызы Нигъмәтуллина сызган юлдан баруыбызны дәвам итсәк, ул һәрчак безнең арада булыр.

**Әдәбият**

*Нигматуллина Ю.Г.* Национальное своеобразие эстетического идеала. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970. 210 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* Национальное своеобразие эстетического идеала: автореф. дис. ... д-ра филол. наук (10.647 – теория литературы). Баку, 1971. 48 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* Методология комплексного изучения художественного произведения. Ч. 1. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1976. 108 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* Комплексный метод и проблема прогнозирования // Проблема комплексности изучения художественного творчества: доклады Межвузовской науч. конф., проведенной Казанской базовой группой Комиссии комплексного изучения художественного творчества Научного совета по истории мировой культуры АН СССР 14–16 мая 1980 г. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1980. С. 4–13.

*Нигматуллина Ю.Г.* Методология комплексного изучения художественного творчества. Ч. 2. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1983. 104 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* Вероятностное моделирование в художественном творчестве и критерии художественности в литературе, искусстве (В свете содружества наук) // Критерий художественности в литературе и искусстве / науч. редактор Ю.Г. Нигматуллина. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1984. С. 3–13.

*Нигматуллина Ю.Г.* Критерии выбора методов прогнозирования // Поиск методов прогнозирования литературы и искусства / науч. ред. проф. Ю.Г. Нигматуллина. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. С. 7–25.

*Нигматуллина Ю.Г.* Комплексное исследование художественного творчества: проблемы прогнозирования. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990. 150 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1996. 191 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 175 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* Системно-комплексное исследование художественного творчества: История научного направления в Казанском университете. Казань: Фэн, 2004. 250 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* Синергетический аспект в исследовании художественного творчества. Казань: Фэн, 2008. 89 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* ТатАвангард и современный цивилизационный процесс. Казань: Фэн, 2011. 68 с.

*Нигматуллина Ю.Г.* Культура как примиритель. // Между дисгармонией и гармонией: Проблемы «срединной культуры» / науч. ред. проф. Ю.Г. Нигматуллина. Казань: Фэн, 2013. С. 3–35.

*Нигматуллина Ю.Г.* «Срединная культура»: Диалог бинарного и тринитарного мышления // Срединная культура. Горизонты исследования: аспекты и методы: сб. ст. / науч. ред. Ю.Г. Нигматуллина. М: Перо, 2019. С. 4–36.

Психология процессов художественного творчества: Материалы симпозиума по методологическим проблемам изучения процессов художественного творчества» / под ред. В.В. Иванова. Л: Наука, 1980.

Содружество наук и тайны творчества» / под ред. Б.С. Мейлаха. М.: Наука, 1968.

Художественное творчество: Вопросы комплексного изучения / под ред. Б.С. Мейлаха. Л.: Наука, 1983.

***Данилова Ирина Леонидовна,***
*филология фәннәре докторы,*
*Гётеборг университеты, Телләр һәм әдәбиятлар*
*институты (Швеция)*

УДК 821.512.145

***Ф.И. Габидуллина***

# ГАЛИМНӘР ОСТАЗЫ
## (Флүн Мусинның тууына 85 ел тулу уңаеннан)

Статья посвящена научной деятельности известного литературоведа Ф.М. Мусина в области татарского литературоведения. Выявляются его первые шаги в мире науки, определяются основные направления исследований. Основное внимание уделяется созданию учёным собственной научной школы, на основе исследований своих наставников, разработке научной методологии и достижениям в этой области. Также отмечаются роль Ф. Мусина в изучении наследия татарских классиков Г. Исхаки и Г. Ибрагимова, его новаторство и значение его работ для развития отчественного литературоведения.

**Ключевые слова:** Ф. Мусин, татарское литературоведение, традиции, методология, научная школа, перспектива.

The article is devoted to the scientific activity of the famous literary critic F.M. Musin in the field of Tatar literary studies. The first steps in the world of science are revealed, the main directions of research are determined. The main focus is on the creation of scientists' own scientific school, based on the research of their mentors, the development of scientific methodology and achievements in this field. The role of F. Musin in the study of the heritage of the Tatar classics G. Iskhaki and G. Ibragimov, his innovation and the importance of his works for the development of patronymic literary criticism are also noted.

**Keywords:** F. Musin, Tatar literary criticism, traditions, methodology, scientific school, perspective.

Халкыбызның күпгасырлык тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү һәм кабат үзенә кайтару өлкәсендә эшләгән һәм эшләүче фидакяр галимнәребез шактый. Шулар арасында Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, профессор, күп кенә галимнәрнең остазы Ф.М. Мусинның (1939–2009) үз урыны бар.

Флүн Мослах улы Мусин 1939 елның 23 февралендә Мөслим районы Иске Карамалы авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Язмыш аңа тууга ук диярлек тормыш ачысын татыта башлый. 1941 елның җәендә аларның гаиләсе, бәхет эзләп, ерак Себергә юл ала. Әмма Чита шәһәренә барып җитәрәк, сугыш башланып китә. Сугышның беренче көннәрендә үк әтисе Мослахны армиягә алалар һәм ул су асты көймәсендә хезмәт иткәндә хәбәрсез югала. Моңа кадәр туган авылыннан башка җирне күрмәгән, русча бер авыз сүз белмәгән әнисе Мөсәвәрә исә ике яшь бала белән бөтенләй чит-ят җирдә торып кала. Сугыш мәхшәренең беренче айларында Себердә бер ярдәмчесез, ач-ялангач калган яшь ана кабат туган авылына кайтырга чыга. Бу юл бик озын һәм газаплы була. Авылга кайтып җиттеләр дигәндә, юлда күргән ачлык-газаплардан кечкенә кызчыгы дөнья куя. Бу авыр

сәяхәттән исән калса да, кечкенә Флүнгә сугыштан соңгы авылда күп кенә авырлыкларны тол әнисе белән бергә үз җилкәсендә күтәрергә туры килә. Балалык чоры ярым ач, язларын кырдан казып җыйган черегән бәрәңге һәм яшь кычыткан ашап уза. 1947 елда ул туган авылындагы башлангыч мәктәпкә укырга керә, бишенче сыйныфтан Күбәк урта мәктәбенә күчеп, аны 1957 елда тәмамлый. Шул ук елның җәендә, гади татар авылы баласы өчен кötелмәгән адым ясый: паспортсыз, поезд билетына көч-хәл белән акча юнәтеп, Мәскәүгә барып чыга. Кулында өлгергәнлек аттестаты – бер «дүртле», калганнары «бишле», документлар соңлап җибәрелгәнгә, медальсез дә кала. Шулай да ул яшьләргә хас үҗәтлек, күңел тулы хыяллар белән бөтен дөньяга шаулаган М.В. Ломоносов исемендәге университетның филология факультеты (гаять зур конкурс аша үтеп, 20 баллдан 19 ын җыеп) студенты булуга ирешә. Биш елдан «бик яхшы» билгеләренә генә университетны тәмамлый. Яшь белгечнең табигый сәләтен, гыйлемлелеген, тырышлыгын күреп, ул чор өчен түгел, бүгенге көн яшьләрен дә көнләштерерлек тәкъдимнәр була: беренчесе – берәр чит ил университетына укытучы булып бару, икенчесе – Мәскәү университетында аспирантурада калу. Яшь егет ике тәкъдимне дә кире кага. Күрәсең, Мәскәү университетындагы бөтен дөньядан җыелган студентлар дөньясында яшәү, танылган галимнәр белән аралашу нәтиҗәсендә авыл егетенең тормышка карашы шактый үзгәргән була. Туган җиренә якынрак булу, татар мәдәнияте өлкәсендә эшләү теләге дә йогынты ясагандыр, билгеле.

1962 елда, партия өлкә комитеты соравы буенча, Флүн Мусин эшкә Казанга җибәрелә. Башта «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли, аннары 1963 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына (хәзер ул Тел, әдәбият һәм сәнгать институты дип йөртелә) күчә һәм вафатына кадәр шунда хезмәт куя. 1970 елда Ф. Мусин филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсен ала, ә 1983 елда Мәскәүнең А.М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтында, татар әдәбиятчыларыннан беренче булып, докторлык диссертациясен яклый. 1991 елда аңа «Татарстан ССРның атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә, 1993 елда профессор була.

Әдәбиятыбыз тарихын җентекләп өйрәнү Флүн Мослах улы Мусинның халкыбызның күпгасырлык һәм күптөрле мирасы белән ныклабрак кызыксынуына сәбәп була. 1987 елда ул үз инициативасы белән оештырылган Рухи мирас комиссиясен җитәкли, ә 1991 елдан шушы комиссиянең вазифаларын үз өстенә алган Татар «Мирас» фондының президенты була, шул ук елны әлеге фонд оештырган «Мирас» журналының баш мөхәррире итеп сайлана. Узган гасырның 80 нче еллары ахырында җәмәгатьчелектә татар милләте яшәеше һәм язмышы мәсьәләсе алгы планга чыга. Милләтне яшәтүдә һәм үстерүдә рухи мирасның мөһим роль уйнавына таянып, Татар «Мирас» фонды, төрле илләргә сибелгән татарларны берләштерү

максатында, беренчеләрдән булып, матбугатта бөтендөнья татарлары корылтаен үткәрү мәсьәләсен күтәреп чыга. Шул уңайдан Ф. Мусин 1992 елда Бөтендөнья татар конгрессын әзерләү һәм үткәрү буенча Татарстан Республикасы премьер-министры җитәкчелегендәге оештыру комитеты составына кертелә, конгрессның үзендә аның Башкарма комитеты рәисе урынбасары итеп сайлана. Әлеге сыйфатта ул 1997 елда Икенче Бөтендөнья татар конгрессын әзерләү һәм үткәрүдә дә актив катнаша, аның яңа сайланган Башкарма комитетының бюро әгъзасы итеп раслана. Үзенең иҗтимагый-фәнни эшчәнлегендә галим татар дөньясында милли яңарыш хәрәкәтен идеологик яктан тәэмин итүгә аеруча игътибар бирә.

* * *

Флүн Мослах улы Мусин фәнни эшчәнлеген 1960 елларда әдәби тәнкыйтьтән башлый. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына күчкәч, ул әдәбият белгече сыйфатында татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә алына. Ике дистә елга якын Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеген җитәкләп, әдәби тарихны өйрәнүне оештыру эшләре белән дә шөгыльләнә. Әдәбиятыбызның үткәне һәм бүгенгесе турында 15 китап һәм 300 дән артык мәкалә авторы булу белән бергә, Флүн Мусин алты томлы «Татар әдәбияты тарихы»ның (бу тарихның XIX йөз һәм XX йөз башын колачлаган, 1917 елдан соң әдәбиятыбызның үткән юлын яктырткан коллектив хезмәтләрнең) төп авторларыннан һәм фәнни җитәкчеләреннән берсе булып тора.

Галимнең татар әдәбиятының төрле актуаль мәсьәләләренә, язучылар, бигрәк тә прозаиклар иҗатына һәм аларның аерым әсәрләренә багышланган тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләре Татарстанда гына түгел, үзәк матбугатта да даими дөнья күрә. Галим-тәнкыйтьченең әдәбият тарихын һәм җанлы әдәби процессны җентекләп өйрәнү-тикшерү нәтиҗәсендә язылган «Тормыш сынавы аша» (1969), «Тарих һәм заман» (1974), «По координатам жизни» (1976), «Связь времён» (1979), «Көмеш көзге» (1989), «Гаяз Исхакый: тормышы һәм эшчәнлеге» (1998) һ.б. татарча һәм русча китаплары XX гасыр татар прозасы проблемаларын, үсеш тенденцияләрен, үзенчәлекләрен, табыш һәм югалтуларын конкрет әсәрләр мисалында анализлаган җитди хезмәтләр итеп каралырга хаклы. Аларда галим, әдәбият фәне һәм бөтенсоюз әдәбияты ирешкән казанышлар югарылыгыннан торып, татар прозасының теге яисә бу чордагы хәленә күз ташлый, аның сан һәм сыйфат ягыннан үзгәрешләрен, тематикасын, жанр үзенчәлекләрен, аерым язучыларның керткән өлешен, яңалыгын тикшерә, бер үк вакытта әдәби традицияләрдән файдалану юллары, әдәби герой һәм чынбарлык, халыкчанлык, прозада документаль нигез, тарихилык, милли стиль, әдәбиятның публицистик пафосы кебек мөһим теоретик проблемалар турында сүз алып бара.

Әдәбият галиме фәнни-тәнкыйди эшчәнлегендә XX гасыр башы татар әдәбияты классиклары иҗатын өйрәнүгә аеруча җаваплы ка-

рый. Мәгълүм ки, 1980 еллар ахырыннан Татарстанда халкыбызның күпгасырлык тарихи-мәдәни мирасын бөтен барлыгында торгызу һәм фәнни өйрәнү эше башлана. Флүн Мусин – татар әдәбиятындагы «ак таплар»ны бетерүгә, исемнәре тыелган әдипләрнең бай мирасларын кайтаруга бөтен гомерен багышлаган галимнәребезнең берсе. Аеруча татар әдәбияты классигы, күренекле сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый иҗатын халыкка кайтаруда һәм фәнни өйрәнүдә башлап йөрүчеләрнең һәм әйдәп баручыларның берсе була. Г. Исхакый тормышы һәм эшчәнлеген тирәнтен өйрәнеп, 1998 елда «Гаяз Исхакый: тормышы һәм эшчәнлеге» монографиясен киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итә. М.Х. Хәсәнов фәнни мөхәррирлегендә дөнья күргән әлеге монографиядә Г. Исхакыйның тормышы һәм эшчәнлеге, иҗаты ике этапка бүлеп тикшерелә: «Туган илдә» һәм «Мөһаҗирлектә». Моннан тыш, җыентыкка Г. Исхакый турында әдәбият күрсәткече урнаштырылып, анда язучы иҗаты хакында 1988 елдан башлап матбугатта дөнья күргән материаллар хакында да мәгълүмат бирелә.

Монография әдипнең тормышын һәм күпкырлы эшчәнлеген шактый тулы колачлаган беренче хезмәт булуы белән дә кыйммәтле. Флүн Мослах улы классик әдип иҗатын фәнни өйрәнү мәсьәләсендә күпсанлы төрле дәрәҗәдәге конференцияләрне оештыручы һәм төп докладлар белән чыгыш ясаучы да була. Әдипнең тууына 130 ел тулуга багышлап үткәрелгән халыкара фәнни конференциядә (2008) «Гаяз Исхакый – милли идеолог һәм лидер» темасына ясаган докладында, Г. Исхакыйның узган гасыр татар дөньясындагы тарихи роле һәм урыны, аның киң планда милли идеолог һәм лидерга әверелүе белән бәйләнгән булуын ассызыклый һәм «...әдипнең мондый дәрәҗәгә әдәбият-сәнгать, иҗтимагый-сәяси, мәгариф, матбугат, фән һәм башка өлкәләрдәге идеяләре һәм аларны тормышка ашыруга юнәлтелгән эшчәнлеге белән ирешүен» [Мусин 2008, б. 13] билгели. Галим Г. Исхакый әсәрләренең төп мотивы халыкчылык булып, милләтне үстерү һәм саклауга юнәлтелгәнлеген дә искәртә. Гаяз Исхакый иҗатын төрле яссылыкта өйрәнүгә бәйле, Ф. Мусин җитәкчелегендә язылган дистәгә якын диссертация дә әдип иҗатын өйрәнүгә фидакярләрчә бирелгәнлеген дәлилли.

Флүн Мослах улы Гаяз Исхакый белән беррәттән татар әдәбияты классигы, энциклопедист-галим күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимовның (1887–1938) иҗади мирасын заман күзлегеннән карап өйрәнүгә дә зур көч куя. Әдип эшчәнлегенең төрле якларын колачлаган күпсанлы фәнни мәкаләләре, чыгышлары шуны дәлилли. Аның Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүгә багышланган фәнни мәкаләләренең берсе «Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүнең торышы һәм бурычлары» дип атала һәм язучының тууына 115 ел тулуга багышлап языла. Мәкаләдә галим Г. Ибраһимовны «...тарихның XX гасырга караган бик мөһим чорын танып-белүдә бу дәвердәге иң күренекле шәхесләребезнең берсе» [Мусин 2002, б. 12], дип бәяли һәм аның күпкырлы эшчәнлеген өйрәнүнең зур әһәмияткә ия булуын

ассызыклый. Классик язучы иҗатын дөнья әдәбияты биеклегеннән анализлап кына калмый, бәлки әдипкә мөнәсәбәтле кичектергесез хәл ителәсе мәсьәләләрне дә күтәрә. Галим фикеренчә, Г. Ибраһимов эшчәнлеге хакында докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре якланып, монографияләр, күпсанлы мәкаләләр язылган, иҗаты төрле яклап анализланып, төп сыйфатлары ачыкланган, әдәбиятыбыз тарихындагы урыны билгеләнгән. Шул ук вакытта автор соңгы елларда язучы иҗатының фән игътибарыннан читтәрәк калып килүенә тукталa һәм, классик фән позицияләреннән торып, татарның иҗтимагый-мәдәни фикер тарихын, аерым шәхесләрен яңача өйрәнү принципларын күрсәтә. Ни кызганыч, галим күтәргән әлеге проблеманың бүгенге көндә дә актуаль булып калуы күзәтелә.

Ф. Мусин Г. Ибраһимовның күпкырлы эшчәнлеген хәзерге карашлар рухында яңача өйрәнергә алынганда берничә мөһим мәсьәләне алга куя: иң әүвәл ул бу иҗатны фактик яктан тулырак белү кирәклеген ассызыклый. Мәгълүм ки, совет чорында ул вакыттагы идеологик карашлар бу мирасны бөтен барлыгында белергә мөмкинлек бирми, кайбер әсәрләре күләгәдә калдырыла. 1980 еллардан «ак тап» булып килгән шундый әсәрләреннән «Адәмнәр» повестена игътибар ителә башлый һәм ул әдәбият тарихына кайтарыла. Галим бик тирән мәгънәле бу әсәрнең әле фәнни тулы анализ һәм бәя алмавын билгели. Аның 20 нче еллар татар прозасын һәм идея, һәм эстетик яктан баета торган әсәр икәнлеге ачыкланып беткәне юк һәм ул бу хәлнең күпмедер дәрәҗәдә «Адәмнәр» повестеның темасы белән идеясен бутау күренешләре күзәтелүен дә ассызыклый: «ачлык әсәрнең темасын тәшкил итә, ә аның идеясе адәм балаларына киң фәлсәфи анализ һәм бәя бирү белән бәйләнгән. Повестьның прозабыз тарихындагы роле әнә шул идеясе зур тәэсир көче белән чагылдыруына бәйле» [Мусин 2002, б. 3]. Әдипнең «Татар хатыны ниләр күрми» һәм «Безнең көннәр» романнарының беренче вариантлары «ак тап» хәлендә кала килүенә дә борчыла галим, күп очракта әлеге әсәрләр фәнни тикшеренүләрдә дә үтеп барышлый гына искә алыналар. Галим фикеренчә, инкыйлабка кадәрге татар дөньясын объектив сурәтләү ягыннан беренче вариантлар күбрәк игътибарга лаеклы, чөнки ул чорда әдип тормышны гомуммилли позициядән торып яктырта, шунлыктан аның турында дөресрәк фикер йөртә. Безгә билгеле булган икенче вариантлар совет чоры идеологиясе кысаларында языла һәм авторның үткәндәге яшәешкә сыйнфый-тенденциоз каравын көчәйтә, бу хәл, ахыр чиктә, хикәяләүнең танып-белү мөмкинлекләрен дә чикли. Нәтиҗәдә, хәзер беренче вариантларның идея-эстетик кыйммәте арта.

Мәкаләдә Г. Ибраһимовның фәнни-теоретик карашлары әле тиешенчә өйрәнелмәгән булуы да искәртелә. Әгәр әдипнең XX гасыр башында татар әдәбияты теориясенә нигез салучыларның берсе булуын, совет чорында да бу өлкәдә әйдәп баручы булып калуын искә алсак, әлеге мәсьәләне өйрәнүнең гомумән татар әдәбият белеме тарихын фәнни яктырту өчен бик мөһим икәнлеге күренә. Гомумән, Ф. Мусин

әлеге мәкаләдә шул чор өчен гаять актуаль, тиз арада хәл ителергә тиешле мәсьәләләрне күтәрә. Шунысы куанычлы, классик әдипнең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре эшләгән 15 томлы академик басмасында әлеге мәсьәләләргә җитди игътибар бирелә, ачыклык кертелә һәм бу эшчәнлектә Ф.М. Мусин карашлары да таяныч, нигез булып торгандыр, дип уйлыйбыз.

Татар әдәбияты тарихы үсешенә зур өлеш керткән галим гомеренең ахырына кадәр, үз мәсләгенә тугры калган хәлдә, рухи мирасыбызны баетуда армый-талмый хезмәт итте. Аның фикер тирәнлеге, фәлсәфи эчтәлеге белән аерылып торган мәкаләләре даими рәвештә матбугатта басылып торды, ул Татарстанда һәм Россиянең төрле почмакларында гыйльми конференцияләрдә доклад-чыгышлар ясады, дистәләрчә аспирантның фәнни эшләренә җитәкчелек итте, фәнни хезмәтләрне рецензияләде, докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау советларында әгъза булып торды. Моннан тыш, даими рәвештә Татарстанда гына түгел, Россиянең төрле төбәкләрендә кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклауда оппонентлык итте. Фәнни хезмәтләргә җентекләп анализ ясаучы, кимчелек-җитешсезлекләрне шәхесне кимсетмәслек итеп, кечкенә табышларны да тотып алып, киләчәк эзләнүләргә рухландырырдай җылы сүзләр табып әйтә белүче галим фатихасы белән бик күпләр фән дөньясына аяк басты. Бүгенге көндә алар, сайлаган кыйблаларына тугры калып, остазлары эшен дәвам иттерәләр. Моннан тыш, галим республикабыздагы югары уку йортларында татар әдәбиятының төрле чорлары буенча лекцияләр укыды. Тыныч, салмак тавышлы, искиткеч тирән белемле шәхесне шәкертләре дә бик якын күрде, хөрмәт итте. Галим фәндә алмаш буын әзерләүгә вакытын да, көчен дә кызганмады.

Гомумән, Флүн Мослах улы Мусин – үз мәктәбен булдырган, Татарстанда гына түгел, чит төбәкләрдә дә дәвамчыларын тәрбияләгән олпат галим. Аның фәнни-теоретик карашлары, ачыш-казанышлары, татар әдәбияты тарихына караган җитди хезмәтләр язылганда, еш кына нигез итеп алына, исбатлауга дәлил булып тора.

**Әдәбият**

*Мусин Ф.* Милләт сагында // Казан утлары. 2008. № 2. Б. 95–104.

*Мусин Ф.М.* Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 191 б.

*Мусин Ф.* Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүнең торышы һәм бурычлары // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 12–19.

*Мусин Ф.* Гаяз Исхакый – милли идеолог һәм лидер // Гаяз Исхакый иҗаты: хәзерге караш: Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2008. 376 б.

***Габидуллина Фәридә Имаметдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль унивеситетының Алабуга институты доценты*

УДК 81'282

*М.Р. Булатова*

# ТЕЛ ГАЛИМЕ И.С. НАСИПОВКА 60 ЯШЬ

Статья посвящена 60-летию со дня рождения языковеда, профессора, доктора филологических наук Илшата Сахиятулловича Насипова. Учёный-методист внёс большой вклад в становление и развитие кафедры татарской и чувашской филологии (Стерлитамакский филиал Уфимского университета науки и технологий) и кафедры татарского языка и литературы (Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы), осуществляющих подготовку учителей родных языков и литератур. Сфера научных интересов И.С. Насипова – диалектология, историческая лексикология, языковые контакты народов Урало-Поволжья, сравнительно-историческое и сопоставительное языкознание. Он является автором многочисленных научных статей, учебников, монографий, учебных пособий, программ и методических разработок. В статье характеризуются педагогические и научные достижения учёного.

**Ключевые слова:** Илшат Сахиятуллович Насипов, языкознание, татарский язык, диалектология, лексикология, ученый, кафедра, методика преподавания.

The article is dedicated to the 60th anniversary of the birth of linguist, professor, PhD Ilshat Sakhiyatullovich Nasipov. Scientist and methodologist made a great contribution to the formation and development of the department of Tatar and Chuvash philology (Sterlitamak branch of the Ufa University of Science and Technology) and the department of Tatar language and literature (Bashkir State Pedagogical University named after Akmulla), which trains teachers of native languages and literatures. The sphere of scientific interests of I.S. Nasipov is dialectology, historical lexicology, language contacts of the peoples of the Ural-Volga region, comparative historical and comparative linguistics. He is the author of numerous scientific articles, textbooks, monographs, teaching aids, programs and methodological developments. The author describes the pedagogical and scientific achievements of the scientist.

**Keywords:** Ilshat Sahiyatulovich Nasipov, linguistics, Tatar language, dialectology, lexicology, scientist, Department, teaching methodology.

Татар дөньясы халкыбызга, яшь буынга телебезнең барлык нечкәлекләрен, әдәбиятын, мәдәниятен, тарихын, сәнгатен җиткерү һәм үстерүгә бөтен гомерен багышлаган гыйлемле, талантлы, милли рухлы галимнәргә, укытучыларга һәм әдипләргә бай. Шуларның берсе – мәгариф һәм фән өлкәсендә олуг эшләре белән танылган шәхес, М. Акмулла исемендәге Башкортстан дәүләт педагогия университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы профессоры, филология фәннәре докторы Илшат Сәхиятулла улы Насипов. 2024 елның март аенда аңа 60 яшь тулды.

И.С. Насипов 1964 елның 16 мартында Башкортстан Республикасы Илеш районы Иске Күктау авылында туа. Туган авылында урта

мәктәпне тәмамлагач, 1981–1987 елларда Башкорт дәүләт университетның татар-рус бүлегендә югары белем ала. 1987–1989 елларда Башкортстанның Авыргазы районы Тукай урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, мәктәп директорының укыту-тәрбия эшләре буенча урынбасары вазифаларын башкара.

1989–1993 елларда Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер сәнгать) институтында аспирантурада укый. Күренекле тел белеме галиме, академик Мирфатыйх Зәкиев җитәкчелегендә 1994 елда «Древнетюркский пласт диалектной лексики мензелинского говора татарского языка» дигән темага кандидатлык, 2010 елда «Финно-угорские заимствования в татарском языке: синопсис и таксономия» темасына докторлык диссертацияләрен яклый.

И.С. Насипов 1989 елдан башлап Стәрлетамак дәүләт педагогия институтында милли мәктәпләрдә рус телен укыту кафедрасы ассистенты, өлкән укытучысы булып эшли. Бу институт 2005 елларда Стәрлетамак дәүләт педагогия академиясе (бер-ике елдан Зәйнәп Биишева исеме дә өстәлә), 2023 елдан Уфа фән һәм технологияләр университетының Стәрлетамак филиалы дип үзгәртелә. 1994 елдан ул – әлеге уку йортының филология факультеты татар бүлеге мөдире. 1997 елда татар һәм чуваш филологиясе кафедрасына нигез сала һәм 2012 елга кадәр анда мөдир булып тора. Кафедрада татар-рус һәм чуваш-рус бүлекләре эшли. Анда «Татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты», «Чуваш теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты» белгечлеге буенча укытучылар әзерләнә. Берничә ел элек белгечлек үзгәртелде: «Туган (татар) тел һәм әдәбият, инглиз теле», «Туган (чуваш) тел һәм әдәбият, инглиз теле» юнәлеше буенча абитуриентлар кабул ителә башлады.

Илшат Сәхиятулла улы бу институтның укыту эшләре һәм җәмәгатьчелек белән бәйләнеш буенча проректор вазифаларын да башкара. 2012 елдан алып 2024 елга кадәр М. Акмулла исемендәге Башкортстан дәүләт педагогия университетының филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире булып эшли. Бүген – шушы кафедра профессоры. Шул ук вакытта «Башкортстан Республикасында күптеллелек шартларында туган (татар) тел, әдәбият һәм мәдәниятнең яшәешен һәм үсешен өйрәнү» фәнни-тикшерену лабораториясе, Каюм Насыйри институтының белем бирү һәм мәдәният үзәге җитәкчесе дә.

И.С. Насипов җәмәгать, оештыру эшләрендә, татар Милли хәрәкәтендә актив катнаша. Ул – төрле елларда Бөтендөнья татар конгрессы, Башкортстан татарлары съезды делегаты, Башкортстан татарлары конгрессы башкарма комитеты әгъзасы, Башкортстан татарлары конгрессының Стәрлетамак шәһәре бүлекчәсе башкарма комитеты рәисе. Мәгариф өлкәсендә башкарган фидакяр эшчәнлеге өчен «Башкортстан Республикасы мәгариф алдынгысы» (2003), «Татарстан Республикасы мәгарифендәге казанышлары өчен» (2015),

«РФ Югары һөнәри белем бирүнең мактаулы хезмәткәре» (2016), «Татарстан Республикасы югары мәктәбенең атказанган хезмәткәре» (2020), «Башкортстан Республикасы мәгарифенең атказанган хезмәткәре» (2022), «Россиянең алтын кафедрасы» (2012) билгеләре белән бүләкләнгән; аңа Башкортстан, Татарстан Республикалары һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыкларының рәхмәт хатлары да тапшырылган.

И.С. Насипов җитәкчелегендә тупланган татар һәм чуваш филологиясе кафедрасы 1997 елда профессиональ кадрлар (И.С. Мансуров, Ф.Т. Бохарова, Г.З. Габбасова һ.б.) кулында уңышлы эшли башлый, җитди үсеш ала. Илшат Сәхиятулла улы тырышлыгы белән студентларның иҗади үсеше өчен дә төрле мөмкинлекләр ачыла. «Илһам чишмәләре», «Дуслар» әдәби түгәрәкләре, «Нәүрүз», «Савни» вокаль ансамбльләре, «БаСТа» шаяннар һәм тапкырлар командасы барлыкка килә һәм хәзер дә уңышлы эшләвен дәвам итә. Алар бөтенроссия, халыкара, республика, шәһәр конкурслары лауреатлары, дипломант исемнәрен яулыйлар.

И.С. Насипов гомерен укыту-тәрбия системасы, мәгариф һәм фән өлкәсендә хезмәт итүгә багышлый. Иң беренче чиратта, игелекле эш – мәктәп укучыларында милли үзаң, туган телгә, туган җиргә һәм үз халкыңа мәхәббәт, алар белән горурлану хисе тәрбияләрлек яшь белгечләр, татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерли. Һәр студентның уку йортын тәмамлаганнан соң да кайда һәм ничек эшләве хакында хәбәрдар ул. Күп кенә шәкертләре үз язмышын укыту белән бәйләгән. Аспирантурада укуын дәвам иткәннәре дә аз түгел. Аларның кайберләре – филология фәннәре кандидатлары. Әйтергә кирәк, студент елларында – диплом эше җитәкчесе, кандидатлык диссертациясе яклаганда рәсми оппонентым да Илшат Сәхиятулла улы булды. Остазыбыз фән һәм мәгариф юлындагы белгечләр белән элемтәсен өзми. Аларның укыту эшләре барышын күзәтеп тора, киңәшләре белән укытучы тәҗрибәсен, осталыгын тупларга ярдәм итә; фәнни мәкалә һәм китапларга бәяләмәләр бирә.

И.С. Насипов югары уку йортлары студентлары өчен татар телен, диалектологиясен укыту буенча дистәдән артык уку әсбаплары, программалар, методик кулланмалар төзи: «Татар теле: Программа һәм методик күрсәтмәләр» (1999), «Введение в теорию языка: Учебно-терминологический словарь» (2001), «Татар теле һәм әдәбияты: Методик материаллар» (2003), «Татарская диалектология: Учебно-методические материалы» (2003), «Татар диалектологиясе: Биобиблиографик белешмә (2004), «Введение в теорию языка: Учебное пособие с грифом УМО МО РФ» (2007), «Древние языки: Учебно-методические материалы» (2008) һ.б. Мәктәп укучыларына татар телен өйрәтү, укыту мәсьәләләренә багышланган күпсанлы мәкаләләр, дәреслекләр авторы да ул (мәсәлән, «Татар теле: Башкортстанның урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек» (2005) һ.б.).

Педагогик эшчәнлек белән беррәттән диалектология белән бәйле фәнни-тикшеренү эшләре дә алып бара. Әйтергә кирәк, «Татар диалектологиясе» фәне – югары уку йортларында татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләүдә мөһим предметларның берсе. Аның фәнни-практик әһәмияте шактый зур. Ул тел тарихын, аның үсеш юлларын билгеләргә, хәзерге әдәби телнең күп кенә мәсьәләләрен ачыкларга, аерым үзенчәлекләрнең асылына төшәргә ярдәм итә, сүзлек составын баету чыганагы да булып тора. Мәктәп балалары сөйләмендәге кимчелекләрне бетерүдә дә аның файдасы чиксез. Әлеге уку йортларында әзерләнгән белгечләрнең күбесе республика мәктәпләренә эшкә җибәрелә. Алар Башкортстан Республикасында таралган татар сөйләшләренә хас үзенчәлекләрне, бу сөйләшләрнең формалашу тарихын белергә тиешләр.

Галим татар җирле сөйләшләрен, халкыбызның сөйләм телен өйрәнә, аларны 330 дан артык фәнни мәкалә һәм монографияләрендә яктырта. Фәнни-тикшеренү эшен ул үз туган авылына хас булган минзәлә сөйләшеннән башлап җибәрә. Аның 1994 елда Казан шәһәрендә уңышлы якланган «Древнетюркский пласт диалектной лексики мензелинского говора татарского языка» дип исемләнгән кандидатлык диссертациясе Башкортстан һәм Татарстан территорияләрендә таралган минзәлә сөйләшендә кулланылган лексик берәмлекләрнең борынгы төрки катламын ачыклауга, туплауга багышланган. Нигездә, И.С. Насипов Урал алды җирлегендә таралган татар халык сөйләшләре үзенчәлекләрен өйрәнү белән шөгыльләнә. Студентлары белән фәнни экспедицияләр оештыра, бик бай диалекталь материаллар туплый. Төрле төбәкләрдә фәнни-гамәли конференцияләрдә катнаша, тел, сөйләш һәм укытуга бәйле докладлар белән чыгыш ясый.

И.С. Насиповның татар тел белеменең бер тармагы – лексикология өлкәсендә җитди казанышларын тәшкил иткән хезмәтләре бар: «Сравнительно-историческое исследование системы лексико-тематических групп татарского языка» (2007), «Опыт систематизации финно-угорских заимствований в татарском языке» (2009), «Языковые контакты в Волго-Камье. Марийские заимствования в татарском языке» (2009), «Языковые контакты в Волго-Камье. Мордовские заимствования в татарском языке» (2013), «Языковые контакты в Волго-Камье. Удмуртские заимствования в татарском языке» (2013), «Татар лексикологиясе» (2016) һ.б.

Галимнең «Финно-угорские заимствования в татарском языке: синопсис и таксономия» дип аталган докторлык диссертациясе (2010), «Опыт систематизации финно-угорских заимствований в татарском языке» (2009) монографиясе татар телендә кулланылган фин-угор алынмаларына багышлана. Төрки халыклар үз тарихында фин-угор халыклары (удмурт, мари, мордва) белән күп гасырлар дәвамында даими һәм үзара тыгыз мөнәсәбәттә була. Аларга төркиләрнең йогынтысы көчлерәк булса да, фин-угорлар да төрки халыкларның этник һәм тел үзенчәлекләре барлыкка килүдә аерым урын алып тора.

Берникадәр дәрәҗәдә бу йогынты татар телендә һәм аның җирле сөйләшләрендә алынма сүзләр буларак чагылыш таба. Автор удмурт, мари, мордва телләреннән үтеп кергән барлык лексик берәмлекләрне туплый, анализлый, аларның татар әдәби телендә һәм сөйләшләрендә кулланылышы турында тәфсилләп яза.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында басылып чыккан коллектив монография – өч томлы «Татар лексикологиясе» (2016) хезмәтенең икенче томында төп авторларның берсе дә ул. Академик лексикология проектының җитәкчесе – академик Мирфатыйх Зәкиев. Китапның икенче томы татар теленең лексик составы формалашу, үзгәрү һәм үсү тарихын, лексиканың кулланыш үзенчәлекләрен яктыртуга багышлана. И.С. Насипов әлеге хезмәттә татар телендә кулланылган фин-угор алынмаларының үтеп керү тарихы, аларның лексик-тематик төркемнәре, лингвистик үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирә. Фин-угор алынмаларының лексик-семантик үзенчәлекләрен тасвирлау бу телләрнең бәйләнеш үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Чөнки лексиканың тематик төркемнәре бу халыкларның аралашуы нинди иҗтимагый-сәяси, хуҗалык-икътисади һәм табигать шартларында баруын ачык чагылдыра, рухи һәм матди лексикада булган үзгәрешләрне күзәтергә мөмкинлек бирә.

Гомумән, Илшат Сәхиятулла улының фәнни хезмәтләре – татар тарихы, теле, лексикологиясе һәм диалектологиясе белән кызыксынучыларга бай һәм әһәмиятле чыганаклар; мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен язылган дәреслекләре, әсбаплары, методик кулланмалары тирән белемле, грамоталы белгечләр тәрбияләүдә зур өлге булып торалар.

И.С. Насипов Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан (Идел буе) федераль университетының Л. Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, Алабуга институты, шулай ук, Казакъстан югары уку йортларының туган тел кафедралары белән тыгыз хезмәттәшлек итә; даими рәвештә уку-укыту һәм фәнни-методик тәҗрибә белән уртаклаша, фәнни-гамәли конференцияләрдә, гыйльми форумнарда катнаша.

Йомгаклап әйткәндә, И.С. Насипов – фән һәм мәгариф өлкәсендә, гадәти тормышта да матур үрнәк булып торучы шәхес, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе, җитди фәнни хезмәтләре белән татар тел гыйлеменә үз өлешен керткән галим. Башкортстандагы татар филологиясе кафедраларының уңышлы эшләп килүе, үз туган телен, әдәбиятын, мәдәниятен хөрмәт иткән милли рухлы, югары квалификацияле белгечләр әзерләнү – барысы И.С. Насиповның да зур тырышлыгы нәтиҗәсе.

***Булатова Миңнира Рәхим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Ә.М. Закирҗанов*

## ШӘРИФ КАМАЛ ТУРЫНДА ЯҢА КИТАП
## («Шәриф Камал: фәнни-популяр җыентык / төз.: А.Р. Шәйхин, Г.Р. Җиһангирова. Казан: Җыен, 2023. 416 б. («Шәхесләребез» сериясе)

Статья содержит рецензию на научно-популярный сборник, посвященный Шарифу Камалу, внёсшему большой вклад в развитие татарской литературы начала XX века. Последовательно выявляются структура, цели, задачи, основные разделы книги. Через анализ вступительной статьи определяется новаторство, привнесенное в татарскую литературу писателем, особенности его творчества. Оцениваются малоизвестные сегодняшним читателям рассказы, публицистические заметки, стихотворения, которые дополняют и обогащают творчество писателя. Исследуя многочисленные воспоминания, письма, дневники, документы, автор определяет их место в раскрытии отдельных черт личности и творческого пути Ш. Камала, определяет их ценность для своего времени и современности.

**Ключевые слова:** Шариф Камал, научно-популярное издание, воспоминание, документ, письмо, дневник, личность писателя.

The article contains a review of a popular science collection dedicated to Sharif Kamal, who made a great contribution to the development of Tatar literature at the beginning of the twentieth century. The structure, goals, objectives, and main sections of the book are consistently identified. Through the analysis of the introductory article, the innovation introduced into Tatar literature by the writer and the peculiarities of his work are determined. Little-known stories, journalistic notes, and poems that complement and enrich the writer's work are evaluated by today's readers. Examining numerous memoirs, letters, diaries, documents, the author determines their place in revealing individual personality traits and the creative path of Sh. Kamal, defines their value for their time and modernity.

**Keywords:** Sharif Kamal, popular science publication, memory, document, letter, diary, personality of the writer.

Күпгасырлык татар әдәбияты тарихында XX йөз башының гаять зур урын алып торуы яхшы билгеле. Әлеге чор әдәбияты җитди Яңарыш кичереп, алдагыларының үсеш-үзгәреш юлын билгеләде. Әдәби процессның нигезен тәшкил иткән Г. Исхакый, Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Камал, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Г. Камал, Н. Думави, Ш. Бабич һ.б. әдипләрнең бай мирасы дөнья әдәби барышына кушылып китә. Алар арасында прозаик, драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе буларак танылу алган Ш. Камалның үзенә хас лаеклы урыны бар. Классик әдипнең тормыш һәм иҗат юлы шактый тулы өйрәнелсә дә, аның шәхесенә йогынты ясаган шартларга, әсәрләренең язылу тарихына һ.б. бәйле сораулар ачык калып

килә. «Җыен» фондының «Шәхесләребез» сериясендә дөнья күргән «Шәриф Камал» фәнни-популяр җыентыгы әнә шуларны тулыландыру, баету, ачыклау максатын күздә тота. Ш. Камалның Татарстан Милли музеендагы шәхси архивыннан, мемориаль квартирасы урнашкан «Татар китап йорты»ндагы материаллар арасыннан һәм башка чыганаклардан табылган язмаларны А. Шәйхин, Г. Җиһангирова бер системага салып, укучыларга тәкъдим итә.

Җыентык Д.Ф. Заһидуллинаның «Шәриф Камал – иң садә, иң яшерен хисләр җырчысы» дигән кереш мәкаләсе белән ачыла. Әлеге язма классик әдипнең татар әдәбияты тарихындагы урынын, алып килгән яңалыгын, традицияләргә нигез салуын билгеләүнең матур бер үрнәге булып тора. Әдип иҗатының башлангыч чорыннан алып, соңгы дәверендә язылган әсәрләренә кадәр тулы бәяләнеп, этрафлы нәтиҗәләр ясала. Беренче әсәрләре 1905–1906 елларда язылса да, Ш. Камал киң җәмәгатьчелеккә 1909–1910 елларда «Шура» журналында басылып чыккан хикәяләре белән танылa. Яңарыш дәвере кичергән татар әдәбиятында бу елларда эчтәлек һәм форма өлкәсендә эзләнүләр бара. Әдип үзенең әсәрләре белән аларга кушылып китә, кайберләрен исә үзе башлап җибәрә. Ул тормышта үзе күргәнбелгәннәргә нигезләнеп яза. Галимә билгеләп үткәнчә, *«кешеләрнең катлаулы психологиясен, рухи үзгәрешләрне, эчке дөньясын, хәтта аң төпкелендә барган процессларны сурәтләү объектына әйләндерә»* [Заһидуллина, б. 7]. Шуңа да Ш. Камалның «Уяну» (1909), «Сулган гөл» (1909), «Буранда» (1910), «Козгыннар оясында» (1910), «Курай тавышы» (1912) һ.б. хикәяләре гади кешенең күңел дөньясын, рухи каршылыкларын, еш кына чарасызлык алдында көчсез калучының кайгы-хәсрәтен ачып бирүләре белән үз вакытында ук киң яңгыраш таба. Әдипнең әсәрләре кыскалыгы, тирән мәгънәле булуы, психологизм алымнарын уңышлы файдалануы белән игътибарны җәлеп итә. Татар җәмгыятен төрле яклап ачуны максат иткән язучы, аеруча читтә бәхет эзләүчеләрне тулы һәм бөтен каршылыгында сурәтли. «Бәхет эзләгәндә» (1911), «Чит илдә» (1912), «Өйдә көтәләр» (1913), «Акчарлаклар» (1915) һ.б. әсәрләренә бәя биреп, Д.Ф. Заһидуллина мондый нәтиҗә ясый: *«Ш. Камал читтә бәхет эзләүнең милләтне инкыйразга китерә торган хәрәкәт булуын идея итеп күтәрә»* [Заһидуллина, б. 17]. Мәкалә авторы фикеренчә, читтә йөрүчеләр татар халкына хас күп кенә әхлакый сыйфатларын югалтып, аракы эчәргә, карта уйнарга, урынлы-урынсыз сугышырга өйрәнәләр. Шуңа бәйле арада туган җире, ата-анасы белән бәйләнешен өзеп, зимагур булып китүчеләр күбәя.

Ш. Камал Октябрь инкыйлабын шатланып каршы ала һәм үзенең иҗаты белән яңа җәмгыятькә хезмәт итүгә алына. Аның «Таң атканда» (1927), аеруча «Матур туганда» (1937) романнары татар совет әдәбиятының үсү юлын билгеләүче әсәрләр буларак бәяләнә. Сәнгати планда йомшак урыннар булса да, идея эчтәлеге ягыннан алар дуслык, хезмәттәшлек, ярдәмләшеп яшәү, мәхәббәт һәм тигезлекне

яклап чыгулары белән чор рухына аваздаш була һәм укучылар тарафыннан яратып укыла.

Җыентыкта Ш. Камалның публицистик язмалары, проза әсәрләре, шигырьләре, драмасыннан өзек, күпсанлы истәлекләр, көндәлекләр һ.б. урын алган. Әдип 1905 елда С.-Петербургта чыга башлаган беренче татар газетасы «Нур» (1905) белән хезмәттәшлек итә башлый, язмалары һәм шигырьләре басылып чыга. Китаптагы публицистик язмалары чор рухын ачык тоемлап, җитди мәсьәләләргә йөз тотып язылган. Инкыйлабларга кадәрге мәкаләләрдә һәртөр артталык, искелек, әдәпсезлектән көлү, аларны фаш итү, алдынгы милләтләрдән үрнәк алу үзәктә тора («Хатын-кыз мәктүпләре», 1910; «Хикәядән бер баб», 1910 һ.б.).

Язучының инкыйлаблардан соң дөнья күргән «“Өтер” үз урынында түгел» (1926), «Безне ничек каршы алдылар» (1929), «Мине кемнәр, нәрсәгә өйрәттеләр» (1934) язмалары шул чор рухын чагылдыруы белән кызыклы.

Җыентыкта Ш. Камалның төрле чорларда язылып, кабаттан бастырылмаган хикәяләре дә урын алган. Алар әлеге бай иҗатның аерым сыйфат-билгеләрен тулыландыруга хезмәт итә. «Чуар манзара» (1910) хикәясе XX гасыр башы татар тормышындагы өч төрле яшәү рәвешен тасвирлавы белән игътибарны җәлеп итсә, «Мигъраҗ» (1912) хикәясендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) җиде кат күккә ашуы турындагы вакыйга искә төшерелә. «Ай яктысында» (1912) хикәясендә яшь хатыннар-ирләр арасындагы мөнәсәбәтләр лирик-эмоциональ планда сурәтләнә. Әдипнең «Җыр тавышы ишетелгәндә» (1926) әсәре зуррак күләмле язманың бер өлеше булып тора. Үзәктә яңа тормыш төзү өчен ихлас хезмәт итүчеләргә бәйле бер вакыйга бирелә. Аның кыйммәтен Гражданнар сугышында ирен югалткан Гайниҗамалның күңел кичерешләрен, уй-фикерләрен эчке монолог, җан хәрәкәте аша сурәтләве билгели.

Китапның «Шигърият» өлешенә Ш. Камалның «Сада» (1906) җыентыгыннан берничә шигырь урнаштырылган. Аларда авторның ил хәлләреннән, татарлар тормышыннан хәбәрдар булуы ачык чагыла. Шигырьләрнең теле гарәп, төрек сүзләре белән чуарланган. Эчтәлектә лирик геройның тынгысыз күңеле ачыла. «Янә шу гаскәр»дә туган җиреннән аерылып читкә җибәрелгән, сугыш михнәтләрендә интегүче солдат язмышы сурәтләнә. Ә инде «Сада» («тавыш», «өн» мәгънәсендә) күләмле шигыре Гареб һәм Шәрык антитезасына нигезләнә. Лирик герой уйлануларында алга карап эш итүче Гареб илләренең тырышлыгын, алга китүен искә ала. Шәрык халыклары исә битараф булып, бу дөньяга ник килгәнен уйламыйча яши, дип борчыла. Шулар аша Ватан вә милләт мәнфәгатен кайгыртып, кешенең гыйлемгә һәм һөнәргә омтылышын яклый.

Ш. Камал драматург буларак та киң танылу ала. Аның «Хаҗи әфәнде өйләнә» (1915) комедиясе язылган вакыттан алып хәзергәчә сәхнәләрдән төшми. 1920–1930 елларда язылган «Ут» (1928),

«Козгыннар оясында» (1929), «Таулар» (1931), «Томан арты» («Габбас Галин») (1934) пьесаларында совет идеологиясе йогынтысы ачык сизелә, шулай да алар үз чоры сәхнәсендә уйналып, драматургия үсешенә уңай йогынты ясый. Җыентыкта урын алган «Төеннәр» пьесасы 4 пәрдәдә булып, бары 1 нче пәрдәсе генә бирелә. Әлеге өлеше 1928 елда «Безнең юл» журналында басыла, 2–3 нче пәрдәләренең кулъязмасы ТР Милли музеенда саклана. Пьеса ул чорда җитди бәхәсләргә китергән ир-хатын, гаилә ныклыгы, хыянәт мәсьәләләренә багышлана. Төп вакыйга байтак еллар элек ялган белән бер кызны үзенеке иткән, хәзер исә, фамилиясен үзгәртеп, алимент түләүдән качып йөргән ир-ат белән бәйле. 1 нче пәрдә буенча конфликт чишелешен ачыклап та, нәтиҗәләр дә ясап булмый, билгеле. Шулай да пьесаның сәнгати планда йомшак булуын тоемлау кыен түгел. Ул авторның иҗат юлын, сәнгати эзләнүләрен аңларга ярдәм итүче факт буларак тәкъдим ителә.

Китапта күпсанлы истәлекләр урын алган. Алар Ш. Камалны шәхес буларак ачарга, характер сыйфатларын билгеләргә ярдәм итә. Кызы Зәйнәп истәлегендә әтисенең йомшак характерлы булып, гади-гадәти тормыш алып баруы билгеләнә. Шулай ук әдипнең физик эшне яратып башкаруы, китап төпләү, сәгать төзәтү, радиоприборларны сүтеп-җыю белән шөгыльләнүен дә язып үтә. Язучылардан Г. Бәширов, Г. Кашшаф, Р. Ишморат, М. Гали, З. Бәшири, С. Хәким һ.б. истәлекләре бирелә. Аларда Ш. Камалның иҗат үзенчәлекләре, әдип буларак яшьләргә мөнәсәбәте, әдәби процесстагы урыны билгеләнә. Г. Бәширов истәлегендә әдипне элекке татар зыялылары традицияләрен дәвам иттерүче буларак бәяли. Әдәпле, тыйнак, тыныч булуын билгеләп, үзенә каршы чыгучыларга *«сынын катырырлык итеп каты әйтә торган гадәте»* [Бәширов, б. 173] булуын да искәртә. Тагын бер сыйфаты буларак мактау һәм мактануны җене сөйми торган кеше булуын ассызыклап үтә. Г. Кашшаф язмасында, 1940 елда автономияле республика язучылары арасында беренчеләрдән булып, Мәскәүдә Ш. Камал юбилеена багышланган тантаналы кичә булу факты билгеләнә. Р. Ишморатның хәтерендә әдип ачык йөзле, мөлаем күз карашлы, йомшак тавышлы, төз һәм ыспай гәүдәле кеше булып саклана. Истәлекләрнең байтагы Ш. Камалны күреп белгән, аның белән бергә хезмәт иткән кешеләр тарафыннан язылган. Алар 1944 елны Ш. Камал музее хезмәткәрләре тарафыннан Рузаевка (Пешлә) һәм Оренбург төбәкләренә оештырылган экспедицияләр вакытында тупланган. Әлеге язмаларны Ф.Х. Вәгазова җыеп, туплап музейга тапшырган.

Ш. Камалның тормышына, иҗатына кагылышлы документлар әдип белән бәйле аерым фактларны, вакыйгаларны төгәлләштерергә ярдәм итә. Мисалга, «Козгыннар оясында» (1929) пьесасының татар театрында уңыш белән куелуын һәм 1930 елны Казандагы Зур рус драма театры сәхнәсенә менгән беренче татар пьесасы булуын искәртеп үтик. Аны рус теленә татар театрының башлангычында торган И. Кудашев-Ашказарский тәрҗемә итә.

Ш. Камал язган һәм әдипкә башкалардан килгән хатлар күп булып, алар аның кызыксынуларын, кемнәр белән якыннан аралашуын, гаилә әгъзаларына мөнәсәбәтен, аларга карата булган хисләрен тоемларга ярдәм итә. Язучы тормышында гаиләсе гаять мөһим урын алып тора. Кая гына барса да даими рәвештә хатыны Хәят ханымның, балалары Зәйнәп белән Йосыфның, кияүләре Ефремның, оныклары Эльвира белән Валерийның хәлен белешеп тора, аларның борчу-мәшәкатен үзенеке кебек кабул итә. Әдипнең аралашу даирәсе киң булып, ул Татарстанның төрле оешмаларыннан, татар әдипләреннән тыш, Мәскәүдә, Киевта, Уфада, Саранскида, Чебоксарда яшәүче төрле милләт язучыларыннан, СССР Язучылар берлегеннән, М. Горький исемендәге Әдәбият институтыннан, «Дружба народов» журналыннан һ.б. күпсанлы хатлар ала, үзе дә актив яза.

Җыентыкта Ш. Камалның 1930–1940 елларга караган куен дәфтәрләреннән, блокнотларыннан язма-истәлекләре бирелә. Алар язучының соңгы чор тормышын, эш-мәшәкатьләрен, шатлык-борчуларын шактый тулы күзалларга ярдәм итә. Ш. Камал тормышының, иҗатының төп даталары, үзе исән чакта чыккан әсәрләренең библиографиясе, Татарстан Милли музеенда әдип коллекциясе, Ш. Камал музее тарихына караган мәгълүматлар, шулай ук әдип фатирындагы чыганаклар бирелү дә тулысынча аклана. Ә инде җыентыкны бизәп торган күпсанлы фоторәсемнәр Ш. Камалның тормыш һәм иҗат юлын, гаиләсен, якыннарын, даими аралашып яшәгән язучыларны, журналистларны, эшче-хезмәткәрләрне хәтердә яңарту аша чор рухын, иҗтимагый-мәдәни тормышның аерым сәхифәләрен күз алдына бастыра. Гомумән, XX гасыр башында яшәп иҗат иткән классик әдипкә багышлап чыгарылган әлеге басма аның турындагы мәгълүматларны баета, тулыландыра, тормышын һәм иҗатын киңрәк, тулырак аңларга, бәяләргә ярдәм итә.

**Әдәбият**

*Бәширов Г.* «Көзге ачы җилләрдә» повесть-истәлегеннән // Шәриф Камал: фәнни-популяр җыентык / төз.: А.Р. Шәйхин, Г.Р. Җиһангирова. Казан: Җыен, 2023. Б. 172–179.

*Заһидуллина Д.Ф.* Шәриф Камал – иң садә, иң яшерен хисләр җырчысы // Шәриф Камал: фәнни-популяр җыентык / төз.: А.Р. Шәйхин, Г.Р. Җиһангирова. Казан: Җыен, 2023. Б. 3–33.

Шәриф Камал: фәнни-популяр җыентык / төз.: А.Р. Шәйхин, Г.Р. Җиһангирова. Казан: Җыен, 2023. 416 б.

***Закирҗанов Әлфәт Мәгъсумҗан улы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге баш фәнни хезмәткәре, бүлек мөдире*

УДК 821.512.145

***Н.М. Юсупова***

# РУХИ МИРАС САГЫНДА

Статья посвящена изучению книги «Истории татарской литературы» Гали Рахима и Газиза Губайдуллина, в которой история татарского словесного искусства изучается, начиная с оригинальных рукописей Орхон-Енисея по первую половину XIX века; анализируется её вклад в развитие татарского литературоведения. В ней история татарской литературы включается в общий контекст развития тюркской, восточной и европейской литературно-философской мысли, в результате история тюрко-татарского словесного искусства воссоздается на фоне евразийской культуры в целом. Сложившаяся в книге научная концепция остается актуальной по сей день. На фоне этого автором статьи обосновывается актуальность перевода книги на кириллицу и повторного её опубликования. Возврат художественного, научного и интеллектуального наследия, составляющего основу духовного наследия татарского народа, в научный оборот, публикация малоизвестных письменных источников, остававшихся до этого в тени, является одной из актуальнейших задач современного литературоведения и текстологии.

В первой части книги анализируются общетюркские памятники рунической, уйгурской и арабской письменности, суфизм и его влияние на восточные литературы, приводятся сведения об уйгурской, чагатайской, сельджукской и османской литературах. Во второй части объектом исследования становятся формирование и развитие татарского литературного языка, «Кодекс куманикус», набгробные камни, ярлыки; изучаются тексты Рабгузи «Кыйссас эл-энбия», Сулеймана Бакыргани, «Кисекбаш китабы», «Сэйфелмелек» и др. Третья часть посвящается изучению творчества поэтов и писателей XVII, XVIII вв., первой половины XIX века. Богатый фактический материал, работа с рукописями Монголии, Китая, Алтая, Средней Азии, Европы, наличие концептуальной основы указывают на научную подготовленность авторов. Знание истории, понимание истории религии и культуры определяют обоснованность и убедительность научной концепции «Истории татарской литературы».

**Ключевые слова:** история татарской литературы; Гали Рахим; Газиз Губайдуллин; концепция; тюрко-татарская литература.

The article is devoted to the study of the book «History of Tatar Literature» by Gali Rakhim and Gaziz Gubaidullin, in which the history of Tatar literary art is studied, starting with the original manuscripts of the Orkhon-Yenisei from ancient times to the first half of the 19th century; her contribution to the development of Tatar literary criticism is analyzed. In it the history of Tatar literature is included in the general context of the development of Turkic, Eastern and European literary and philosophical thought as a result the history of Turkic-Tatar verbal art is recreated against the background of Eurasian culture as a whole. The scientific concept developed in the book remains relevant to this day. Against this background, the author of the article substantiates the relevance of translating the book into Cyrillic and re-publishing it. The return of the artistic, scientific and intellectual heritage, which forms the basis of the spiritual heritage of the Tatar people, into scientific circulation, the publication of

little-known written sources that had previously remained in the shadows, is one of the most pressing tasks of modern literary criticism and textual criticism in general.

The first part of the book analyzes common Turkic monuments of runic, Uyghur and Arabic writing, Sufism and its influence on eastern literatures and provides information about Uyghur, Chagatai, Seljuk and Ottoman literatures. In the second part, the object of study is the formation and development of the Tatar literary language, the Codex Cumanicus, tombstones, labels; the texts of Rabguzi «Kyyssas el-enbiya», Suleiman Bakyrgani, «Kisekbash kitaby», «Seifelmelek», etc. are studied. The third part is devoted to the study of the works of poets and writers of the 17th, 18th centuries and the first half of the 19th century. Rich factual material, work with manuscripts from Mongolia, China, Altai, Central Asia, Europe and the presence of a conceptual framework indicate the scientific preparedness of the authors. Knowledge of history, understanding of the history of religion and culture determine the validity and credibility of the scientific concept of the «History of Tatar Literature».

**Keywords:** history of Tatar literature; Gali Rahim; Gaziz Gubaidullin; concept; Turkic-Tatar literature.

Татар әдәбиятының тарих тузанына күмелгән әдәби-тәнкыйди, гыйльми мирасын татар укучысына кайтару, татар халкының рухи мирасы нигезен тәшкил иткән, әмма бүген фәнни җәмәгатьчелекнең дә билгеле бер өлешенә генә билгеле язма чыганакларны кабат фәнни әйләнешкә кертеп җибәрү – бүгенге әдәбият белеме һәм текстология тармакларының көнүзәк бурычларыннан. Әлеге фикер «Рухи мирас» сериясеннән чыгып килә торган чираттагы басма – Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллин нәзари фикер үсешенең ачык энциклопедиясе булган, шушы юлда иң саллы хезмәтләрдән саналган «Татар әдәбияты тарихы» китабы мисалында да дәлилле яңгырый. Биредә урын алган фәнни карашлар, әдәбият тарихын өйрәнү барышында ул алга куйган концепция һәм фактик мәгълүматлар инде бер гасыр дәвамында фәнни кыйммәтен югалтмый. Алай гына да түгел, сүз сәнгате тарихын системага салып, концептуаль югарылыкта өйрәнү теләсә кайсы чорда әдәбият белеменең теоретик югарылыгын, шушы юлда хезмәт итәрлек укымышлы, киң карашлы фикер ияләре булуын дәлилләрлек саллы факт та булып тора. Бу хезмәтнең бастырып чыгарылуы, киң җәмәгатьчелеккә кайтарылуы шул яктан да бик вакытлы һәм гыйльми әһәмияткә ия иде.

Д. Заһидуллина китапка язган кереш сүзендә әлеге хезмәткә төпле бәя биреп, аны бүгенге әдәбият белеме фәне контекстында анализлый, татар халкы, нәзари фикер үсешендәге урынын билгели. Үз вакытында төрки халыкларның югары уку йортларында дәреслек буларак кулланылса да, китапның язмышы шактый аяныч була. XX гасырның 30 нчы елларында башланган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр аның авторларын озак елларга онытылу упкынына ташлый, татар әдәбият белемендә сүз сәнгате тарихын өйрәнүгә юл салган хезмәт үзе исә кульязмалар бүлекләренең китап киштәләренә кереп урнаша. Шулай булса да, еллар үтеп, иҗтимагый-фәлсәфи фикер шактый үзгәреп, фәнни офыклар киңәйсә дә, гыйльми әһәмиятен югалтмаган

сирәк хезмәт, тарих тузанын сөртеп ташлап табылган җәүһәр ташы булып кала. Аның бүгенге татар укучысы, хәзерге әдәбият белеме өчен әһәмияте, кыйммәте нидә соң?

Беренчедән, «Татар әдәбияты тарихы» сүз сәнгатебез тарихы фән буларак эшләнмәгән чорда беренче булып мәйданга чыга, татар гыйльмиятендә әдәби фикер тарихын өйрәнүнең магистраль юлын сала, фундаменталь нигезен күрсәтә, системалы өйрәнү тәгълиматын көн тәртибенә куя. Авторлар үзләре дә хезмәтнең асылын шуның белән бәйләп аңлата: «Татар әдәбияты тарихы – моңар кадәр бер дә диярлек кул тимәгән, эшләнмәгән бер гыйлемдер. Мөәллифләрнең бу әсәрне язганда күз алдында торткан максатлары – әдәбиятыбызның тарихы хакында үзебезгә беренче мәртәбә мөфассалрак бер хисап биреп карау, әдәбият тарихыбызны фән шәкеленә кертү, системага салу юлында бер тәҗрибә ясап, беренче адым атлау, беренче нигез ташларын салудыр» [Рухи мирас..., 15 чыг., б. 20].

Икенчедән, әдәбият тарихын өйрәнгәндә китап авторлары диахроник системага, ягъни әдәби процессны хронологик эзлеклелектә өйрәнүгә нигезләнә. «Бер әдәбиятның тарихын фән рәвешенә китерү өчен, билгеле, анда бер система булырга тиеш; чөнки системадан башка һичбер төрле белем дә фән була алмый» [Рухи мирас..., 15 чыг., б. 20], – дип санаган авторлар әдәбият тарихын өйрәнүдә өч факторны аерып чыгара: язучылар иҗаты, типологик һәм хронологик факторлар. «Татар әдәбияты тарихы»ның төрле елларда чыккан томлыклары да диахроник системага нигезләнә, ягъни татар әдәбият белеме инде бер гасыр дәвамында, асылда, Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллин сызган юлдан, аларның карашларын үстереп, баетып алып бара, дисәк тә хата булмас.

Өченчедән, бу хезмәт «татар әдәбияты тарихы кайчан башлана, аның чишмә башы кайда?» дигән сорауга шул вакытта ук төпле җавап биреп мәйданга чыга. Ул сүз сәнгате тарихын гомумтөрки катламнардан башлап өйрәнергә кирәклекне көн тәртибенә куя. Бу тәгълиматның хаклы булуын тарих инде раслады: бүген дә татар әдәбияты тарихы гомумтөрки чордан, рун һәм уйгур язулы истәлекләрдән башлап өйрәнелә. Әдәби чорларның исемнәре бераз үзгәреш кичерсә дә, асылда, Г. Рәхим белән Г. Гобәйдуллин тәкъдим иткән этапларга бүленеш концепциясе әдәбият тарихында актуаль булып кала. Мисал өчен, әлеге хезмәттә Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбияты дәвере XIX гасыр ахырына кадәр сузыла. Д. Заһидуллина күрсәткәнчә, «Татар әдәбиятындагы Яңа заман исә XVIII гасыр ахырыннан, Хәлфиннәр, Фәезхановлар, Мәрҗаниләр, К. Насыйри, Акмуллалар иҗатыннан башлана. Шул рәвешле, бер дәвердән икенчесенә күчү арасында бер гасырлык күчеш чоры булып чыга. Кызганычка каршы, алардан соң чорларга бүлү мәсьәләсендәге күп кенә буталчыклыклар, аерым алганда, Яңа заманның башлану вакытын әле XIX гасыр башы, әле уртасы, әле соңгы чирегә дип билгеләүләр шушы үзенчәлекне исәпкә алмауга, бер дәвер беткән ноктаны икенчесенең

башланган вакыты итеп карау белән бәйле иде. Безгә, бу мәсьәләдә Г. Рәхим белән Г. Гобәйдуллин фикеренә әйләнеп кайтып, Яңа заман әдәбиятына күчү аралыгының XVIII гасыр ахырыннан XIX гасырның ахырына кадәр сузылуын тану таләп ителә. Күп кенә Европа әдәбият тарихларында, шул исәптән төрек әдәбияты тарихы фәнендә дә ул шулай» [Заһидуллина, 2022, б. 14–15]. Димәк, бу яктан да хезмәт үзенең әһәмиятен җуймаган.

Дүртенчедән, әдәби күренешләрнең формалашу үзенчәлеге, үсеш-үзгәреше, әдипләр иҗаты, әдәби ядкәрләр төрки, Гареб һәм Шәрык сүз сәнгате традицияләре яктылыгында өйрәнелә. Чын мәгънәсендә гыйлем ияләре булган, Гареб һәм Шәрык сүз сәнгатеннән, фәненнән, төрки мәдәнияттән тирән мәгълүматлы, ул үрнәкләрне оригиналда укый алган Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллин әдәби-мәдәни диалог аша татар әдәбиятының йөзен билгеләгән төп сыйфатларны, сүз сәнгатебезнең үз әдәби табышларын аерып чыгаралар.

Бишенчедән, төрки халыклар тарихын, аларның халык авыз иҗатын, борынгы кульязмаларга таянып, һәр чыганакны табып, белеп-аңлап язылган әлеге хезмәттә әдәбият үсеше киң масштабта – тел, мәдәният, тарих белән янәшәдә бәяләнә. Юкка гына хезмәтнең кереш өлешендә үк әдәбият тарихының киң мәдәни процесс кысаларында бәяләнәчәге искәртелми: «…бу китап Идел буенда төрк телендә язылган вә укылган әсәрләрне бер яктан гына карамыйча, аларның заманга, мәдәни мохиткә, заманасының фикри хәятына мөнәсәбәтләре, шулай ук телләре, өслүбләре, ниһаять, әдәби кыйммәтләре ягыннан да карап тикшерәчәктер. Әлхасыйль, чынлыкта бу әсәр бер әдәбият тарихы булудан өстен, Идел буе татарларының мәдәният тарихларының зур бер кисәген эченә алачактыр» [Рухи мирас..., 15 чыг., б. 25]. Сүз сәнгате тарихын мондый аспектта өйрәнү әдәби фикердә барлыкка килгән күп кенә күренешләрнең асылын, формалашу үзенчәлеген, мәйданга чыгу вакытын төгәлләштерергә, дөрес аңлатырга мөмкинлек бирә. Бу яктан да бүгенге әдәбият фәне, татар укучысы өчен әлеге хезмәт бәһаләп бетергесез кыйммәткә ия чыганак булып кала һәм сүз сәнгате үсешенең алга таба да киң планда, масштаблы күзаллаулар аркылы бәяләнергә тиешлеген дәлилли.

Алтынчыдан, әлеге хезмәттә әдәбият тарихы коры күзәтүләргә яки теоретик фикерләргә генә ияреп түгел, ә конкрет чыганакларга таянып языла. Китап авторларының Европа, Алтай, Кытай, Монголия, Урта Азия халыклары әдәбиятын, тарихын яхшы белүе күзгә ташлана. Кытай чыганакларын, Европа сәяхәтнамәләрен, В. Радлов, В. Бартольд, А. Самойлович, В. Томсен, С. Малов, Ф. Корш кебек белгечләрнең рус телендәге фундаменталь хезмәтләрен өйрәнеп, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, З. Вәлиди хезмәтләрен алар белән чагыштырып бәяли алалар. Авторларның борынгы текстларны яхшы белүе, оригиналда укый алуы да игътибарга лаек. Алар бик күп тарихи, әдәби чыганакларны фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә. Бу чыганакларның күбесе инде нәкъ менә әлеге китап аша бүгенге

укучыга кайтып ирешә. Биредә без аерым кульязмаларга бәйле фикерләр белән дә очрашабыз. Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллин тарафыннан теге яки бу кульязмаларның язылу чорына бәйле фәнни бәхәсләргә нокта куярлык яки мәсьәләне хәл итү юлын күрсәтерлек фикерләр дә әйтелә. Мәсәлән, аерым әдәби ядкәрләрнең тел үзенчәлекләренең иҗат ителү чорына туры килмәве кульязмаларны күчереп язучыларның аерым үзгәрешләр кертүе белән бәйләп аңлатыла. Яки аерым әсәрләрнең татар дөньясында таралыш алуын алар татар милләтенең ихтыяҗы, омтылышлары, менталитеты, күзаллаулары, тормыш-яшәеш рәвеше белән бәйләп куя.

«Татар әдәбияты тарихы»ның икенче һәм өченче кисәкләренең беренче басмасы 1922–1923 елларда дөнья күрә, ә беренче кисәге 1924 елда басылып чыга. 1925 елда «Феодализм дәвере» исеме белән кыскартылган икенче басма нәшер ителә.

«Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә. Мәдхәл» исеме белән аталган беренче кисәктә рун, уйгур һәм гарәп язулы гомумтөрки истәлекләр өйрәнү объекты итеп куела, уйгур, чыгтай, сәлҗук һәм госманлы әдәбиятлары турында мәгълүматлар бирелә. Шушы юлда төрки халыклар тарихы, аларның язу сәнгате үсеше, тәңречелек карашларының формалашу, үсү-үзгәрү тарихы бер җепкә тезеп куела. Рун язуы Орхон әлифбасы дип аталып, аның формалашуы бөртекләп, тарихи фактларга нигезләнеп аңлатыла.

Бу өлештә суфичылык һәм суфичылык шигъриятен тикшергән өлешләр кызыклы һәм бүген дә актуаль яңгырый. Суфичылыкның таралу сәбәпләре һәм формалары турында фикер йөртеп, төрки халыкларда киң таралуы түбәндәгечә аңлатыла: «Төрк халыклары арасында һәм аларның әдәбиятында суфилыкның ни өчен рәваҗ табуы мәсьәләсенә килсәк, без анда ике төрле сәбәп күрәбез. Беренчесе шул чит халыклардан кергән идеологиянең тәэсире булса, икенчесе – төрек халыкларының күчмә тормыш вә сахра-чүлләрнең җәгърафи халәте тудырган рухи хосусиятендәдер» [Рухи мирас..., 15 чыг., б. 93]. Суфичылык шигъриятенә хас сыйфатлар аерып куела: кинаялелек һәм символларга таяну; Аллаһка мәхәббәтне төп сурәтләү объекты итеп күтәрү; лирик геройның Аллаһ гыйшкыннан исерек зат, дәрвиш булуы; мистицизм; фикер иреклеге, хөрлеге (хөррияте кәламия). Бу хасиятләр һәркайсы гарәп, фарсы шагыйрьләренең әсәрләре фонында анализлап, бәяләп барыла. Шунысы бәхәссез: биредә урын алган суфичылык һәм суфичылык шигъриятенә кагылышлы гыйльми фикерләр бүгенге фәнни җәмәгатьчелек өчен дә кызыклы булып кала.

«Татар теле һәм әдәбиятының тарихи язмышы», «Идел буенда иң борынгы тел ядкәрләре», «Идел буенда чыгтай әсәрләре», «Идел буенда госманлы әсәрләре» дигән өлешләрне бергә туплаган икенче кисәктә татар әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсүе, борынгы тел ядкәрләре буларак «Коман мәҗмугасы», каберташ язулары, ярлыклар

өйрәнелә. Бу өлештә галимнәр татар сүзенең, этнонимының килеп чыгышын чыганакларга таянып, тәфсилләп аңлаталар, татар ханлыклары, этнографик төркемнәр барлыкка килү мәсьәләсенә җентекләп тукталалар, бу материалда «татар кем ул?» дигән сорауга да тулы җавап табыла. Идел буенда чыгтай әдәбиятыннан Рабгузиның «Кыйссас әл-әнбия», Сөләйман Бакырганиның «Хәзрәте Мәрьям китабы», «Хәким ата китабы», «Бакырган китабы», «Ахырзаман китабы» әсәрләре, «Сөбат әл-гаҗизин», «Кисекбаш китабы», «Диване хикмәт», «Йосыф китабы», Идел буенда госманлы әдәбиятыннан «Мөхәммәдия», «Сәид Баттал», «Тутыйнамә», «Әбүгалисина китабы» кебек әдәби ядкәрләр аерым-аерым тикшерелә.

Өченче кисәктә XVII, XVIII гасырларда, XIX гасырның беренче яртысында иҗат иткән әдипләр мирасына, аларның әсәрләренә, халык авыз иҗатына, сәяхәтнамәләргә, васыятьнамәләргә күзәтү ясала, татар әдәбиятының зур этаплары бәяләнә һәм тикшерелә. Икенче бүлекнең зур өлешен, авторлар үзләре үк искәрткәнчә, безнең сүз сәнгатенә «чыгтай вә госманлы әдәбиятларыннан кереп тә, үзгәртелмичә укылып килгән һәм, тәмамән үзләшеп, татар халкының үз әдәби малы хөкемендә булып киткән әсәрләр» [Рухи мирас..., 16 чыг., б. 123] тәшкил итсә, өченче бүлек «баштанаяк соңгы өч үткән гасыр эчендә Идел буенда татарларның үз язучылары тарафыннан язылган (оригиналь) әсәрләрдән гыйбарәт» [Рухи мирас..., 16 чыг., б. 123]. Бу бүлектә «Тәварихе Болгария», «Галикәй аталык васыятьнамәсе», «Бәдәвам китабы», «Рисаләи Газизә», «Таһир илә Зөһрә», «Кыйссаи Нәбрүз» һ.б. әдәби ядкәрләр тикшерелә. Авторларның фикер куәсе, фикерләү масштабы сокландыра: әсәрләрнең һәрберсе Көнчыгыш, төрки әдәбият белән бәйләнештә анализлана, бәяләнә, шул фонда татар әдәбиятының йөзе, үз традицияләренең формалашу ысуллары ачылып бара! Габдерәхим Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый, Габделкаһир Сөләйман углы, Шәмсетдин Зәки, Һибәтулла Салихов, Мәхмүд Ширвани, Габделҗәббар Кандалый иҗатлары да шул аспектта тикшерелә, әсәрләренә тулы анализ ясала.

Әлбәттә, киң карашлы, тирән мәгълүматлы, белемле, эрудицияле галимнәрнең бай эчтәлекле хезмәте хакында күп фикерләр әйтергә мөмкин. М. Мәһдиевнең Г. Рәхимне «Татар халкының иң затлы укымышлысы, милләтебезнең йөзек кашы» дип атавында олы хаклык бар. Шундый фикер иясе каләменнән генә бер гасыр буена әһәмиятен җуймаган фәнни хезмәт төшә ала: әдәбият тарихын үз чорының нәзари стереотиплары нигезендә тикшерсә, бәяләсә дә, бу китапның бүген дә фәнни кыйммәтен, актуальлеген югалтмавы күп нәрсә турында сөйли! Мондый хезмәтнең Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре А.М. Ахунов, И.Г. Гомәров, Л.Ш. Гарипова, Г.А. Хөснетдинова, Л.Р. Надыршина тарафыннан беренче мәртәбә кириллицага күчерелеп, татар укучысына тәкъдим ителүе рухи мирасыбызны кайтару юлында чын мәгънәсендә гыйльми вакыйга буларак бәяләнүгә лаек.

Кабат бастырып чыгарылмыйча, кульязмалар бүлегенең китап шүрлекләрендә генә калса да, «Татар әдәбияты тарихы» әдәбият гыйлемендә һәрдаим бик билгеле чыганаклардан санала, татар әдәбият белеменең даими күз уңында тора. Биредә урын алган күп фикерләр, тәгълиматлар, чыганагы, галимнәрнең исемнәре күрсәтелми генә үзләреннән соңгы фәнни хезмәтләргә дә «кереп китә». Тарихи дөреслекне урнаштыру ягыннан да, китапның кабат дөнья күрүе, андагы фикерләрнең үз авторлары белән татар укучысына килеп ирешүе кирәк иде. Бүгенге укучының, хәтта фән юлына баскан яшь буынның гарәп графикасын танымавын, укый алмавын исәпкә алганда, бу басманы кабат бастырып чыгаруның зарурияте бермә-бер арта. Алга таба да татар халкының рухи мирасын бүгенге укучыга тәкъдим итү, аз билгеле язма чыганакларны бастырып чыгару традициясе дәвамлы булсын иде!

**Әдәбият**

*Заһидуллина Д.Ф.* Кереш сүз // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбияты тарихы. Борынгы дәвер. Казан: ТӘһСИ, 2022. 15 нче чыг. Б. 5–16.

Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбияты тарихы. Борынгы дәвер = Духовное наследие: поиски и открытия. Г. Рахим, Г. Газиз. История татарской литературы. Древний период / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Ш. Гарипова, Г.А. Хөснетдинова, А.М. Ахунов, И.Г. Гомәров; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. Казан: ТӘһСИ, 2022. 15 нче чыг. 300 б.

Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Г. Рәхим, Г. Газиз. Татар әдәбияты тарихы. Борынгы дәвер. XVII–XIX гасырлар = Духовное наследие: поиски и открытия. Г. Рахим, Г. Газиз. История татарской литературы. Древний период. XVII–XIX века. Т. 2 / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Ш. Гарипова, Л.Р. Надыршина, А.М. Ахунов, И.Г. Гомәров, Г.А. Хөснетдинова. Казан: ТӘһСИ, 2022. 16 нчы чыг. 300 б.

***Юсупова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институты Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф Югары мәктәбенең татар әдәбияты кафедрасы профессоры, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге доценты*

# Э.К. СӘЛАХОВАНЫҢ «ТӘТЕШ ӨЯЗЕ ТАТАРЛАРЫНЫҢ КӨНКҮРЕШЕ ҺӘМ РУХИ ТОРМЫШЫ (XVIII йөз ахыры – XX йөз башы)» (Казан, 2023. 296 б.) КИТАБЫНА РЕЦЕНЗИЯ

Э.К. Сәлахованың «Тәтеш өязе татарларының көнкүреше һәм рухи тормышы (XVIII йөз ахыры – XX йөз башы)» монографиясе бу төбәкне, аның тарихын өйрәнү буенча татар телендә беренче комплекслы тикшеренү булып тора. Китапның максаты – Тәтеш өязендә гомер иткән татарларның көнкүрешен һәм рухи тормышын тасвирлау. Монографиядә өязнең иҗтимагый-сәяси, икътисади, рухи тормышы киңкырлы чыганаклар нигезендә яктыртыла. Игътибар шулай ук төбәкнең тарихи истәлекләренә, күренекле нәселләренә, үзенчәлекле гореф-гадәтләргә, аш-су традицияләренә дә бирелә. Монография галимнәргә, төбәк һәм нәсел тарихлары белән кызыксынучыларга адреслана.

Хәзерге вакытта Тәтеш өязе җирләре Татарстан Республикасының Тәтеш, Апас, Кама Тамагы һәм Буа районының бер өлешенә карый. Шунлыктан, хезмәттә шушы төбәкләрдә урнашкан торак пунктлар хакында, аның халкы, әлеге төбәктә барган иҗтимагый хәрәкәтләр турында сүз бара. Тәтеш төбәге тарихы берничә юнәлештә карала: төбәкнең бай археологик, эпиграфик, нумизматик истәлекләрен фәнни өйрәнү барышы һәм нәтиҗәләре, аның социаль-икътисади үсеше, рухи тормышы, мәгарифе, иҗтимагый вакыйгалар һәм хәрәкәтләр яктыртыла. Төбәк атаклы нәселләре аша да күзаллана. Моннан кала, хезмәттә мөһим иҗтимагый күренешләр, әлегә кадәр өйрәнелмәгән өлкәләргә игътибар бирелә. Алар арасында аеруча чукындыру һәм кире исламга кайту хәрәкәте, һәм шуңа бәйле, иман сагында торып, Туруханга сөрелгән шәхесләр язмышына аерым урын бирелә. Шулай ук халыкларның бер урыннан икенче урынга күчүләре, шуның нәтиҗәсендә авыллар белән аерым өлкәләр арасындагы тарихи бәйләнешләрне ачыклау фәнни тикшеренү эшендәге яңалыкларның берсе дип әйтергә була.

Китапның хронологик кысалары Тәтеш өязенең административ берәмлек булып яшәү вакыты белән бәйле, әмма географик яктан аның кысаларыннан чыгып киткән, чөнки өяз татарлары бөтен Тау ягы төбәгенең аерылгысыз өлешен тәшкил иткән.

Монографиянең структурасы кереш сүздән, алты бүлектән, нәтиҗәдән, чыганаклар һәм әдәбият исемлегеннән, кыскартулар һәм кушымталардан гыйбарәт. Беренче бүлектә Тәтеш төбәгенең археологик, нумизматик һәм эпиграфик һәйкәлләре карала. Материал Казан император университеты каршында эшләп килгән Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте экспедицияләре һәм Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри, Г. Әхмәровның төбәккә караган язмалары нигезендә төзелгән. Совет чоры һәм хәзерге заман тикшеренүләре дә җентекләп каралган. Һәйкәл-истәлекләрне тасвирлаганда автор аларны беренче булып ачкан галимнәрнең эшләренә мөрәҗәгать итә, татар мәгърифәтчеләренең язмалары белән тулыландыра.

Икенче бүлек алты параграфтан тора һәм төбәкнең социаль-икътисади үсешен яктырта. Беренче параграфта авыл хуҗалыгының торышы, җир биләү һәм җир мөнәсәбәтләренең үзенчәлекләре, төрле катламнарның хәле һәм социаль каршылыклар күрсәтелә. 1877–1878 еллардагы крестьян хәрәкәтенең төп вакыйгалары күзәтелә. Башка параграфларда һөнәрчелек һәм кәсепләр, сәүдә, атчылык, нефть разведкасы үсешләре турында мәгълүмат китерелә.

Вакыт чынбарлыгын чагылдыру өчен, ат урлау турында аерым сюжет бик урынлы дип саныйбыз. Тау ягындагы ат урлаучылар халык хәтерендә әле дә онытылмаган, алар фольклорда һәм нәфис әдәбиятта үз урыннарын алган.

Беренче бөтендөнья сугышы елларында Тәтеш өязе тормышы турындагы соңгы параграф бүлекнең гомуми эчтәлегеннән аерылып тора, әмма монографиянең әлеге структурасында ул урынлы һәм, һичшиксез, кызыклы дип уйлыйбыз. Э.К. Сәлахова бәетләрне һәм солдат хатларын анализлый, аларда сугыш авырлыкларын күтәрүче халыкның килеп чыккан фаҗигага мөнәсәбәте ачык чагыла. Кушымтада Тәтеш өязеннән Беренче бөтендөнья сугышына алынган һәм дәүләт тарафыннан бүләкләнгән хәрбиләрнең исемлеге китерелә.

Өченче бүлек Тәтеш төбәге татарларының рухи тормышына һәм традицион мәдәниятенә багышланган. Автор төбәкнең рухи тарихында эз калдырган яки төбәктән чыккан күренекле дин әһелләре турында мәгълүмат китерә, язма мәдәният һәм кульъязма мирас турында сөйли, халык бәйрәмнәре һәм йолалары, Тау ягы татарларының милли аш-су үзенчәлекләре белән таныштыра. Икенче параграф, рус теле укытучысы Г. Әхмәров һәм мулла Х. Бикташев мөнәсәбәтләре мисалында, традиционистлар һәм җәдитчеләр арасындагы конфликтны күрсәтә. Автор, дәлилләр китереп, шуны исбатлый: кадимиләр дип аталган диндарлар надан ретроградлар һәм прогресс дошманнары булмаган: «бервакытта да традиционлыкка яңалыкны каршы куярга ярамый, берсе бик әйбәт булып, икенчесен бик начар итеп бәяләү бервакытта да үзен акламый», – ди автор. XIX–XX гасырлар чигендә традиционлык белән яңарыш көрәше, аның кискенлеге, җәмгыятьнең шул чордагы үз юлын табу омтылышы, җиңел генә бармаган үзгәреш юлы төрле хәл-вакыйгалар мисалында ачыла бара.

Дүртенче бүлек өяздә һәм Тәтеш шәһәрендә татарларның халык мәгарифе торышын тасвирлый. Автор беренче тапкыр төрле чыганакларга, шул исәптән моңарчы җәлеп ителмәгән архив эшләренә таянып, Тәтеш өязе мәктәп һәм мәдрәсәләре, аларны оештыручылар һәм мөгаллимнәр турындагы мәгълүматларны системалаштыра. Тәтеш рус-татар мәктәбе мөдире Ш. Салиховның күренекле рус язучысы Л.Н. Толстой белән хат алышуы турында архив материаллары укучылар өчен аеруча кызыклы булыр дип саныйбыз. Автор билгеләп үткәнчә: «Бөек рус язучысы, фәлсәфәсече Л.Н. Толстой белән аралаша алырлык, аның белән әңгәмә тотарлык татар яшьләренең булуы, аларның белем дәрәҗәсе, фикерләү югарылыгы XX йөз башы татар

җәмгыятенең күрсәткече була ала». Бу исә Тәтеш төбәгенең мөһим бер үзәк булуын да ассызыклый.

Бишенче бүлектә автор элек билгеле булмаган архив материаллары нигезендә Тәтеш өязе һәм Тау ягындагы яңа чукындырылган мөселманнарның исламга кайту хәрәкәте тарихын тәкъдим итә. Хәрәкәтнең лидерлары – гади авыл имамнары һәм крестьяннар. Аларның дистәләгәне Турухан краена, ерак Себергә сөргенгә җибәрелгән. Беренче Бөтенроссия халык санын алуга каршы тору белән бәйле вакыйгалар да өяздә киеренке төс алган. Аерым алганда, проблеманы кую буларак, татар мөселманнарының чуваш халкына йогынтысы турында мәгълүмат китерелә. Соңгы параграфта шәҗәрәләр, архив документлары һәм өлешчә туган якны өйрәнү материаллары буенча Тәтеш өязе татарларының башка татар төбәкләре белән бәйләнешләре күзәтелә.

«Тау ягының атаклы нәселләре һәм шәхесләре» дигән соңгы алтынчы бүлектә Морза Галишаһ нәселенең һәм авыл имамы Мортаза Фәйзов токымнарының татар халкының мәдәниятенә керткән өлеше күрсәтелгән: «Җәмгыятьнең рухи тормышында һәр авылның муллалары, имамнарының роле бихисап. Алар үзләренең мәхәлләләре, авыллары кысасында эш итеп тә, татар җәмгыятенең сыйфатлы үсешен, белемен, әхлагын булдыручы төп көчләр», – дип бәяли автор. Аерым параграф танылган хатын-кызларга багышланган, анда автор күренекле педагог, җәмәгать эшлеклесе һәм шагыйрә Маһруй Мозаффариянең чын туган көнен билгели алган һәм Туруханга сөрелгән имамнарның хатыннары турында тирән мәгълүмат биргән, гомумән, берничә хатын-кыз мисалында гына да җәмгыять тормышында, аның үсешүзгәрешендә татар хатын-кызының әһәмиятле роль уйнавы күрсәтелгән.

Кушымтада Олы Әтрәч авылының 1858 елгы ревизия кенәгәсе; мәчетләр төзү, дини вазифаларга раслау турындагы документлар; нәсел исемлекләре; чукындырылган татарларның мөселманлыкка кире кайтуы турындагы документлар; ике исем белән (православ һәм мөселман) йөргән чукындырылган татарлар исемлеге; Сөкәй нефть ятмасының 1913 елгы тасвирламасы; Беренче бөтендөнья сугышында бүләкләнгәннәр исемлеге; архив материаллары буенча автор тарафыннан төзелгән шәҗәрәләр урнаштырылган.

Монографиядә Тәтеш төбәге татар тарихында борынгы һәм мөһим бер үзәкләрнең берсе буларак күрсәтелә. Идел буе халыкларының тарихын өйрәнгәндә бу төбәкнең иҗтимагый һәм мәдәни тормышын тасвирлау тарихи белемнәрне тулыландыра. Аерым төбәкнең тарихы, анда барган вакыйгаларны сурәтләү зур тарихны детальләп күрсәтергә мөмкинлек бирә. Бу саллы фәнни хезмәт әлеге юнәлештә үз максатына тулысынча ирешкән дип әйтә алабыз. Э.К. Сәлахованың монографиясе тарих фәнендә үзенең лаеклы урынын алыр һәм башка төбәкләрне өйрәнүдә матур үрнәк булып торыр.

***Абдуллин Хәлим Миңнулла улы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

**2024 елның 10 гыйнварында** Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында Парижда татар телендә басылып чыккан китапларны тәкъдим итү кичәсе булды. Парижда француз телендә «ANTHOLOGIE DE LA PROSE TATARE CONTEMPORAINE» («Хәзерге татар прозасы антологиясе»), Ленар Шәехнең «MON COEUR BRÛLE COMME UN FEU» («Йөрәккәем янганда») шигырьләр җыентыгы һәм Роза Туфитуллованың «GOULSOUM» («Язмыш җиле») романнары дөнья күргән. Француз телендәге китапларны тәкъдим итүдә Татар китап нәшриятының баш мөхәррире, шагыйрь Ленар Шәех, язучы, шагыйрь, драматург, әдәбият белгече Галимҗан Гыйльманов һәм «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе, язучы Ландыш Әбударова-Фәезова катнашты.

Татар әдәбияты француз теленә 2021 елдан 2023 елга кадәр тәрҗемә ителеп нәшер ителгән. Антологиядә хәзерге прозаиклардан Ркаил Зәйдулла, Айсылу Имамиева, Галимҗан Гыйльманов, Рөстәм Галиуллин, Фирүзә Җамалетдинова хикәяләре урын алган. Чарада студентлар Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Муса Җәлил, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев әсәрләреннән өзекләрне француз теленә үзләре тәрҗемә иткән вариантта яңгыратты.

**2024 елның 16 гыйнварында** татар академик музыкасына нигез салучыларның берсе, танылган композитор Нәҗип Җиһановның туган көне уңаеннан Татарстан Республикасы Милли музеенда Нәҗип Җиһановның хезмәттәшләре һәм дусларына багышланган күргәзмә ачылды. Чарада композитор язган опералардан өзекләр һәм кыллы квартет башкаруында татар композиторлары музыкасы яңгырады.

**2024 елның 31 гыйнварында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында танылган драматург, журналист, татар театрын оештыручыларның берсе Галиәсгар Камалның тууына 145 ел тулуга багышланган түгәрәк өстәл утырышы узды. Утырышны Институт директоры, филология фәннәре докторы Ким Миңнуллин ачып җибәрде. Оештыручылар исеменнән анда катнашучыларны – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Язучылар берлеге, фәнни һәм белем бирү оешмалары, вакытлы матбугат вәкилләрен һ.б. сәламләп, ул Г. Камал эшчәнлегенең күпкырлылыгын, әдипнең әсәрләре бүгенге көндә дә бик актуаль булуын билгеләп үтте. Республика Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова үзенең сәламләү сүзендә ТӘһСИ тарафыннан 2024 елда оештырылган беренче түгәрәк өстәлнең Г. Камал тормышына һәм иҗатына багышлануының символик мәгънәгә ия булуын ассызыклады. Түгәрәк өстәлдә филология фәннәре докторы, әдәбият белеме бүлеге мөдире Әлфәт Закирҗанов, сәнгать фәннәре докторы, Сәнгать белеме үзәге мөдире Рауза Солтанова, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ислам тикшеренүләре үзәге өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы Илдус Заһидуллин, филология фәннәре кандидаты, Институтның Сәнгать белеме үзәге өлкән фәнни хезмәткәре Айгөл Салихова-Габәши, тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни хезмәткәре Илнар Гарифуллин һ.б. чыгыш ясады.

**2024 елның 2 февралендә** Казан Кремлендә Фән һәм техника өлкәсендә 2023 ел өчен Татарстан Республикасы Дәүләт премияләре тапшырылды. Әлеге мәртәбәле премиягә 6 томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» өчен филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты Тимерханов Айнур Әхәт улы (проект җитәкчесе), филология фәннәре кандидатлары, ТӘһСИнең лексикография бүлеге хезмәткәрләре Таһирова Фәридә Инсан кызы, Сабитова Илһамия Исламетдин кызы, Галимова Ольга Николаевна, Сафина Эльвира Ирфат кызы, Сәфәров Ринат Таһир улы (бүлек мөдире), Гаффарова Фирая Фаяз кызы һәм Сабирова Гөлзадә Гәрәфетдин кызы лаек булды. Галимнәрне әлеге югары бүләккә ия булулары белән ихлас котлыйбыз, киләчәктә дә яңа фәнни казанышлар телибез!

**2024 елның 9 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Россия фәне көненә багышланган тантаналы утырыш үткәрелде. Утырышта Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Россия фән һәм югары белем министры Валерий Фальков, Татарстан Республикасы фәнни оешмалары, югары уку йортлары җитәкчелеге һәм галимнәре катнашты.

Чара башланганчы Рөстәм Миңнеханов, Валерий Фальков һәм башка кунаклар Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тармак бүлекчәләренең фәнни проектлары белән таныштылар, Россия фәне көненә һәм Татарстан Республикасында фәнни-технологик үсеш елына багышланган экспозицияне карадылар. Утырышта фән өлкәсендә югары казанышларга ирешкән галимнәргә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре тапшырылды.

**2024 елның 9 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы Миңнуллин Ким Мөгаллим улы «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләнде. Әлеге югары бүләкне К.М. Миңнуллинга, күпьеллык нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге, татар халкының телен һәм мәдәниятен үстерүгә һәм саклауга мөһим өлеш кертүе өчен, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Россия фәне көне уңаеннан уздырылган тантаналы чарада Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министры В.Н. Фальков һәм Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов тапшырды. Ким Мөгаллим улын әлеге мөһим вакыйга уңаеннан ихлас күңелдән котлыйбыз һәм киләчәктә дә яңа фәнни ачышлар, һөнәри казанышлар телибез!

**2024 елның 14 февралендә** Мамадыш шәһәрендә күренекле татар язучысы Шәйхи Маннур истәлегенә багышланган чаралар узды һәм аның исемен йөрткән премияләр тапшырылды. Әлеге премиягә агымдагы елда «Бөртекләп җыелган гомер» китабы өчен шагыйрә Дания Нәгыйм, матур әдәбиятны пропагандалау һәм яшь буынны милли-мәдәни җирлектә тәрбияләү юнәлешендәге күпьеллык эшчәнлеге өчен Мамадыш районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының Мамадыш балалар китапханәсе, әдәби иҗаты һәм «Балачак ТВ» проекты белән яшь буынны тәрбияләүгә керткән өлеше өчен Мамадыш шәһәре 5 нче «Бәләкәч» балалар бакчасы татар

теле тәрбиячесе Гөлия Сөнгатуллина, әдәби иҗаты һәм яшь буынны тәрбияләүгә керткән өлеше өчен Казандагы күппрофильле 186 нчы мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, яшь галимә Алия Мөбарәкшина лаек булды.

**2024 елның 15 февралендә** Россия сәнгать академиясе музей-күргәзмә комплексында танылган Казан рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Александр Михайлович Артамоновның «Alter Ego. График+» дип аталган шәхси күргәзмәсе ачылды. Әлеге чарада катнашып, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм институтының Сәнгать белеме үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, сәнгать фәннәре кандидаты О.Л. Улемнова үзенең чыгышында рәссамны иҗатында Көнбатыш һәм Көнчыгыш мәдәни кодларын, классик һәм авангард эш ысулларын, киң жанр һәм тематик диапазонны берләштергән, басма һәм уникаль графиканың төрле техникаларын оста үзләштергән, предметка тирән фәлсәфи мөнәсәбәтле белгеч буларак ачты. А.М.Артамоновның Россия Сәнгать академиясе Идел буе бүлеге һәм Россия рәссамнар иҗат берлеге Эксперименталь иҗади остаханәләренең «Графком» лабораториясе җитәкчесе, төрле сәнгать проектлары кураторы һәм яшь рәссамнарның остазы буларак, бүгенге көндә Татарстан графикасы сәнгатен үстерүдә мөһим роль уйнавын ассызыклады.

**2024 елның 16 февралендә** Казан Кремле фонды («Казан Кремле» музей-тыюлыгы) сирәк экспонат – XIX гасырның уникаль Коръән басмасы белән тулыланды. Бу басма 1803 елда Император Казан гимназиясе типографиясендә басылган.

**2024 елның 16–18 февралендә** Татарстан Республикасы Фәнни китапханәсе базасында «Россия Фәннәр академиясенең 300 еллыгы елында Казанда академик фән» дип аталган фестиваль үткәрелде. Фестиваль фәннең төрле юнәлешләре буенча лекцияләрне, түгәрәк өстәлләрне, күргәзмәләрне, экскурсияләрне колачлады. Чара Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге тарафыннан оештырылды.

**2024 елның 20 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Халыкара туган тел көне уңаеннан «Федераль белем бирү программаларын гамәлгә ашыру шартларында туган тел (татар теле) һәм әдәбиятны укыту: проблемалар һәм перспективалар» темасына төбәкара онлайн семинар үткәрде. Әлеге чарада методист галимнәр, туган тел һәм әдәбияттан УМК авторлары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты вәкилләре, Россия Федерациясе төбәкләренең һәм Татарстан Республикасының туган (татар) тел һәм әдәбият укытучылары катнашты.

**2024 елның 20 февралендә** «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясенә лаек булган алты томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» һәм башка сүзлекләрне тәкъдим итү чарасы узды. Проект җитәкчесе – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты, филология фәннәре докторы Айнур Тимерханов сүзлекне эшләү тарихы белән кыскача таныштырды. Матбугат конференциясендә Татарстан

Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре – лексикография бүлеге җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Ринат Сәфәров, бүлекнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Фәридә Таһирова, өлкән фәнни хезмәткәр, филология фәннәре кандидаты Ольга Галимова чыгыш ясады.

**2024 елның 21 февралендә** – Халыкара туган тел көнендә – Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында 2023 ел нәтиҗәләре буенча йомгаклау утырышы узды. Утырышны ачып, Институт директорының фән буенча урынбасары Олег Хисамов 2023 ел йомгаклары турында сөйләде һәм төп игътибарны коллектив алдында торган бурыч-максатларга юнәлтте. Утырыш кысаларында шулай ук Институтның структур бүлек җитәкчеләре һәрберсе үз юнәлеше буенча эш нәтиҗәләре белән таныштырды, перспектив эш юнәлешләренә аерым тукталды. Чыгышлардан соң кайбер мәсьәләләр буенча фикер алышу оештырылды, тәкъдимнәр яңгырады. Утырыш кысаларында Институт тарафыннан 2023 елда әзерләнеп нәшер ителгән фәнни хезмәтләр күргәзмәсе дә тәкъдим ителде.

**2024 елның 28 февралендә** «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында «Татар телендге 25 томлы «Татар халык иҗаты» академик басмасын тәкъдим итүгә багышланган матбугат конференциясе үткәрелде. Күптән түгел академик басманың 9 томы Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. Матбугат конференциясендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор, проект җитәкчесе К.М. Миңнуллин, бүлек мөдире, филология фәннәре кандидаты И.И. Ямалтдинов һәм 25 томлыкның дөнья күргән җыентыкларын төзүчеләр – филология фәннәре докторлары, бүлекнең баш фәнни хезмәткәре И.Г. Закирова һәм бүлекнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Л.Х. Дәүләтшина чыгыш ясадылар, журналистларның сорауларына җавап бирделәр.

**2024 елның 28 февралендә** Татар китабы йортында (Шәриф Камалның мемориаль фатиры) «Хәзерге мәдәни һәм фәнни институцияләрдә Шәриф Камал мирасын актуальләштерү» темасына түгәрәк өстәл утырышы оештырылды. Әлеге чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре – филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы Д.Ф. Заһидуллина һәм филология фәннәре докторы Ә.М. Закирҗанов катнашты. Дания Заһидуллина Ш. Камал иҗатын бүген яңача өйрәнергә кирәклеген билгеләп, тормышын һәм иҗатын яшь буынга җиткерү, аерым алганда, мәктәптә тәрбия дәресләрендә классиклар иҗатына тукталу мөмкинлекләре турында сөйләде. Әлфәт Закирҗанов әдип иҗатын ул яшәгән чор, аның замандашлары белән тыгыз бәйләнештә тикшереп бәяләүнең зарурлыгына басым ясады, мәктәпләр өчен классик язучылар иҗатын өйрәнүгә бәйле методик ярдәмлекләр эшләргә кирәклеген искәртеп үтте.

**2024 елның 1 мартында** Россия ислам институтының татар теле һәм милли мәдәнияте кафедрасы тарафыннан «Туган (татар) тел һәм әдәбият укытуның теориясе һәм

практикасы» темасына түгәрәк өстәл утырышы оештырылды. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни хезмәткәрләре – филология фәннәре кандидаты, милли мәгариф бүлеге мөдире Гөлназ Мөхәрләмова татар әдәбияты дәресләрендә укучыларда этномәдәни компетенция формалаштыру юлларына багышланган доклад белән чыгыш ясады, милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Мөслимә Шәкүрова татар язуы тарихы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнгән яңа «Әлифба» турында сөйләде.

**2024 елның 4 мартында** «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Сәнгать белеме үзәгенең яңа басмалары тәкъдим ителде. Сәнгать белеме үзәге эшчәнлеге, аның үсеш юлы турында сәнгать фәннәре докторы, үзәк мөдире Рауза Солтанова сөйләде, алга таба ул фәнни хезмәткәрләрнең соңгы вакытта дөнья күргән басмаларын тәкъдим итте. Бүлек эшчәнлегенең аерым юнәлешләре һәм сәнгать белгечләре әзерләгән китаплар белән сәнгать белеме кандидаты Наталья Герасимова, Луиза Петрова, Гүзәл Юнысова һәм Гөлназ Гыйлемҗанова таныштырды.

**2024 елның 4 мартында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Урта гасыр татар тарихы портретлары» дигән Бөтенроссия фәнни конференциясе узды. Конференциядә рәссам И.З. Мортазинның «Олуг Мөхәммәд хан» картинасы тәкъдим ителде, фәнни докладлар тыңланды. Конференция кысаларында «Казан ханлыгы: тарихны репрезентацияләү проблемалары» дип аталган түгәрәк өстәл оештырылды. Чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре – халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәрләре, филология фәннәре докторлары Лилия Мөхәммәтҗанова, Илсөяр Закирова, Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Азат Ахунов катнашты һәм чыгыш ясады.

**2024 елның 27 мартында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Татарстан Республикасының халык язучысы, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Әмирхан Еникинең тууына 115 ел тулуга багышланган «Әмирхан Еники һәм татар әдәбияты яңарышы» дип аталган түгәрәк өстәл утырышы үткәрде. Фикер алышуга түбәндәге мәсьәләләр чыгарылды: чорның тарихи-иҗтимагый һәм мәдәни мохите контекстында Ә. Еники шәхесе һәм иҗаты; Ә. Еники – XX гасыр татар совет әдәбиятын үзгәртүче; татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүдә Ә. Еникинең роле һәм аның традицияләре; Ә. Еники иҗаты – киләчәккә аталган мирас; Ә. Еники иҗатын өйрәнүнең торышы һәм бурычлар. Чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты, Татарстан Язучылар берлеге, вакытлы матбугат басмалары вәкилләре катнашты.

**2024 елның 29 мартында** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хисабы тыңланды. Әлеге чара кысаларында парламент фойесында Фәннәр академиясенең Татарстанда фәнни-технологик үсеш елына багышланган күргәзмәсе тәкъдим ителде. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты проектлары белән депутатларны ТӘһСИ директоры, филология фәннәре докторы, ТР ФА мөхбир әгъзасы Ким Миңнуллин таныштырды. Күргәзмәдә соңгы елларда дөнья күргән өчәр томлы академик «Татар әдәби теле тарихы» һәм «Татар теленең лексикологиясе», алты томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», 8 томлы «Татар әдәбияты тарихы», Г. Ибраһимовның 15 томлы академик басмасы, «Татар халык иҗаты»ның татар телендәге 25 томлы һәм рус телендәге 15 томлы җыентыклары, «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе, шулай ук электрон проектлар һәм милли мәгариф юнәлешендәге эшчәнлек тәкъдим ителде.

**2024 елның 30–31 мартында** Казанда «Дала Евразиясе халыкларының тарихы һәм мәдәнияте: традицияләр һәм үзара хезмәттәшлек» Халыкара фәнни конференциясе үткәрелде. Конференция – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе базасында төзелгән Дала Евразиясен тикшерү халыкара үзәгенең беренче фәнни чарасы.

Конференциядә Россия, Азәрбайҗан, Белоруссия, Болгария, Казакъстан, Кытай, Кыргызстан, Монголия, Румыния, Төркия, Үзбәкстаннан галимнәр катнашты. Пленар утырышта Россия Фән һәм югары белем министры урынбасары Константин Могилевский, халыкара Үзәк Азия тикшеренүләре институты директоры Эврен Рутбиль, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов, Россия Фәннәр академиясенең Ерак Көнчыгыш халыклары тарихы, археологиясе һәм этнографиясе институты директоры Николай Крадин һәм башкалар чыгыш ясады.

Конференция нәтиҗәләре буенча Дала Евразиясен өйрәнү буенча халыкара программа кабул ителде.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2024. № 1

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 29.03.2024. Басылды: 12.04.2024.
Офсет кәгазе. Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Гарнитура «Times».
Басма табак 12. Тираж 300 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшриятында басылды
(нәшрият адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал бушлай таратыла



Казан Кремлендә ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләренә Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премияләрен тапшыру тантанасы.
Казан, 2024 ел, 2 февраль




ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА мөхбир әгъзасы К.М. Миңнуллинны «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләү.
Казан, 2024 ел, 9 февраль



Россия фән һәм югары белем министры В. Фальковка ТР ФА тармак бүлекчәләренең фәнни проектларын тәкъдим итү. Казан, 2024 ел, 9 февраль



ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2023 ел нәтиҗәләре буенча йомгаклау утырышы. Казан, 2024 ел, 21 февраль

Е.П. Алексееваның «1920–1930 елларда Татарстанда кино сәнгате барлыкка килү (“Татаркино”ның 100 еллыгы уңаеннан)» мәкаләсенә



Беренче кинотеатр «Электро»



«Булат Батыр» фильмын төшерүчеләр төркеме. Икенче рәттә (уңнан сулга): актриса А. Войцик, режиссёр ассистенты И. Пырьев, режиссёр ассистенты һәм актёр К. Поздняков, бишенче – режиссёр ассистенты В. Корш-Саблин, җиденче – режиссёр Ю. Тарич, сулдан иң кырыйда – актриса Г. Кравченко. Кинокамера янында – оператор Г. Гибер. 1927 елның көзе. *(Г.Н. Кравченконың шәхси архивыннан кино белгече Р.М. Янгиров тәкъдим итте)*



«Булат Батыр» фильмыннан күренеш



«Комета» фильмыннан күренеш. Г. Кравченко һәм М. Яншин



«Комета» фильмын төшерүчеләр төркеме. Өстәге рәттә: (уңнан сулга) өченче – режиссёр В. Инкижинов. Урта рәттә: уңнан икенче – актриса Г. Кравченко, аның янында – актриса В. Вод. Утырганнар: уңнан икенче – режиссёр ассистенты һәм актёр К. Поздняков. *(Г.Н. Кравченконың шәхси архивыннан кино белгече Р.М. Янгиров тәкъдим итте)*

Г.Ф. Юнысованың «“Кави – Сәрвәр” операсы: әдәби-музыкаль нигез
һәм куелыш үзенчәлекләре» мәкаләсенә






«Кави – Сәрвәр» операсыннан күренешләр

Е.Н. Шевченконың «Драматик спектакльдә пластиканың роле турында
(Г. Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры тәҗрибәсеннән)»
мәкаләсенә




«100 Тукай» перформансы, 2023 ел




«Яралу» перформансы, 2023 ел





Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында ТР ФА хисабы кысаларында
Татарстанда фәнни-технологик үсеш елына багышланган күргәзмәне тәкъдим итү.
Казан, 2024 ел, 29 март

## М.Р. Булатованың «Тел галиме И.С. Насиповка 60 яшь» мәкаләсенә



И.С. Насипов 50 яшьлек юбилеенда.
Стәрлетамак, 2014 ел



Илшат Насипов фәнни җитәкчесе, академик Мирфатыйх Зәкиев
һәм үзенең шәкерте, филология фәннәре кандидаты
Миңнира Булатова белән. Казан, 2012 ел, 17 апрель

---

## Яңа китаплар










